PRESSA

1926–1991 елларда АЗАТ ХАТЫН

№ 10 / 2022

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ЯЛГЫЗ ӘТИ
ЯЗМЫШЫ
әтиләр көне

ирең̧не
бәхетле итәм
ТОРМЫШ
язган хикәят

чуду
КАБАКТАН
Дагстан сые

Алинә
ХӘМИДУЛЛИНА
«Максатчанлык – уң̧ышның төп сере!»

PRESSA

Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

■ 1985 елның җәе бик коры килгән. Әнием килен булып төшкән августның уналтысына кадәр күктә ник бер болыт әсәре күренсен.
Ә бит берничә ел очрашып йөргән әтием белән әниемнең юллары инде аерылырга да мөмкин булган. Юллама буенча Алексеевский районы Зур Тигәнәле мәктәбенә кайткан әнием Фәния, билгеләнгән эш вакыты чыккач, үз районына кайтып киткән. Әтием Равил исә, бәхет эзләп, нефтьле Әлмәткә юл тоткан. Шулай да, акыллы, тыйнак, шаян Нурлат кызын оныта алмаган ул. Тәвәккәлләп, кыз сорарга киткән. Оста куллы, яшел күзле кияү дәү әни-дәү әтигә ошаган...
Туй күлмәген алар Казанга барып икәү сайлаганнар. Ак күлмәк кигән әнием кара Волгада Тигәнәлегә килен булып төшкәндә, яңгыр сибәли башлый. Бер-берсен яратучы ике йөрәк кушылуын авыл халкы бәхеткә юрый.

Ландыш НӘСЫЙХОВА.
Казан.

Фото: Анна Арахамия.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Баш мөхәррир урынбасарлары 222-09-78
Мәликә Әсәтуллина
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламаның эчтәлеге (фото, текст) аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.


Тышлыкта:
Алинә Хәмидуллина
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 26.09.2022 ел.
Чыгу көне: 6.10.2022 ел.
Заказ О-2865
Тираж 8624

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык), П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Фото: Анна Арахамия

Ленар ШӘЕХ

* * *

Әй, көзкәем,
Көяз көзем минем!
Җаным-тәнем сиңа тартыла.
Шашкын күңел
Язга талпынса да,
Нигәдер гел көз яратыла.

Уйчан көзем,
Бөек көзем минем!
Елак та син, кайчак көләч тә.
Күзләремдә
Өмет уйный башлый,
Көз кояшы күктән көлгәч тә.

Әй, көзкәем,
Алтын көзем минем! –
Елмаюың йокты үземә.
Тар сукмактан
Йөгерәм...
Очам гына
Баса-баса яфрак-эзеңә.



Безнең тышлыкта



«Россия күләмендәге бәйгеләрдә дә татарча шигырьләр сөйлим, безнең әдәбиятка мөрәҗәгать итәм. Һәм бу башка катнашучылардан бер өстенлегем булып тора. Күп җиңүләремнең сере шунда.»

14
«Син булдырасың, кызым!»
Руфия Рәхмәтуллина







10
Сәясәттә дә, гаилә дә ихласлык кирәк
Эльмира Закирова

18
«Иң авыры – балага ирек бирү»
Чулпан Галиәхмәтова

24
Кадерле кешебез
Равия Шәймуллина

Э Ч Т Ә Л Е К

Заман һәм без

Әти — 6
Чулпан Галиәхмәтова

Йөрәгеңне йөрәгемә куям — 20
Лилия Гәрәева

Татар дөньясы

Яшәтәбез әле авылны! — 28
Алсу Шакирова

30 чакрым тукыма — 32
Алсу Заһидуллина

Мәдәни тормыш

Шигырьләп тамдылар яшьләрем — 34
Лилия Фәттахова

Соңарган туй — 36
Люция Фаршатова

Һәр китап — аерым бер Галәм — 43
Фирдүс Гыймалтдинов

Яшәеш

«Мин синең иреңне бәхетле итәм...» — 46
Гөлнур Сафиуллина

«Дустың да ул, кайчак дошманың да...» — 52
Гөлнур Сафиуллина

Хуҗабикә

«Алтын вакыт»ны истән чыгармыйк — 54

Яшь әни: сорау—җавап — 56

Көзен туклану рационы — 58

Стрессны чыгарабыз — 59

Өйнең яме — гөлләрдә — 62


Якты төсләр палитрасы — 64
Зилә Нигъмәтуллина

40




Жыр — язмыш ул!
Роза Мулланурова

50



Тик сине эзлим мин...
Лилия Гәрәеваа

60




Кабактан — чуду
Ләйсән Нургалиева тәкъдим итә

»



АКТУАЛЬ ТЕМА

Октябрь аеның соңгы якшәмбесендә рәсми рәвештә Әтиләр көне билгеләп үтелә. Ул бала тәрбияләүдә әти ролен ассызыклау һәм традицион гаилә кыйммәтләрен саклап калу, ныгыту максатыннан булдырылды. Илдәге иң яшь бәйрәмнәрнең берсе. Әле узган ел гына дәүләт күләмендә уздырыла башлады. Россия гаиләләрендә дилбегә элеккечә ирләр кулында. Әмма көнбатыштан килгән гендерлар тигезлеге җилләре гаилә кыйммәтләренә йогынты ясамый калмый. Моңа каршы тору өчен «әтиләр мәнфәгате» турында елдан-ел күбрәк сөйли башладылар. Хәзерге көннәрдә аеруча актуаль булган патриотик тәрбиядә әти культы кирәк. Чөнки «әти» сүзе «Ватан» сүзе белән аваздаш. Кайбер гаиләләрдә ул әле «әни» сүзе белән дә аваздаш.



ӘТИ



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Әтисезлек

Безнең җәмгыять гаилә кыйммәтләренә нигезләнеп төзелгән, шуңа күрә дә ул нык. Ләкин узган гасырның туксанынчы елларыннан соң читтән кертелгән замана трендларына ияреп, бу кыйммәтләрне төссезләндерергә тырышкан шаукымнарны да күзәтергә туры килә. Җитмәсә, аерылышучылар саны югары булып кала. Ә ул гаиләләрдә, нигездә, балалар бар. Өлкәннәрнең үзара аңлашу тапмавы аркасында бала әти тәрбиясеннән мәхрүм кала. Әле бит ялгыз аналар армиясе бар. Сүз – кияүгә чыкмый гына бала тапкан хатын-кызлар турында. Россиядә алар 5 миллион тирәсе. Бу биш миллион бала ата тәрбиясе күрми, ә бәлки әтисенең кем икәнен дә белми үсә дигән сүз. Хәзер хатын-кызлар ир-ат белән бертигез булып эшли, акча таба. Әни гаилә учагын саклый, әти мал таба дигән төшенчә актуальлеген югалтты. Шуңа күрә дә хатын-кызлар бала тәрбияләүдә ирләрнең актив катнашуын таләп итә йә мин болай да акча табам инде, нәрсәгә түзәм әле мин аңа, дип аерылышырга ниятли. Шул рәвешле, гаиләдә әти тәрбиясенең ролен арткы планга күчереп куя. Әмма гаиләдә әти бар икән, баласын алдына утыртып сөеп утырмаса да, дәресләрен әзерләшмәсә дә, булган абруе һәм ныклы йә җылы сүзе белән кирәк вакытта балага йогынты ясамый калмый. Бөтенроссия җәмгатьчелек фике-

рен өйрәнү үзәге «Илкүләм өстенлекләр» автоном коммерцияле булмаган оешма белән берлектә сораштырулар үткәргән. Ил халкының 67 проценты балалар мәйданчыгында кечкенә бала белән әти кешене күрү – гадәти хәл, ә игътибарны җәлеп итүче гайре табигый күренеш түгел дип саный. Һәм россиялеләрнең 72 проценты бүген әти кеше баланы әни кешедән начар карамый дип саный. «Күпчелек әтиләр гаиләдә үзләрен мал табучы дип кенә кабул итми, ә вакытларын балага, гаиләгә багышларга тели, – дип шәрехләгән әлеге тикшеренүләрне оешма җитәкчесе София Малявина. – Сораштыру нәтиҗәләре бик мөһим нәрсәне күрсәтә: хатын-кыз да, ир-ат та «идеаль әти» образын бертөсле күзаллый. Димәк, илдәге күпчелек гаиләләрдә әти-әни рольләре буенча үзара аңлашу һәм килешү бар дигән сүз». Бу инде идеаль гаиләләр турында. Әмма алда язуыбызча, тормыш бар яктан да идеаль була алмый.

Әти дә, әни дә...

Кеше язмышлары төрле булган кебек, гаилә язмышлары да төрле. Әле бит әни булмаган гаиләләр дә бар. Бу очракта әти роле, әти җаваплылыгы икеләтә арта: ул балалары өчен әти дә, әни дә.

Бүгенге көндә Россиядә ялгыз әтиләр саны – 648 мең тирәсе. Республикада әлеге әтиләр санын ачыклый алмадык. Татарстан Министрлар Кабинетының гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе дә, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы да мондый исәп алып бармаулары турында әйтте. Әти булмаган гаиләләргә, кызганыч, ияләшеп беттек инде без. Хатын-кыз тормышны да тарта, баласын да тәрбияли – нык ул, дибез. Ә ялгызы гына балалар үстергән ирләргә гаҗәпләнеп тә, җәлләп тә карыйбыз. Сынмас микән дип шикләнәбез, хатынсыз озак яши алмас, өйләнер дип уйлыйбыз. Ә чынлыкта алар яңа гаилә дә кормыйлар, «әнине алыштырып булмый инде, бу сафсата», дисәләр дә, менә дигән итеп балаларын да тәрбиялиләр.

«Мин бәхетсез кеше түгел»

Биектау районы Коркачык авылында яшәүче Габбас абый Галәветдинов йортының капка төбенә килеп туктадык. Капка төпләре, койма буйлары шау чәчәккә күмелеп утыра. Тәрәзә төпләрендә дә гөлләр күренә. Бу ихатада хатын-кыз булмаганга ышанасы да килми. Ә бит Габбас абый инде менә 26 ел ялгыз канат. Елмаеп-көлеп каршы алды ул безне, сөйләшеп аралашканда да йөзеннән елмаю китмәде.

Хатыны белән алар бары алты ел гына яшәп кала. Өйләре янында трактор бәрдереп китә аны. Габбас абый кулында җан бирә Васыйгасы. «Каравыл кычкырып елап җибәрмәдем инде, татар кешесе бик сабыр бит. Шунда ук балаларым күз алдыма килде. Аларны бит үстерергә кирәк. Олысына 4 яшь, кечкенәсенә – яшьтә тә сигез ай гына иде», – дип искә ала ул вакытларны Габбас абый. Бәхетенә, янында әнисе була. Балаларны тәрбияләргә ул булыша. Кызлар әбиләренә әни дип эндәшергә тели, әмма әбиләре риза булмый. «Улым өйләнсә, тагын бер әни булачак. Өйдә ике әни булмый», – ди ул. Малаен бик өйләндерәсе килсә дә (әни кешенең ялгыз улы өчен җаны сызланмый калмагандыр), Габбас абый өйләнми. «Балалар янына үги әни алып кайтмыйм», – ди. Үги әнинең бер матур үрнәге дә булмый тирәягында. Үги үги инде ул, әни түгел дип уйлый. Үги әни ана назы бирә дигән фикергә дә ышанмый ир. Нинди хатын туры килә бит әле?! «Татарларда бит бер шәп әйтем бар: «Сыер белән хатын-кыздан уңуы бик авыр», бик дөрес сүзләр ул», – дип, шаян елмая Габбас абый.



Сораштыру

Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүче үзәк, идеаль әти нинди сыйфатларга ия булырга тиеш дигән сорауга җавап эзләп, ил халкы арасында сораштыру уздырган. Сораштырылучылар төп сыйфатлар итеп менә шуларны күрсәткән:

- балаларының әнисен кайгырту, хөрмәт белән карау;
- балалар тормышында актив катнашу;
- бергәләп проблемаларны хәл итү юлларын эзләү;
- үрнәк була белү;
- мәрхәмәтлелек;
- ышанычлы булу.

Фото: www.freepik.com

Ә монда хатын гына түгел, балаларга әни булырга кирәк. Әни урынын беркем алыштыра алмый.

Габбас абыйның ике кызы – Чулпан белән Гөлия дә көлепелмаеп кына торалар. Бик шат күңеллеләр. «Без ярату-назда үстек. Әни юклыгын үсә төшкәч кенә сиздек. Әти безне һаман иркәләп торды, гел күчтәнәчләр, бүләкләр алып кайта иде», – диләр. Габбас абый кызларының югары белем алуларын тели. Һаман укулары белән кызыксынып тора. «Ул вакытта ата-аналар җыелышына ирләр йөрми иде әле. Оялып тормадым, үзем йөрдем», – ди Габбас абый. «Әниләрен кызларым бөтенләй хәтерләми. Аннан соң кыз бала әтисенә тартыла дип әйтәләр бит. Ул сүзләрдә дә хаклык бардыр. Табигатьтер инде ул, кыз кеше әтигә сарылучан. Минекеләр дә гел янымда булды. Кочаклап-үбеп кую безнең өчен гадәти хәл. Хәзер дә бетми әле ул гадәт», – ди әтиләре. Аның сүзләрен раслагандай, кечкенә оныгы Әминә бабасын муеныннан кочып, битеннән үбеп китә. Ә Габбас абый сөйләгәннәр күңелгә керә бара.


– Хатын үлде, ялгыз яшәдем, тормыш барып чыкмады, дип әйтеп тә булмый. Язмышыма шулай язылган, күрәсең. Гомер буе сагынып та яшәп булмый бит инде. Вакыт үткән саен, яралар ябыладыр ул. Мин бәхетсез кеше түгел. Тормыштан канәгать. Кызларымны үстердем, яхшы тәрбия бирергә тырыштым. Эшемдә дә хезмәтемне бәяләделәр. Пенсиягә чыкканчы машина йөрттем, «Татарстанның атказанган автотранспорт хезмәткәре» дигән мәртәбәле исемгә лаек булдым. Әле хәзер дә, пенсиядә булсам да, урман-янгын үзәгендә машина йөртүче булып эшләп йөрим...

Унбер ел элек әнисе авырып үлеп китә. Бик авыр кичерә ул югатуны Габбас абый. Илле елдан артык бергә яшәлгән. Әни кеше – изге кеше бит әле ул, җитмәсә. Ялгызлыктан курыкмый Габбас абый. «Картлык көнендә үзең генә каласың, диләр. Нишләп ялгызым калыйм? Балалар әкренләп ишәеп тора. Сөендереп, оныгым үсеп килә. Балалар атна саен кайтып йөри. Шөкер, миңа үпкәләре юк. Ә мин кызлар булып тууларына куанып бетә алмыйм. «Бәхетле кешеләрнең генә кызлары бар», – дип әйтәм һәрвакыт. Үги әни алып кайтмавымны соңыннан әни дә хуплагандыр дип уйлыйм. Әлегә кадәр хатынымның туганнары белән аралашып яшибез. Алар миңа рәхмәт кенә укый. Бигрәк тә телевизордан «Яланаяклы» кыз фильмын күрсәткәннән соң, елый-елый рәхмәт әйттеләр. Аннан соң Васыйга урынын минем өчен беркем дә алыштыра алмас иде. Аз яшәп калдык, әмма матур яшәдек».

– Кечкенә вакытта, әгәр әтиегез өйләнсә, дип сүз каталар иде, без риза булмый идек. Хәзер инде уйлыйбыз: ул вакытта бездә эгоистлык хисе көчле булгандыр инде. Өйдә чит кеше күрәсебез, ә иң мөһиме: әтине беркем белән дә бүлешәсебез килмәгәндер. Аның бөтен игътибары бездә булды, әле дә шулай. Шуның өчен без аңа бик рәхмәтле. Хәзер инде безнеке генә дигән уй юк, ялгызы яшәгәнче, янында йөрәгенә яткан иптәш булса, безгә тә тынычрак булыр иде дә соң... Ләкин инде ул теләми өйләнергә. Әтиебезне бик нык яратабыз, әти генә булганга микән инде ул?! Ул – безнең горурлыгыбыз. Шуңа да аңа лаеклы булып үсәргә тырыштык, бервакытта да йөзенә кызыллык китермәдек. Аның да безнең белән горурлануын теләдек», – ди кызлар.

«Зомби кебек яшәлгән»

Габбас абыйның янында әнисе булу зур терәк булган, билгеле. Әле бит бер ярдәмчесез бала үстергән әтиләр бар. Апас районы Урта Балтай авылында яшәүче Илфир Гәрәев – әнә шундыйлардан. Ике кыз тәрбияләп үстерә ул. Хатыны Ләйсән кисәк кенә авырып, үлеп киткәндә олы кызына – 10, кечесенә 3 яшь тирәсе була. Авылның икенче башында яшәгән хатынының әти-әниләреннән кала, беркеме булмый янында. Төзегән йортларыннан кубарылып китәргә дә теләми. Кызларын үзе генә үстерергә карар кыла. «Язмышың шулай булгач, тормыш өйрәтә ул. Чәч үрергә дә, ашарга пешерергә дә өйрәндем», – ди тыйнак кына аз сүзле Илфир. Ялгыз калгач, аның да бердәнбер уе – балаларны үстереп кеше итү була. Бары әнә шул максат белән яши башлый. Җиңел булмый, билгеле, тормыш. «Зомби кебек яшәлгән инде», – ди, ул вакытларны артык исенә



төшерергә теләмичә. Яшәлгән... Әмма ул гомер балалар хакына яшәлгән бит! Кызларына менә дигән тәрбия биргән. Илүзәсе Урта Балтай участок хастаханәсе каршында эшләп килүче гериатрия бүлегендә – шәфкать туташы, Зиләсе мәктәптә укый. Әни булмагач, кызлар бик иртә мөстәкыйль тормышка өйрәнә. Җитәкче урында эшләгән әтиләренең хәленә керәләр. «Игътибар да җитеп бетмәгәндер инде. Әни тәрбиясен беркем алыштыра алмый. Әти кеше баланы ашата, киендерә. Моннан ары башканы бирә дә алмый», – ди ул. Әти тагын наз бирә әле ул. Әти назы, әтинең игътибары кызлар өчен аеруча мөһим. «Ярдәм итүче кешегез дә булмаган, нишләп өйләнергә уйламадыгыз соң?» – дип сорыйм җайлап кына. «Бәлки, өйләнәсе дә калгандыр... Әмма хатын белән балалар арасында йөреп өзгәләнермен дип уйладым», – ди ул. Илфир өчен дә бизмәндә балалар ягы баса.

Җәмгыятьтә менә шушындый әтиләр барлыгын да онытмау, аларны хөрмәтләү зарурдыр, мөгаен. Әни – кайгырту, җылылык, наз һәм мәхәббәт булса, әти – саклау, көч, тотрыклылык. Әлеге әтиләр әни миссияен дә, әти миссиясен дә башкара. Ирләре турында: «Бала тәрбияли беләмени соң ул, әле аның үзен карарга кирәк», дигән кайбер хатын-кызлар өчен әлеге әтиләр үрнәк булып тора. Ышаныгыз, тормыш барысына да өйрәтә. Хатын-кызларга ирләренә бары тик мөмкинлек бирергә генә кирәк. Онытмасак иде: бала әти өчен дә бала ул. Ул – мөстәкыйль булырга, карарлар кабул итәргә, кылган гамәлләр өчен җавап бирергә өйрәтүче. Балалар үз борчулары белән әнигә киләдер, мөгаен, ә әтигә алар билгеле бер ярдәм сорап, проблемалардан чыгу юлларын эзләп мөрәҗәгать итә. Шуңа күрә дә гаиләдә ирне бары тик керем чыганагы йә алтын куллы оста итеп кенә кабул итү тамырдан дөрес түгел, бала тәрбияләгәндә әтиләрнең өлеше үтә дә мөһим.

Фотолар: гаилә архивыннан.



Солтания ГАТАУЛЛИНА,
психолог

Әти кеше дөньяви эшләр белән мәшгуль. Шуңа да баланы тәрбияләгәндә күп мәшәкать әниләр өстенә төшә. Ләкин балага әтиләр тәрбиясе дә бик мөһим. Аның назына малайлар да, кызлар да бер үк дәрәҗәдә мохтаҗ. Әти мәхәббәтенә төренеп үскән балалар бәхетле һәм үз максатларына ирешүчән. Ул бала өчен якын кеше генә түгел, ә чын ир үрнәге, төп ышаныч һәм терәк, дисциплина һәм тәртип күрсәткече. Күз алдына китерегез әле, балалар бакчасында хатын-кызлар тәрбия бирә, мәктәпләрдә укытучы апалар эшли, шулай итеп, бу хатын-кыз эше дип, әтиләр икенче планга кала кебек. Гаиләдә әти кешегә аерым игътибар бирелү мөһим. Әниләр аларны гаепләргә ашыкмасын иде. Әтилек хисләре әниләрнекенә караганда, соңрак килә. Һәм ир-атның бала тәрбияләүдә катнашуын хатын-кыз үзе дә хәл итә. Ирегездән сезгә бала карашуын сорагыз. Нәкъ шулай – сорагыз, таләп итмәгез, тавыш күтәрмәгез, ачуланышмагыз. Заманча җәмгыять акрынлап бала тәрбияләүдә әтинең роле акча табу белән генә чикләнмәвен аңлый башлады. Әни бирә алмаган тәрбияне әти кеше бирә ала. «Күпме мәктәпләр, институтлар, университетлар булуга карамастан, яхшы әтидән башка яхшы тәрбияле балалар да була алмый», – дип язган Николай Карамзин. Әти баланың үзбәясен формалаштырырга ярдәм итә. Кагыйдә буларак, ир-атлар баланы азрак иркәләве аша аларны мөстәкыйль булырга, дисциплинага өйрәтә.

Малай кешене тәрбияләүдә, сүз дә юк, әтинең роле бик зур. Чөнки бу очракта бала әтисенең гаиләгә, яраткан хатынына, дусларына, балаларына карата мөнәсәбәтен үрнәк итеп алачак. Әтисен күзәтеп, малайлар аның кыланышларын, хәрәкәтләрен, сүзләрен кабатлый. Егет кеше җаваплылык, хатын-кызга карата яхшы мөнәсәбәт кебек күп кенә уңай сыйфатларны әтисеннән ала. Аның өчен әти дуслыгы аеруча мөһим..

Үз әтиләрен күрми торган малайлар мәктәпне дүрт тапкырга күбрәк ташлый, андыйлар алкоголь, наркотикише яман гадәтләрне дә тиз үз итә, хокук бозулар, психик тайпылышлар да килеп чыгарга мөмкин. Бала үзен ялгыз тоймасын өчен, аңа, ким дигәндә, 15 минут вакыт бирү – ата назын тоярга ярдәм итә. Әтиләре белән файдалы итеп вакыт үткәргән малайларның телгә оста булуы, шулай ук математикадан да сәләтле булуы исбатланган.

Кыз бала булачак тормыш иптәшен әтисенә охшатып сайлаячак. Ул әтисенә карагач, ир-атны чын ир-ат итә торган сыйфатларны күрергә тиеш. Кыз баланы әни кеше тәрбияләргә тиеш дип уйлау – шулай ук ялгыш фикер. Нәкъ менә әти кыз балада наз сыйфатларын тәрбияли дә. Әти белән үзеңне хан кызы итеп тою да күпкә җиңелрәк бит!

Кызыгызга комплиментларны кызганмагыз. Шулай итеп, аның уңай үзбәясе барлыкка килә. Һәрвакыт кисәтү ясап тору, кимчелекләрен ассызыклау анда негатив хисләр уятачак. Сүз дә юк, гел мактап кына торырга ярамый. Кызлар әтиләрен җирдәге иң көчле кеше дип саный, шуңа күрә алар үзләрен нык сак астында итеп тоя. Баһадир гәүдәле ир-атларның кызының кечкенә генә кулларыннан җитәкләп баруы нинди матур күренеш бит! Кызы белән курчаклы уйнарга яки йомшак аюын йокларга яткырырга һәр әти дә сәләтле түгел.

Әти белән кыз мөнәсәбәте бик иртә формалаша. Бәләкәй ханбикәгез үзен иң яраткан кыз итеп тойсын өчен, әтиләргә берничә киңәшне истә тотарга кирәк. Беренчедән, кызыгызның әнисен яратыгыз! Гомумән, бу – бала тәрбияләүдә төп кагыйдә! Шушы очракта гына кызыгыз үзе өчен дә шундый ук гомер юлдашы эзләр. Кызыгыз белән серләшегез, бүләкләр, чәчәкләр бүләк итегез, иркәләүдән курыкмагыз. Балачакта тиешле дәрәҗәдә яратылган балалар аралашучан, ачык, ярдәмчел булып үсә. Андыйлар йөрәгендәге мәхәббәт хисе якыннарга да, туганнарга да, дусларга да җитәчәк һәм ул сезгә әйләнеп кайтачак.

СӘЯСӘТТӘ ДӘ, ГАИЛӘДӘ ДӘ ИХЛАСЛЫК КИРӘК



Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Зилә ВӘЛИЕВАның тормыш кагыйдәләре

Мин өй тәрбиясендә үскән бала. Әти-әниләр һәрвакыт эштә, мәктәпкә кадәр күбесенчә әбием карамагында булдым. Ул вакытта без гел татарча сөйләшә идек. Мәктәптә рус телен үзләштердем. Кирәк чакта немец телендә сөйләшә алам. Инглиз теле буенча да берникадәр күнекмәләрем бар. Ләкин телне яхшы белер өчен даими шөгыльләнергә кирәк, моның өчен вакыт җитми дибез. Минемчә, мохит кирәк, аралашу, туган телне куллану җитми. Бала чакта ата-ана телен белә идем, хәзер онытттым дип йөрүчеләргә ышанмыйм. Миңа калса, балачакта сөйләшкән тел – ул компьютердагы файл кебек: аны хәтер төпкеленнән алып була. **КЕШЕГӘ БАЛАЧАКТА НИКАДӘР КҮБРӘК ТӘРБИЯ, КҮНЕКМӘЛӘР, БЕЛЕМНӘР САЛЫНСА, ШУЛКАДӘР ЯХШЫРАК.**

Дөньядагы алты мең телнең яртысы якын киләчәктә соңгы вәкилен югалтырга мөмкин. Шуңа күрә туган телне саклау өчен эшләнгән һәр гамәлнең мәгънәсе бар. Үзебезнең халыкка гына хас булган сүз бар – татар моңы. Ул татарның бөтен асылын аңлата. **ТЕЛ ЯШӘГӘНДӘ ХАЛЫКНЫҢ АСЫЛЫ, МОҢЫ КАЛА.** Көн саен яңалык ачу, тырышлыкның нәтиҗәсен күрү ошый миңа.

Хезмәткә күнегү, белемгә тартылу белән дә шул ук хәл. 9 нчы класста укыганда мәктәп идәнен юып эшләгән акчабызга кышкы каникулда Ленинградка барган идек. Узышлый, башкалада туктап, «Воробьёвы горы»га күтәрелгәч, Мәскәү университетының күккә ашкан мәһабәт бинасыннан күземне ала алмый сокланып басып тордым. «Мин шушында укыячакмын!» – дип, күңелемә беркеттем. **ГОМЕРЕҢ ЗАЯГА УЗМАСЫН ДИСӘҢ, ҮЗЕҢӘ ИРЕШЕП БУЛМАСТАЙ ТОЕЛГАН БИЕКЛЕК БИЛГЕЛӘРГӘ КИРӘК!**

БАЛАЧАКТА, ЯШЬЛЕКТӘ ХЫЯЛ КАНАТЛАРЫНДА ОЧУ – ТАБИГЫЙ ХӘЛ. Без барыбыз да – СССРның хоккей җыелма командасы җанатарлары идек! Ә менә классташыбыз Валера фанатның да фанаты. Аңарда җыелып матч карыйбыз, Валера – хоккейчылар киемендә, кәшәкә таягы белән идәнгә бәреп-бәреп ала, хәлиткеч мизгелләрдә сикереп торып: «Анатолий Иванович, чыгарыгыз!» – дип кычкырып җибәрә...» Анатолий Иванович СССР җыелма командасы тренеры Тарасов була инде. Фанат егетебез турында язмый булдыра алмадым... «23 нче уенчы» дигән юморескам мине журналистикага китерде.

Мәктәп укытучыларым үземә булган ышанычны үстерде, кыенлыклардан куркып калмаска өйрәтте. Соңрак Мәскәүдә университет корифейлары, дәреслекләр язган галимнәр белән аралашу шулай ук күп нәрсә бирде. Гомумән, үрнәк алырга, аларга тигезләнергә теләгән кешеләр күп булды тормышымда. Журналист булып эшләгәндә кайларга гына барырга, кемнәр белән генә аралашырга туры килмәде! Хирурглар белән операцияләрдә янәшә басып тордым, летчиклар кабинасында штурвал артында самолетта очтым. Үз эшләрен яратулары, профессиональлыклары сокландырды мине. **УҢЫШКА ИРЕШКӘН КЕШЕЛӘР ҮРНӘГЕ ҺӘРЧАК ЗУР ЭШЛӘРГӘ ЭТӘРГЕЧ БИРӘ. АЛАРГА КАРАП ҮЗ ЯЗМЫШЫҢНЫ ҮЗЕҢ ХӘЛ ИТӘ АЛУЫҢА ИНАНАСЫҢ.** Анатолий Аграновский сүзләре белән әйткәндә, «яхшы яза белгән түгел, яхшы уйлый белгән әйбәт яза». Ә уйлый белү – минем һәр эшемдә иң кирәклесе иде.

БАРЛЫК ГЛОБАЛЬ ВАКЫЙГАЛАРНЫҢ ҮЗ НЕЧКӘЛЕКЛӘРЕ БУЛА, ШУНДА КАЙНАГАН КЕШЕ ГЕНӘ АНЫ ДӨРЕС ИТЕП БӘЯН ИТӘ АЛА. Ул вакыйгалар кызыклы да, шул ук вакытта сабак бирерлек гыйбрәтле дә. Бөек үзгәрешләр чоры барлык кешеләр язмышында да чагылыш тапты. Мине, яшьли газетага эшкә кереп, иҗтимагый эшләрдә бераз тәҗрибә туплаган журналистны, шул сәяси күтәрелеш елларында республика парламентына депутат итеп сайладылар. Язмышым текә борылыш алды, җаваплылык бермә-бер артты. Ике ел дәвамында депутатлык мандаты булган парламент хәбәрчесе булып эшләгәч, парламент рәисенең беренче урынбасары итеп сайладылар. Заманы да, җитәкчеләр дә, коллегалар да шундый булгандыр, бу үзгәрешләр беркемне гаҗәпләндермәде.

СӘЯСӘТ – ХАТЫН-КЫЗЛАРГА КЕРҮ ТЫЕЛГАН ИРЛӘР МУНЧАСЫ ТҮГЕЛ. Талантлы, акыллы, зирәк, харизмалы, лидерлык сыйфатларына ия хатын-кызларыбыз бүген инде даими зур эшләре белән моны исбатлый!

Карьера минем өчен беркайчан да үзмаксат булмады, һәм аңлы рәвештә аңа омтылмадым да. Үз эшеңне җиренә җиткереп башкарырга, үз урыныңда кирәкле белгеч булырга кирәк. Һәр кеше теләсә нинди вазыйфада үзен күрсәтә ала. Ләкин **БЕР ГЕНӘ ШӘП КАРЬЕРА ДА ШӘХСИ ТОРМЫШТАГЫ БӘХЕТНЕ АЛЫШТЫРА АЛМЫЙ.** Хатын-кыз мәхәббәтне дә, ана булу бәхетен дә татырга тиеш. Ул дөньяны кабул итү чикләрен киңәйтә, әйләнә-тирәңә башкача карарга ярдәм итә.

Безнең эш алымнарыбыз, максатларыбыз кешелеклелеккә нигезләнгән. Бигрәк тә өлкәннәргә, хатын-кызларга уңай мөнәсәбәт кирәк. **ИР-АТЛАР ХАТЫН-КЫЗЛАР БЕЛӘН ИСӘПЛӘШМӘСӘ, ГАИЛӘСЕ – ГАИЛӘ, ДӘҮЛӘТЕ ДӘҮЛӘТ ТҮГЕЛ ИНДЕ АНЫҢ.**

ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ БАЛАЛАРГА МӨНӘСӘБӘТЕННӘН ЧЫГЫП, ШУЛ ҖӘМГЫЯТЬ ТУРЫНДА ФИКЕР ЙӨРТЕП БУЛА, диләр. Килешәм. Тикмәгә генә малайларны тәрбияләү – ир-егет тәрбияләү, кызларны тәрбияләү – милләтне тәрбияләү ул, дип әйтмиләр.

Бала чакта уңган килен булырга хыяллана идем. Без ул чакта ике катлы баракта яшәдек. Бар җыенысы ун гаилә. Шимбә саен ишегалдыбызга туй машиналары килеп туктый да, без – бала-чагаларга конфет-печеньелар чәчәләр. Мин килен булып төшкән кызлардан күземне алалмыйм! Икенче көнне үк алар бүлмәсе ишек төбендә (фатирлар юк) чип-чиста идән келәме җәелә, тәрәзәгә яңа челтәр-пәрдәләр эленә. Яшь киленнәрнең идәнне ничек кырып юуларын, ишегалдына аркылы баулар сузып,

Фото: Алсу Шакирова

хуш исле ап-ак керләр элүен карап торырга яратам. Мин 1 нче класска барганчы ук болдырларны кырып юа идем. Әти, әни, без өч кыз, әби, туганнан туганнар, кардәшләр, абыйлар, апалар... Кайберләре авылдан Уфага укырга килеп бездә яши. Кемнәрдер дәваланырга килә. Башка йомыш белән тукталучылар да бар. Кыскасы, ишле бер гаилә. Барыбызга да рәхәт. **ИШЛЕ ГАИЛӘДӘ ҮСКӘННӘР ТУГАН ҖАНЛЫ, КИҢ КҮҢЕЛЛЕ БУЛА.** Мин әле хәзер дә өйдә ялгызым гына калырга яратмыйм.

Кухняда вакыт бик тиз үтә ул. Бөтен хатын-кызлар өчен дә бик мөһим минутлар бу. **ҺӨНӘРИ ВАЗЫЙФАЛАРЫҢ АШ-СУ БҮЛМӘСЕННӘН НИКАДӘР ГЕНӘ ЕРАК КИТМӘСЕН, ХАТЫН-КЫЗДА ҮЗ ГАИЛӘСЕН ТАБЫНГА ҖЫЮ ТЕЛӘГЕ МӘҢГЕ БЕТМИ.**

ӨЙ ҖЫЛЫСЫН САКЛАП, БАЛАЛАР ҮСТЕРЕП, АЛАРГА ТӘРБИЯ БИРЕП КЕНӘ ЯШӘҮ ДӘ – ХАТЫН-КЫЗ ӨЧЕН ЗУР ХЕЗМӘТ. Аларның шуның белән генә чикләнергә дә хаклары бар. Ә бүгенгеләр барысын да булдыра.

Диплом җитәкчем атаклы журналист Валерий Аграновский: «Журналистикада, редакциядә начальниклар булмый. Кем иң шәп мәкалә язган, шул – көн герое», – дип тәрбияли иде. Бүлек редакторы, баш редактор дигән вазыйфаларга бер дә кызыкмадым. Миңа яшьтән үк шул әйберне сеңдерделәр. **СИНЕҢ ТУРЫДА ШӘП ЯЗА ТОРГАН ЖУРНАЛИСТ ДИСӘЛӘР, ГОРУРЛАНСАҢ ДА БУЛА.**

ЖУРНАЛИСТИКА – ҮЗЕ ҮК СӘЯСИ ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ БЕР ТӨРЕ УЛ. Син җәмәгатьчелек фикере, гражданлык җәмгыяте белән эшлисең. Яхшы журналистның сәяси йогынтысы югары урындагы түрәнекеннән ким түгел.

1995 елда Михаил Горбачёв Россия Президенты сайлавында катнашты. Ул СССР җитәкчесе чакта Мәскәүнең съездлар сараенда «тотып» алып интервью да алганым бар. Бу юлы миңа рәсми вазыйфа эләктте – кандидатны Казанда озатып йөрүне ышанып тапшырдылар. Мин ул вакытта Дәүләт Советы Рәисенең беренче урынбасары идем. Ирле-хатынлы Горбачёвлар белән ике көн эшләдем, кичен кунакханәгә озата бардым. Раиса Максимовна ял итәргә кереп китте, ә без Михаил Сергеевич белән иртәнге дүрткә кадәр сөйләшеп утырдык. Иң зур илнең башлыгы булган кеше белән нәрсә турында сөйләшергә мөмкин, дисездер? Без... мәхәббәт турында сөйләштек. **«ТОРМЫШТА ИҢ МӨҺИМЕ – ҮЗ ТИҢЕҢНЕ ТАБУ ИКӘН!** Бу иң зур бәхет. Бу яктан мин бик бәхетле», – дигән иде Михаил Сергеевич. Ул чыннан да хатынына табынып яшәгән ир. Моның өчен Горбачёвны яратмаучылар бар. Шәхсән миндә ул хөрмәт кенә уята.

Гаилә корып, балалар үстерүче ир белән хатынның ихласлыгы, якынлыгы, бер-берсенә ихтирамы – дөньякүләм әһәмиятле күренеш. **ДӘҮЛӘТ ЭШЛӘРЕНДӘ ДӘ, ГАИЛӘДӘ ДӘ ЫШАНЫЧ ЗУР ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ. БУ ЫШАНЫЧНЫ КАКШАТЫП ҖИБӘРЕРЛЕК КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ СӘБӘП ТӘ БУЛМАСКА ТИЕШ.** Иремнән – журналист, җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиевтән – гаилә тормышы турында сораганда: «Бездә барысы да әйбәт, без икебез дә бер кешене – Зиләне яратабыз», – дип шаяртып җавап бирә иде. Озын-озак гаилә тормышыбыз уңаеннан тагын шундый фикере бар – чынлыкта, бер-беребез турында башта уйлаганга караганда, без яхшырак та булып чыктык, ди ул.

Һәр көнем сәгатьләп бүленгән. Ничек кенә теләсәм дә, шәхси тормышка вакыт гел аз кала. Әмма **ГАИЛӘБЕЗНЕҢ ЯЛ КӨННӘРЕНДӘГЕ КӨНДЕЗГЕ АШЫ – МИНЕМ ӨЧЕН ИЗГЕ ӘЙБЕР.** Якын кешеләрем – улым, оныкларым, туганнарым белән аралашу көч бирә миңа. Гаиләм, якыннарым катлаулы дәүләт, җәмгыять эшләрен башкарырга ярдәм итеп торды. Алар минем зур эшләрдә катнашуым белән горурлана. Шуның белән мин дә алар алдында җаваплылык тоям.

Дәүләт Советында эшем тәгәлләнгәннән соң, мин матбугат һәм мәгълүмат министры, аннан соң мәдәният министры булдым. Ул чакта рухи азыкны акча эшләүгә әйләндерү өстенлекле бурыч түгел иде әле. Ачыктан-ачык ялганга корылган заказлы мәкаләләр, тапшырулар, сәнгать әсәрләре беркемгә дә кирәк түгел, бу мәсьәләдә фикерем катгый. Чөнки газета укучылар һәм тамашачылар ялганны һәрвакыт сизә. Сәясәтне, дәүләтне пычрату очраклары бардыр дөньяда. Ләкин халык дәүләткә ышанырга тели, аның башка өмете юк. **ГАДЕЛЛЕККӘ, ДӨРЕСЛЕККӘ ҺӘРВАКЫТ ИХТЫЯҖ БУЛЫР ДИП УЙЛЫЙМ. СӘЯСӘТТӘ, ДӘҮЛӘТ ЭШЛӘРЕНДӘ ДӘ, ГАИЛӘДӘ ДӘ ИХЛАСЛЫК КИРӘК ДИП САНЫЙМ.**

Кешегә гомер буе сайлау мөмкинлеге бирелә. Болай да эшли ала, тегеләй дә гамәл кылырга мөмкин. Әйе, бер кеше барысын да үзгәртә алмый, ләкин үз урынында гына булса да бу һөнәрнең дәрәҗәсен, хөрмәтен саклап калуны булдыра ала. **ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ КАЙНАР, АВЫРТКАН УРЫНЫН СИЗЕП-ТОТЫП АЛА БЕЛЕРГӘ КИРӘК.**

30 еллап хакимият даирәсендә булдым. Хәзер иҗтимагый оешмалар казанында кайныйм. Бу өлкәләрне берләштерә торган нәрсәләр күп. Миңа калса, һәркем матурлыкны һәм хакыйкатьне күрергә тели. **ТОРМЫШНЫ СЫЛАП-БИЗӘП КҮРСӘТҮ БЕРКЕМГӘ ДӘ КИРӘКМИ, ЧЫНБАРЛЫКНЫ НИЧЕК БАР, ШУЛАЙ ТАСВИРЛАУ МӨҺИМ.** Кем генә булмасын: баламы ул, синең укытучыңмы, зур җитәкчеме – алар алдында үзеңә йөкләнгән ышанычны акларга кирәк.

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.

РЕДАКЦИЯДӘН: Зилә Рәхимҗан кызы ВӘЛИЕВАны – Татарстан Республикасындагы затлы, зыялы, зирәк, тәвәккәл, һәрчак иҗадилыкка, камиллеккә, яңалыкка омтылучы шәхесне, танылган хатын-кыз сәясәтчене – журналыбыз укучылары исеменнән күркәм юбилее белән котлыйбыз! Тынгысыз дөньясын күңелле мәшәкатьләр бизәсен! Сәламәтлек, яңа уңышлар, яңа җиңүләр телибез!

«СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫНА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

Җылы сүз... Аның кешегә кирәк булмаган чагы юк бугай. Хәтта үзен бик көчле санаганнарга да. Җылы сүз – җан азыгы, ди халкыбыз...

«Сөембикә» журналы гомер-гомергә үзенең язмалары аша меңләгән укучысына җылы сүз өләште. Иң кирәк вакытта – төпле киңәш бирде. Күпләр өчен иң ышанычлы бер терәк булды.

Аңлаучы. Яклаучы. Якын итүче. Әйе, хатын-кыз хатын-кызны һәрвакыт яхшырак аңлый!

Җаныгызга җылы эзләп сез бүген дә «Сөембикә»не кулыгызга ала аласыз. Матур мизгелләр алып килсен, сөендерсен әле, дип, журналны иң якын кешеләрегезгә бүләк итә аласыз. Әниләр көненә – әниләрегезгә!

Күңелгә рәхәтлек биргән мизгелләр бүләк итүдән дә зуррак бүләк була алмый...

ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМАГЫЗ

1. «Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча
2. Татарстанлылар өчен бер елга индекс – **П8299**

   Ярты елга индекс – **П2204**
3. Республикадан читтә яшәүчеләр өчен индекс – **П0279**

РЕДАКЦИЯДӘ
Килеп алу шарты белән ярты елга язылу бәясе – **360 сум.**
Теләсә кайсы айдан язылырга мөмкин.

Яртыеллыкка язылырга өлгерми калучылар һәр айның 15 нә кадәр язылып, журналны киләсе айдан алдыра ала.

Хәзер «Сөембикә» журналын Wildberries, Kazan Express, Ozon, «Татмедиа» онлайн кибетеннән дә сатып алырга була.



БЕЗНЕ УКЫГЫЗ
Сайтта: **www.syuyumbike.ru**
ВКонтактеда: **vk.com/suumbike**

16+ РЕКЛАМА

«СИН БУЛДЫРАСЫҢ, КЫЗЫМ!»



Руфия РӘХМӘТУЛЛИНА

1 сентябрь иртәсе. Алинә дулкынланып йокысыннан уяна. Кичә әнисе шикәрле су белән чәченә кәгазь чорнады бит, димәк, аның толымнары матур булып бөдрәләнеп торачак. Әйе, бөдрә толымнарны үлеп ярата ул. Хыялы – бер генә тапкыр булса да шулай мәктәпкә бару. Караватыннан торып көзге каршына килә, кәгазьне сүтә һәм... матур толымнарның эзе дә юк. Шикәрле су белән каткан чәчен күреп, Алинәнең күзләре яшьләнә. Аларны ни тарап булмый, ни җыеп. Бу аның иң күңелсез 1 сентябрь иртәсе була. Нәкъ шул көнне ул күңел дәфтәренә язып куя: «Үскәч, көн саен матур итеп чәчемне бөдрәләтәчәкмен». Әлбәттә, үсмерлек чорына кереп баручы кызның иң риясыз хыялы була бу. Шулай да... Казан кызы Алинә Хәмидуллинаның хыялы тормышка ашкан: бүген ул «Сөембикә» матурлык салонын җитәкли, димәк, көн саен чәчен бөдрәләтеп йөри ала. Ләкин хәзер инде ул бүтән максатлар, бүтән уй-хыяллар белән яши: яхшы кардиолог булырга хыялланган кыз – КФУның фундаменталь медицина факультеты студенты.

«Укучылар белән шөгыльләнгән вакытларны сагынам»

Алинә университетның беренче курсында укыганда ук эшли башлый – унберенче сыйныф укучыларын химия, биология фәннәре буенча БДИга әзерли. Бер елдан инде үзенең мәктәбен ача.

– Әнигә рәхмәт, миңа гел терәк булды, репетиторларга йөртте, – ди Алинә. – Шуңа күрә бу өлкәне яхшы өйрәндем: репетиторларга ихтыяҗ зур бит. КФУга укырга кергәч тә, унберенчедә укучы бер кызны химиядән БДИга әзерли башладым. Ул кыз дустын алып килде. Әнә шулай ике укучым барлыкка килде. Яңа йөри башлаган кызга: «Сиңа атнасына ким дигәндә ике тапкыр килергә кирәк, юкса БДИны югары баллга бирә алмаячаксың», – дидем. «Безнең түләргә акча юк», – дигән сүзләрен ишеткәч, әллә ничек кыен булып китте, кызгандым мин аны. «Өч кеше алып килсәң, синең белән бушка шөгыльләнәм», – дип тынычландырдым. Ике көн дә узмады – сыйныфташларын ияртеп килде. Ел азагына кадәр алар белән шөгыльләндем. Иң сөенечлесе – ул балаларның барысы да имтиханда югары балл җыеп, үзләре теләгән уку йортларына керделәр.

«Ватык телефон» яхшы эшли: икенче елны Алинәдә БДИга әзерләнергә теләүче егет-кызлар саны дистәдән артып китә. Һәм ул дусты белән бер бина арендалап, шунда дәресләр үткәрә башлый.

– Укыту эшен шундый яраттым! – ди Алинә илһамланып. – Укучылар белән аралашу, аларның сорауларына җавап бирү гаҗәп дәрәҗәдә мавыктыргыч тоелды. Беләсезме, хәтта үземнең методикамны булдырдым мин. Тәҗрибә күрсәткәнчә, химиядән БДИ ел саен катлаулана, олимпиада биремнәре арта бара бит әле. Шуңа күбрәк һаман шул олимпиада биремнәрен чишә идек. Минем бит педагогик белемем юк, биремнәрне үзем ничек аңлыйм, шулай аңлаттым. Һәм бу алым бик яхшы булып чыкты.

Пандемия башлангач, Алинә укучыларын онлайн укытуга күчерә. Ләкин зур дәрт белән башлаган эш шул уку елында тукталып та кала. Репетитор кыз анысын болай аңлата:

– Укучылар белән күзгә-күз карап эшләмәгәч, күңел сүрелде. Баланың аңлаганмы, юкмы, сине дикъкатъ белән тыңлыймы, юкмы икәнен экран аркылы күреп булмый бит. Аннары әти-әниләр алдында да җаваплылык тоясың: күпме акча түләп ул баласын синең яныңа җибәрә. Нәтиҗәсе булмаса, эшләп торуның кирәге юк дип саныйм. Әйтәм бит, бу бик җаваплы эш.

БДИга әзерләүдән туктауның тагын бер сәбәбе – Алинәнең укуга вакыты җитми башлый. Беренче, икенче курсларда әле мәктәптә өйрәнгән база белемнәре буенча барса, алга таба уку катлауланганнан-катлаулана.

– Укучылар белән шөгыльләнгән вакытларны әле дә сагынам, – ди әңгәмәдәшем. – Алар белән кызык, ниндидер шәп энергетика килә үзләреннән... *(Хыялга бирелеп.)* Кем белә, бәлки, кайчан да булса кабат бу юнәлешкә әйләнеп кайтырмын әле. Медицина буенча югары белем алгач, студентлар белән дә эшләргә була.

Яшьләр килә, юл бирегез!

Кыю яшьләр үсте. Алар белемле, заманча. Киенү, яшәү рәвеше, дөньяга карашлары белән дә аерылып торалар. Ләкин мине иң гаҗәпләндергәне – үз-үзләренә булган ышаныч.



Фото: Анна Арахамия



«Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кулыннан бүләк алу – үзе бер мәртәбә!»



Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов белән.

Без университет тәмамлагач, кыяр-кыймас кына редакция ишеген ачып кергән булсак, алар – бөтенләй башка! Килеп тә керәләр, синең белән иркенләп сөйләшә дә башлыйлар. Алинә дә шундыйлардан. Күпләрнең башына да килмәгән идеяләрне ул инде тормышка да ашырган. Мондый кыюлык кайдан килгән соң аңа?

– Кечкенә чагымда әни мине нинди генә конкурсларга йөртмәде! – дип искә төшерә Алинә. – Җиңмәсәң дә, алар сиңа үсәргә ярдәм итә. Үз-үзеңә ышаныч арта, кешеләр белән танышасың, аралашасың. Монда да әниемнең йогынтысы зур булды: «Син булдырасың, кызым!» – дип, мине гел үсендереп торды. Җиденче сыйныфны тәмамлагач, «Сәләт»кә килдем. Һәм шуннан башланды инде...

Республика күләмендә нинди иҗади, интеллектуль конкурслар бар, Алинә барысында да катнашкан, миңа калса. Республика яшьләр форумнары оештырырга булышкан. Парламент дебатларында җиңүләр яулаган. 19 яшендә «ПолитЗавод» республика иҗтимагый-сәяси проекты җиңүчесе булган. Саный китсәңме... Мәскәү, Санк-Петербургларга барып та төрле форумнарда проектлар яклаган, иң яхшылар исемлегенә кергән. Быел җәен исә Президент академиясе актив яшьләр өчен оештырган бик дәрәҗәле чарада – белем форумында катнашып җиңү яулаган. Әнә нинди кыз бит ул!

– «ПолитЗавод»та катнашу өчен 1000 гариза кабул ителгән иде, шулар арасыннан 357 егет-кызны сайлап алдылар. Проект кысаларында без депутатлар белән аралаштык, сәяси темаларга чыгышлар ясадык, лидерлык сыйфатларын үстерү өстендә эшләдек. Шул чакта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән якыннан аралашу бәхете дә тәтеде. Акыллы, заманча яшьләр арасында беренчелекне яулау минем өчен зур җиңү булды.

Алинәне тыңлап, кызны җиңүгә илткән сыйфатларны барлыйм. Кечкенәдән үҗәт булуы да үзенекен иткән, минемчә. Менә бер генә мисал. Алтынчы сыйныфны тәмамлагач, ул Казанның 4 нче кызлар гимназия-интернатына керү өчен имтиханнар тапшыра. Ул чагындагы татар-төрек лицее бу. Сынауларны уңышлы узса да, өстенлек районнардан килгән балаларга бирелә икән. Кабул итү комиссиясе каршысына яңадан кергәч: «Абыйлар, апалар, мине укырга алсагыз, бер дә үкенмәссез. Мин бик күп шигырьләр беләм», – дип әйтә дә бөтен аудиторияне таң калдырып, Габдулла Тукайның «Туган авылым» шигырен сөйли башлый. Мөгаллимнәр мондый кыю кызны күреп шакката. Ә Алинә ул көнне имтиханнан татар-төрек лицее укучысы булып кайтып китә. Кыз сүзендә тора: татарча, төрекчә укып, дистәләгән конкурсларда җиңү яулый! Лицейның йолдызы булып кабына!

– Шигырьләр хәзер дә сөйләргә яратам, – ди Алинә. – Хобби бу минем. Укыган кайбер шигырьләремне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның социаль челтәрләренә дә куялар. Күңел була инде. *(Көлә.)*

Матурлык «Сөембикә»дән башлана!

Алда әйткәнемчә, Алинә бүген матурлык салоны җитәкчесе. Тиктормас тынгысыз студент кыз әнә шундый эш ачкан. Бер ел эчендә тәҗрибә туплап, бу өлкәне шактый өйрәнгән ул. Билгеле бер фикергә килеп, үзенчә яңалыклар керткән.

– Салонның исемен башта заманча яңгырашлы итеп, инглизчә атаган идем. Карыйм: гел татар апалары килә безгә. Башта ничектер яшьләрне җәлеп итәсем килгән иде. Ләкин яшь кызлар акция белән тырнак ясата да – вәссәлам! Ә менә кырыктан узган ханымнар үзләрен башкача тота: аларга затлы итеп чәчләрен дә кисәргә, килешле төскә буярга да кирәк. Массажга да керәләр. Салоныбызга бик зыялы кешеләр йөри, күбесе татарлар. Арада театр, сәхнә дөньясындагылар да байтак. Тукта, мин әйтәм, безнең клиентларга синең инглиз исемле салоның нигә ул – миллилеккә йөз тотарга кирәк. Эзләнә торгач, уйга иң беренче «Сөемби-

кә» исеме килде: горур, затлы, легендар. Әлбәттә, ул җаваплылык та сорый, исем җисемгә туры килергә тиеш бит. Бүген менә командабыз белән шул юнәлештә эшлибез. Визажист, чәч кисүче, тырнак ясаучы, массаж ясаучы – барысының да татар теле камил дәрәҗәдә. Клиент канәгать калсын өчен, бик тырышалар: матур итеп сөйләшәләр, һәркемгә игътибар күрсәтәләр.

Исем алмаштырып кына эш бетми, әлбәттә. Матурлык эзләп килүче гүзәл затларны салонда Сөембикә «каршы ала». Ханбикәнең купшы портреты иң түргә эленгән. Портретның авторы Эльмира Низамиева аны махсус ясаган. Авторның миллилек белән сугарылган бүтән эшләрен дә күрергә була биредә.

– Мондый үзгәреш даими клиентларыбыз күңеленә хуш килде, – дип аңлата Алинә. – Чынлап та, салонда ниндидер җылылык барлыкка килде. Шуннан соң янә бер фикер туды: килгән кеше халык җырларын тыңласын. Патефон алып кайтып куйдым. Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова пластинкаларын таптым. Бүген инде клиентлар төрле пластинкаларны үзләре бүләккә алып килә. «Сезгә килеп кергәч, чын татар рухын тоясың», – диләр. Инде аларның күбесе

Күпләрнең башына да килмәгән идеяләрне ул инде тормышка да ашырган.

белән дуслашып, туганлашып беттек. Һәркайсын чәкчәк, чәй белән сыйлыйбыз. Үзебезчә, татарча булсын дибез. (*Канәгать елмая.*)


– Алинә, матурлык салоны медицинага якын булса да, барыбер икенче юнәлеш. Табиб булып эшләү хыялы бармы? – дим.

– Әлбәттә, бар! Кардиолог буласым килә минем. Ординатураны шул юнәлештә дәвам итәргә планлаштырам. Табиб булу балачак хыялым бит. Әле беренче сыйныфта укыганда ук үземнең бүлмә ишегенә «Баш табиб Алинә Хәмидуллина» дип язып куйган идем. *(Көлә.)* Һәм шул хыялыма тугры калдым. Татар-төрек лицеенда сигезенче сыйныфка кадәр укыгач, химия, биологияне тирәнтен өйрәнергә дип, 116 нчы лицейга кердем. Төннәр буе БДИга әзерләнә идем. Киләчәктә медицина өлкәсендә яңа үрләр яуларга дигән максат белән яшим. Мисал өчен, күптән түгел генә МГИМО уздырган «Ныклы үсеш» форумында «Медицина – сәламәт тормыш» темасына чыгыш ясап, «Иң яхшы тема һәм делегат» исеменә лаек булдым. Заманча медицина клиникалары ачарга телим. Шул ук вакытта матурлык өлкәсендә дә эшне җәелдерәсем килә. Сез әйткәнчә, икесе бер юнәлеш бит.

...Бүген күп яшьләрдән татар теленигә кирәк дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Алинә исә тәгаен белә: тирән белемең һәм туган телең ярдәмендә зур уңышларга ирешергә мөмкин. Бу алымны ул күп тапкырлар сынаган: форумнарда чыгыш ясаганда татарча да сөйләп, бөтен аудиторияне үзенә караткан. Ике телне дә камил белүче Алинә янына ахырдан килеп, якыннан танышалар икән. Менә ни өчен аның танышлары, дуслары – бөтен җирдә!

– Россия күләмендәге бәйгеләрдә дә татарча шигырьләр сөйлим, безнең әдәбиятка мөрәҗәгать итәм. Һәм бу башка катнашучылардан бер өстенлегем булып тора. Күп җиңүләремнең сере шунда, – ди булачак табибә. – Әнинең «Син булдырасың, кызым!» дигән сүзләре миңа һәрвакыт көч бирә.





«Сөембикә» журналы укучылары өчен генә – салонда **500 сумлык ташлама!**

Адрес: **Чехов ур., 53.**
Контакт өчен телефон:
+7-917-223-09-66

РЕКЛАМА



«ИҢ АВЫРЫ – БАЛАГА ИРЕК БИРҮ»

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Рубрикабызның кунаклары – «ТАТМЕДИА» акционерлар җәмгыятенең генераль директоры Шамил САДЫЙКОВ һәм аның кызы ЗӨҺРӘ.

Зөһрә, кыз бала өчен әти беренче ир-ат идеалы. Аның мөнәсәбәте, кызының киләчәк тормышын билгели. Бу фикер белән килешәсеңме?

– Әйе, әлбәттә. Әти кеше иң элек ир-атларның нинди булырга тиешлеген күрсәтә. Әти белән кыз бала мөнәсәбәте тәрбиядә бик җитди һәм зур урын алып тора дип уйлыйм. Шуңа да әти игътибар күрсәтергә, сөйләшергә, бүләкләр бирергә, иркәләргә тиеш. Нәкъ минем әти кебек. Кыз кеше әти мәхәббәтендә, әти игътибарында коенып үссен инде ул. Безнең әти бик яхшы, бигрәк тә безгә кызларына. Аның яратуын тоеп яшибез. Ул аны күрсәтә дә белә: безне аңлый, кочаклап сөя.

Шуның кадәр яраткан атада көнләшү дигән сыйфат та булмый калмыйдыр. Бигрәк тә аралашу мохитендә егетләр барлыкка килә башлагач.

– *(Көлә.)* Ансыз булмый инде. Бу – нормаль күренеш дип уйлыйм. Алар безне тәрбияли, үстерә, ә монда таныш булмаган бер егет килеп чыга да, хәзер ул минеке дип белдерә. Әтиләр аңласын иде: кызлар һәрвакыт әти-әни канаты астында, алар контролендә яши алмый. Әти белән бу хакта сөйләшә башласак, ул шаяртырга тотына. Аның нигә шаяртуын да аңлыйм инде...

Минем әти барысын да аңлый, дисең. Шулай да аңа үпкәләгән чагың булдымы?

– Бер ел элек булды андый үпкәләшү. Бер егет белән аралаша башлагач, ул мине бергә йөреп кайтырга чакыра, дип әйттем әтигә. Әти сораштыра башлады. Рус егете булуы әтигә ошамады, билгеле. Мин ул егет белән барыбер очраштым. Әти ул вакытта үпкәләде кебек, хәтта миңа карата мөнәсәбәте салкынайды. Шуның өчен мин әтигә үпкәләдем. Аның шулай үзгәрүенә хәтерем калды.

Кем беренче дуслашты соң?

– Хәтерләмим инде. Әтидер, мөгаен. Ул мине бик ярата. Мин бит аның беренче кызы!

Быел син мәктәп тәмамлыйсың. Укы, имтиханнар тапшырасың бар, дип әйтәләрдер инде...

– Бу хакта әни белән сөйләшергә мөмкинбез. Әтинең сораштырып җәфалаганы юк. Ул бит җаваплы кеше икәнемне белә. Ышана дип уйлыйм. Билгеләремне дә карап бармыйлар. Мәктәптә болай да киеренке, өйдә дә һәрвакыт мәктәп, уку турында сөйләп торсалар, авыр булыр иде. Әти кечкенәдән үк һәр теләгемә теләктәшлек итте. Музыкага укыйсым килә, дидем – музыка мәктәбенә йөрттеләр. Дөрес, берничә елдан соң теләгем сүрелде. Әмма башлагансың икән, тәмамла, диде әти. Диплом алдым. Ул миңа кирәк тә түгел инде, әмма әти синең үсешең өчен кирәк ул, ди. Аннан соң сәнгать мәктәбенә керәсем килә, дидем. Әти балалар архитектура мәктәбенә алып барды. Имтиханнар биреп, анда укый башладым. Һәм киләчәк һөнәремне билгели алдым. Архитектор буласым килә. Мине мәҗбүриләүче булмады. Моның өчен рәхмәт аларга.

Әгәр дә әтиең фикере белән килешмәсәң... Бу очракта нишлисең?

– Мин кире. Әти дә кире. *(Хәйләкәр елмая.)* Гадәттә, мин ничек телим шулай була.

Димәк, әти барысын да аңлый, гафу итә дигән позициядә яшисең?

– Әйе!

Әтинең күзләренә карап әйтергә кыймаган фикерләр дә бар бит әле, аларны ничек җиткерәсең?

– Әти минем социаль челтәрләрне күзәтеп тора. Нәрсәдер әйтми калганны шулар аша әйтәм. Фотолар куйганда да уйлап куям. Кайчакта моны әтидән качырырга кирәктер дип тә уйлыйм.

Дөрес аңладыммы: куркасың, әмма куясың?

– Шәхси тормышыңны күрсәтмә, безнең һәм үзеңнең абруеңны төшерерлек сүзләр язма, фото куйма, ди әти. Әмма ул бит минем тормыш, мин инде – шәхес. Миңа тиздән 18 яшь. Нәрсә эшләргә ярый, нәрсә эшләргә ярамыйны үзем хәл итәргә тиешмен. Әти-әниләр таккан түгел, үземнең тормыш кыйммәтләремне табарга телим. Менә шул фикерләрне җиткерәсем килә.

Шулай да әтиеңнең сиңа шарт куйганы бармы?

– Булачак иремә карата бар. Нинди милләт кешесе булуы мөһим түгел, әмма ул мөселман булсын, ди. Сайлау алдында калам икән, әлбәттә, әтинең фикере өстен чыгачак. Егетләр күп ул, әти берәү генә. Егетләр бит сине нәрсәдер өчен ярата, ә әтиләр бары бу дөньяда булганың өчен.

Булачак ирең әтиең кебек булуын телисеңме?

– Әйе, әлбәттә.

Таба алырмын дип уйлыйсыңмы?

– Таптым бугай инде...

Шамил Мөхәммәтович, кыз бала тәрбияләү авырмы, малаймы?

– Уларны тәрбияләү авыр дип уйлый идем, юк, кызлар белән авыррак икән. Без шаблоннар, үрнәкләр буенча яшибез. Минем өчен әнием, хатыным, хатынымның әнисе – идеал. Шуларга карап кыз баланы тәрбияләү буенча программа төзү җайлы, әлбәттә. Әмма Зөһрәне алай тәрбияләп булмаячак, чөнки ул бөтенләй башка буын. Җитмәсә, кеше шундый зат – ул беркайчан да кеше хаталарында өйрәнә алмый. Аның үзенең хаталанып карыйсы килә. Бу бигрәк тә үсмерләрдә чагыла. Кирелекләре, үҗәтлекләре белән капма-каршы булырга тырышалар.

Сезнең өчен кыз бала тәрбияләүдә төп бурыч?

– Милли тәрбияле, татар җанлы булып үсү, татар кешесенә хас булган сыйфатларга туры килү. Татар халкы әдәплелек белән генә чикләнми, мәгърифәтле ул, яңалык, гыйлем эзли. Шәхси тормышында бәхете булса, үз һөнәрен, дөньяда үз урынын тапса гына кеше гармониядә яши ала. Һәм, әлбәттә, иманлы булу. Иман – ул эчке социаль иммунитет. Әгәр дә Аллаһы Тәгаләгә ышаныч булмаса, иммунитет булмый, иммунитет юк икән, чирлибез. Балаларга дөрес юлны күрсәтә белү – төп бурычыбыз. Бала тәрбияләгәндә иң авыры – аңа үз тормышында яшәргә мөмкинлек бирү.

Әти көнләшүе дигән нәрсә бар бит әле...

– Көнләшү бардыр инде ул... Әмма көнләшү микән соң ул?.. Балага мондый мөнәсәбәт бары тик хаталар ясамавын теләүдән генәдер. Минем алдымда сайлау: йә аның егылганын карап торырга, йә акыллы киңәш бирергә. Үзем әти-әни киңәшен тыңлап үстем. Әти миңа журналист буласың, диде. Әни хатын-кызлар турында дөрес күрсәтмә бирде. «Үз балаларыңа әни булырлык кеше табарга кирәк сиңа», – диде.

Димәк, сез әти-әни сүзен йөз процент тыңлап үскән үсмер?

– Сүз тыңлау түгел бу, ә дөрес тәрбия алу.

Ә хәзерге үсмерләр өчен дөнья бик киң. Алар алдында сүзең үтә алырлык абруйны ничек саклап калырга соң?

– Кеше үз баласын бәхетле итәргә тели икән, ул иң элек үз-үзен үзгәртеп тәрбияләргә тиеш. Үзебезнең тормыш белән аларга үрнәк күрсәтергә кирәк. Бу, бәлки, артык купшы сүзләрдер, ләкин мин 45 яшемә төрле психологик кичерешләр кичергән кеше. Үз өстемдә күп эшләргә туры килде. Тормышка яраклаша белергә кирәк. Балалар миңа килеп: «Әти, син үзең менә шундый бит», – дип әйтә алмыйлар. Идеаль булып яшәргә тырышам. Бала тәрбияләүдә иң көчле инструмент – ярату һәм үрнәк күрсәтү.

Әти кеше кыз бала тормышында беренче ир-ат идеалы. Әти кыз балага нәрсә бүләк итә?

– Үз үрнәгендә ир кеше нинди булырга тиешлекне күрсәтә. Әлбәттә, төрле хәлләр бар. Кечкенә вакытта Зөһрәне ныграк та «бөккәнмендер». Ләкин ул хәзер җиткән кыз, шәхес буларак формалашкан. Ниндидер ситуацияләрдә ул миңа караганда җитдирәк, акыллырак. Үз тормыш юлын табарга тырыша. Күрәм, эзләнә. Шуңа мин әйткән сүзләргә дә каршы килә. Ул конфликтларның чикләрне билгеләү икәнен дә аңлыйм.

Көннәрдән бер көнне Зөһрә, мин кияүгә чыгам, дип кайтса...

– Тормышта ир табу – бәхет эше. Син кемне генә сайласаң да, килешәчәкмен, чөнки мин сине яратам, дим аңар. Ләкин аңа гармонияле тормыш турында аңлатырга тырышам. Парлы булу, димәк, бертөрле фикерләү, бертөрле карашта яшәү, бертөрле диндә булу. Төрле диндәге кешеләр гаилә корса, зур проблемалар туа. Катнаш гаиләләрдәге балалар да төрле динне сайлый. Бу бит инде таркаулыкка китерә. Әлеге юлны сайлаган кеше, миңа калса, үз-үзенә дошман. Хатын-кызның бәхетле булуы 99 процент кияүгә дөрес итеп чыгуга бәйле.

Сез – дини кануннарны саклап яшәүче әти. Кызларыгызга яулык яптыру турында сүз булдымы?

– Ул адымны кеше үзе ясарга тиеш, үз ихтыяры белән. Кияүгә чыгып, тормышын көйли башлагач, ире белән бергәләп дингә килерләр дип өметләнәм. Без дә хатыным белән намазга бергәләп бастык.

Сез һәрвакыт телефонда. Зөһрә әйтүенчә, өйдә дә аннан аерылмыйсыз. Балаларга вакыт җитәме?

– Минем бернәрсәгә дә вакытым җитми, иртәнге җидедән алып, кичке тугызга кадәр эшлим. Үзеңә, гаиләңә вакытны бүлү идеаль вариант инде ул... Шушы телефонның зыянына караганда, файдасы күбрәк. Син һәрвакыт элемтәдә! Гаилә өчен дә! Көнне дә гаилә чатында бер-беребезгә хәерле иртәләр теләп башлыйбыз. Кем нәрсә ашый, кем кая бара – барысын да шуннан белеп, күреп торабыз. Көн дәвамында Зөһрә белән билгеле бер темалар буенча мессенджерлар аша фикерләшәбез. Балалар социаль челтәрләрен актив рәвештә алып бара. Бу дөрес әйбер дип саныйм. Социаль челтәрләр аркылы эчке дөньяларының торышын беләм. Аңлыйм: алар да миңа нәрсәдер әйтергә теләсәләр, социаль челтәрләр аркылы җиткерәләр. Бер-береңә месседж җиткерү мөһим. Бөтенесен дә кешенең күзенә карап әйтеп булмый, «кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла» дигән гыйбарә дә бар бит әле. Бала белән аралашу инструментлары төрле булсын ул.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Фото: Анна Арахамия

PRESSA



ЙӨРӘГЕҢНЕ ЙӨРӘГЕМӘ КУЯМ



Лилия
ГӘРӘЕВА

Тормышның гади генә бер манзарасын күз алдына китереп карагыз әле. Эштән соң кич кенә өегезгә кайтып кердегез. Анда гаиләгез, балаларыгыз һәм меңтөрле мәшәкатегез көтә. Иртәгәсе көнгә көч туплап, йокыгызны туйдырасы урынга, кемдер сезнең ярдәмгә мохтаҗ дип, төнгә каршы өегездән чыгып китә алыр идегезме? Ә ул кемдер туганыгыз да, хәтта танышыгыз да түгел, бөтенләй җиде ят булса? Сез үзегез дә табиб яисә шәфкать туташы булып эшләмисез, гомумән, бу ярдәмнең сезнең белгечлеккә бер катнашы да булмаса? Йә, ничек, ярдәм итәргә чыгып йөгерер идегезме?

...Каршымда төрле яшьтә, төрле милләттән булган ханымнар утыра. Һөнәрләре дә төрле аларның, кызыксыну, мавыгулары да... Шундый төрле булсалар да, аларны берләштерүче бер уртак көч бар. Ул көч – шәфкатьлелек. Бу ханымнар барысы да Татарстан Республикасының «Детям» – «Балаларга» иҗтимагый хәйрия оешмасы вәкилләре. Әлеге оешма 2010 елның февралендә теркәлә. Ә чынлыкта барысы да аннан күпкә элек, Казан әниләренең форумыннан башлана...

Чын бәхетнең ни икәнен тоясың килсә, башка берәүне генә шатландыр.



Ольга Сазонова Татарстандагы волонтерлык хәрәкәтенең башлангычында торучыларның иң беренчеседер, мөгаен. Алты яшь булды микән аңа ул вакытта, җидеме – ятим малай турында әтисе белән караган һинд киносы әле дә исендә. «Без дә бер бала алыйк», – дип, соңыннан әнисен тәмам аптыратып бетерә. Ятимнәргә булышу теләге әнә шул чагында ук күңеленә кереп кала аның.

Хәтерлисезме, 2000 нче еллар башында зур сәүдә үзәкләренә «Теләкләр чыршысы» куелды. Ятимнәрнең Кыш бабайга атап язган хатлары белән бизәлгән иде ул. Әлеге чарага сеңлесе белән Ольга Николаевна да кушыла – Дәрвишләр бистәсендәге балалар интернатында яшәүче ике кызның хыялындагы бүләкләрне алып, сабыйларны шатландырырга ашыгалар. «Тагын кызларга гына алып килгәнсездер инде бүләкләрне. Безнең янга бер дә килми Кыш бабай», – дип, ишек төбеннән үк 14–15 яшьлек малайлар каршы ала аларны. Үзләренә дә бүләк булмаганын белеп, тәмам нәүмизләнәләр. Берсенең бик тә сәгатьле буласы килә икән, икенчесенә радиоалгыч кирәк – җырлар тыңларга ярата. Интернаттан чыгу белән, кабат кибеткә юнәлә «Кар кызлары». «Карагыз әле, егетләр, моннан чыккач, Кыш бабайны очраттык бит. Менә сезгә дә бүләкләрегезне тапшырырга кушты», – дигәч, малайларның шатлыгы эчләренә сыймый. «Кыш бабай чынлап та бар икән, безгә дә бүләкләр җибәргән!» – дип сөенешәләр. Карап торышка бар җирләре сәламәт кебек тоелса да, акылга зәгыйфь ул балалар яныннан чыкканда күзләре генә түгел, күңелләре дә мөлдерәмә тула. Буш вакытларында интернаттагы балалар белән аралашу тормышының аерылгысыз бер өлешенә әверелә Ольга Николаевнаның. Экскурсияләр оештыра, ялларда өенә алып чыга. Ятимнәргә тиешле фатирларны юллау, кирәкле белешмәләр туплау, укырга урнаштыру, авырсалар – дәвалау, боларның барысын да төп эшеннән бушаган арада башкара ул. Ә бит үз эше дә бик җитди, вакытын да, көчен дә күп ала торган – Социаль гуманитар белем институтында проректор була Ольга Николаевна. Хәзер – «Балаларга» хәйрия оешмасының координаторы.

– Якыннан аралашкач, мин ул балаларны язмыш белән бергә-бер калдыра алмадым инде, – ди ул. – Алар социальләшмәгән, гадәти генә эшләрне дә үзләре белеп башкара алмыйлар, кулларыннан җитәкләп йөртүчесе, юл күрсәтүчесе кирәк. Бәхетемә, гаиләм мине аңлады, «нигә кирәк бу сиңа?» димәделәр, гел булышырга гына торалар.



Галина Юсыпейның да волонтерлык тәҗрибәсе ун елдан артык. Ул – «Балаларга» хәйрия оешмасын оештыручыларның берсе.

– Башкалар кебек үк, без дә ятимнәр йортындагы сабыйларга памперслар, коры сөт, уенчыклар җыюдан башладык, – ди Галина Александровна. – Әйе, балаларга болар бик кирәк, ләкин памперслар белән генә аларны бәхетле итә алмыйсың. Балаларга гаилә җылысы мөһимрәк. Үзләренә яңа әти белән әни эзләүче балаларның фотолары куелган махсус сайт бар интернетта. Дөресен генә әйткәндә, без башлаганда гына андагы кайбер фотолар коточкыч иде. Кайберләре бик искергән. Балага инде 5 яшь, ә фотодан берничә генә айлык сабый карап тора. Ятимнәрне тәрбиягә алырга теләгән гаилә башта бит аның белән әнә шул фото аша таныша. Опека органнары белән сөйләшеп, без ул балалар өчен фотосессия уздырырга килештек. Балаларга тагын да кызыклырак булсын өчен, беррәттән квест һәм осталык дәресләре дә оештырдык - пицца, печеньелар пешердек. Бик җанлы килеп чыккан иде ул фотосессия.

Ул вакыттагы волонтерларның барысы да диярлек – декрет ялындагы яшь әниләр. Вакыты җиткәч, күпләр эшкә чыга. Волонтерлык белән шөгыльләнү өчен вакытлары калмый. Шуңа да бүгенге көнгә кадәр килеп җитүчеләр – иң чыдамнары, иң түземнәре, иң фидакарьләре.

– Без күбрәк Казанның 18 нче хастаханәсендә дәваланучы ятим-

Тәмле ризык, матур киемнән битәр,
ятим күңеле якты хатирәләргә мохтаҗрак.

нәр янына килә идек. Егермеләп балага нибары бер тәрбияче. Гел килеп йөргәч, тәмам үз кешеләргә әверелеп беттек. Кайчагында тәрбиячене алыштырып торырга да туры килгәләде. Йә авырып китә, йә ялга чыгарырга кирәк... Оешмабызның төп юнәлеше шулай билгеләнде, – ди Галина Александровна.

Авырып, хастаханәгә эләккән баланың кичерешләрен аңлавы кыен түгел. Бөтенләй ят мохит, ят кешеләр, җитмәсә, авырттыра торган уколлары тагын! Балалар йортында яшәүче сабый авырып китә икән, хастаханәгә аның ялгызын гына салалар. Хәтта күкрәк баласын да! Балалар йортының аңа тәрбияче билгеләрлек мөмкинлеге юк. Ә хастаханәдәге табиблар, шәфкать туташларының үз эше. Авырткан урынны «өф» итәргә, юатырга, иркәләргә вакытлары бик тә чикле. Дәваланудан тыш, хастаханәдәге бала аерым кайгыртуга да мохтаҗ. Аның янында утыручы, елаганда юатучы, курыкканда тынычландыручы, киемнәрен алыштыручы, юындыручы, ашатучы кеше кирәк.





– Хастаханәдә дежур торуны баштарак үз көчебез һәм волонтерлар ярдәме белән генә башкарырга тырыштык, – дип сүзгә кушыла «Балаларга» хәйрия оешмасы директоры **Аделина Минһаҗева**. – Ләкин волонтерлар бүген килә, иртәгә вакыты булмаска да мөмкин. Әлбәттә, волонтерларның ярдәме бәяләп бетергесез. Ләкин алар көненә ике-өч сәгатькә генә килә ала. Без дә һәр көнне хастаханәдә куна алмыйбыз, һәрберебезнең үз гаиләсе бар, аларга да без кирәк. Уйлаштык та, җыелган хәйрия акчаларына хастаханәдәге балалар янында кизү тору өчен нянялар ялларга булдык. Бу эш белән 2011 елдан бирле шөгыльләнәбез. Ләкин әйтүе генә җиңел. Интернетта «сиделка» хезмәте күрсәтергә әзер булучыларның белдерүләре күп булса да, без тәкъдим иткән акчага кызыгучылар аз. Без бит бизнесменнар түгел, хәйрия оешмасы гына. Аннары, кеше риза булса да, бу эш аның җанына туры килмәскә мөмкин. «Бала карары олы кешене карау түгел», – дип уйлап килүчеләр бар. Ялгышалар. Әйе, олы кешене күтәрү-төшерү, юучистарту кебеге авыррактыр, килешәм. Операциядән трубкаларга уралып чыккан, авыртудан сызланып елаган баланы юатуы, трубкаларны тартып ала күрмәсен дип, бер мизгелгә дә күздән ычкындырмый саклап утыруы, беләсезме, ничек кыен?! Ятим балалар арасында физик мөмкинлекләре чикләләр дә күп. Куллары хәрәкәтләнә алмаган баланы зонд аша һәркем ашата алмый, түземлеге дә җитми, аның өчен тәҗрибә дә кирәк.

Без хәзер күбрәк Республиканың балалар һәм йогышлы авырулар клиник хастаханәләрендә эшлибез. Ковид башланган 2020 елны барыгыз да хәтерлидер. Әлеге куркыныч чир турында ул чакта берни дә белми идек бит әле. Бездән бер генә кат өстәрәк урнашкан бүлеккә ковид йоктырган беренче авыруны алып килделәр. Ул көнне дежурда Тәнзилә апа Тихомирова иде. «Тәнзилә апа, кайтыгыз. Анда калу хәзер үзегез өчен куркыныч», – дидек. Олы яшьтәге кешеләр өчен бу чир аеруча хәтәр. Беләсезме, шул чакта да ул дежурлыкны калдырып китмәде. Авырып яткан ятим бала гомерен үзенекеннән дә өстенрәк куйды. Тәнзилә апа – Казанның Юдино бистәсеннән. Безнең белән тоташ дүрт ел эшләде. Кеше шулкадәр мәрхәмәтле булса да булыр икән! Палатадаш хатыннар Тәнзилә апаны баланың үз әбисе дип уйлый иде. Кайсы бала белән генә булса да! Гаҗәеп киң күңелле ул.

Бер очрак турында гына сөйлим дә... Балалар йортыннан хастаханәгә бер баланы китерделәр. Онкология иде аңарда. Шуны белгәч, үзара килештек тә бу балага чит кешеләрне билгеләмәдек, үзебез генә чиратлап карарга булдык. Дүрт ай дәваланды ул. Шулкадәр ияләшеп беттек аңа, үз балабыз кебек якын булды. Соңыннан аны бер гаилә уллыкка алды. Тәнзилә апа шул гаилә белән дуслашып, хәзер аларның яраткан әбиләренә әйләнде. Әле дә аралашалар, кунакларга йөрешәләр.

Ә Елена Ивановна Пойлова?! Үзенең дә дүрт оныгы бар. Ул ялдан кайткан көнне хастаханәгә бик авыр хәлдәге баланы китерделәр. Андый

балаларны карар өчен тәҗрибәле няня кирәк. Кыенсынып булса да Елена Ивановнага шалтыраттык. Ике тәүлек буе автобуста кайткан кеше шул төнне үк дежурга чыкты. Ике төн рәттән!!! Никадәр миһербан булырга тиеш бу кешенең күңелендә?!

– Беребез дә робот түгел. Барыбыз да хисчән, – ди Галина Юсыпей. – Бик авыр тарихлы балалар була. Шушы нарасыйларның моңа кадәр ниләр кичергәнен уйлыйсың да… Узган ел әниләре аркасында салкында калып өшегән балалар турында матбугатта күп яздылар. Ул балаларны хастаханәдә без карадык. Ходай күрсәтмәсен андыйны күрергә, коточкыч… Бервакыт әнисе белән юл һәлакәтенә юлыккан 14 яшьлек кызны карарга туры килде. Әнисе вафат… Бөтен җире имгәнсә дә, бала исән. Өстәвенә, тумыштан ДЦП да икән үзендә. Минем улыма да 14 яшь иде ул вакытта. Телисеңме, теләмисеңме – параллельләр уздырасың. Бу дөньяда япа-ялгызы калган шул баланы уйлап җаным сыкранды. Болай да яшәве җиңел булмаган бит инде аңа, хәзер әнә сынмаган сөяге юк… Боларның барысын да үз йөрәгең аша кичерәсең. Шуңа да кемдер озакка чыдамый, китә. Оешмада күп еллардан бирле даими эшләүчеләр без берничә генә кеше. Үзебезнең волонтерлар чаты бар. Анда дүрт йөздән артык кеше. Кирәк вакытта алар да ярдәм кулы сузарга әзер.



Галина Александровна төп эше белән волонтерлыкны ун ел рәттән алып барган. Узган ел тәки йөрәгенә буйсынырлык көч тапкан үзендә – дәрәҗәле дә, акчалы да эшеннән үз теләге белән киткән.

– Бу дөньяда акчадан бик күпкә мөһимрәк нәрсәләр бар, мин шуны аңлар яшькә җиттем, ахрысы, – ди ул. – Минем хәзер төп эшем – оешмага хәйриячеләр җәлеп итү, чаралар оештыру, грантлар конкурсына гаризалар язу…

«Балаларга» иҗтимагый хәйрия оешмасының проектлары икәү. Берсе югарыда бәян иткән «Хастаханә балалары» – «Больничные дети» булса, икенчесе – сәламәтлеге чикле балалар өчен иппотерапия һәм адаптив ат спорты үзәге.

– Бу идея безгә көтмәгәндә килде, – ди Аделина Әмировна. – Ятим балалар белән эшләүче оешма буларак, безнең дә төп максатыбыз – аларга яңа әти-әни табу. Сәламәт балаларны гаиләле итүе күпкә җиңелрәк. «Без бу балаларга тагын ничек ярдәм итә алабыз?» – дип уйлаштык та, иппотерапия искә төште. Әлбәттә, ул чагында без бик җиңел генә уйлаганбыз. Барабыз да бер ат сатып алабыз, нәрсәсе бар аның, янәсе. Иппотерапия белән теләсә кем шөгыльләнә алмаганын, һәм ул белгечләрне Санкт-Петербург белән Мәскәүдә генә әзерләгәннәрен белә идек үзе. Укырга җибәрү өчен кешесен дә таптык. Светлана Викторовна Гайнетдинова шунда ук курсларга укырга китеп барды. Тик менә ат мәсьәләсе… Казан ипподромында күңелебезгә ошаган теләсә кайсы атны бушка алырга тәкъдим иттеләр итүен дә… Эзләнә, өйрәнә торгач, моның өчен теләсә кайсы атның туры килмәве, аның холкы, буе, хәтта аркасының киңлегенә дә билгеле бер таләпләр булуы ачыкланды. Бик чыдам, акыллы, сабыр, киң һәм тигез аркалы, салмак адымлы, артык биек тә булмаска тиеш иде ул. Калуга өлкәсендә табылды андый ат. Ярты хакын үз акчамнан түләдем, ә яртысын Светлана Викторовна бирде. Мине үз гомеремдә әле ике генә тапкыр күргән килеш! Хәзер инде безнең үзәктә андый атлар алтау. Иппотерапия ул атка атланып йөрү генә түгел. Ул – махсус өйрәтелгән атта һәм махсус белеме булган тренер күзәтүендә уздырылган күнегүләр системасы. Бу система һәр бала өчен аерым билгеләнә.

Үзәк эшли башлаганнан бирле биредә акыл һәм физик зәгыйфьлеге булган 900 бала сәламәтләнү узган. Ә 2015 елдан монда шөгыльләнгән 22 бала адаптив ат спорты һәм паралимпия чабышы буенча ярышларда катнашкан. Быел җәй исә Татарстан тарихында беренче тапкыр безнең команда ат спорты буенча Мәскәүдә узган махсус Спартакиадада чыгыш ясаган.

Кызганыч, әлегә аларның үз мәйданчыклары юк, ләкин киләчәктә булыр дип өметләнәләр.

– Заманча җиһазландырылган шундый үзәк Татарстанда да ачылса, анда паралимпиячеләрне дә әзерләп булыр иде, – дип хыяллана «Балаларга» хәйрия оешмасы җитәкчеләре. – Россиядәге шундый башка үзәкләр өчен кирәкле белгечләрне дә үзебездә генә укытыр идек…

Оешманың әлеге проекты 2018, 2021 елларда Россия Президенты грантына ия булган, узган ел Татарстан Республикасында «Елның иң яхшы социаль проекты» булып танылган. Хәзерге вакытта аларның «Татнефть» хәйрия фонды грантын гамәлгә ашыру белән янып йөргән көннәре – адаптив ат спорты һәм иппотерапия юнәлешендә шөгыльләнергә теләүчеләр өчен Әлмәт шәһәрендә бушлай курслар оештырачаклар.

«Балаларга» хәйрия иҗтимагый оешмасы «Мәрхәмәтле Казан», Добро Mail.ru, СберВместе сервисларының иң ышанычлы хәйрия оешмалары реестрына кертелгән.

«Әгәр һәркем үзе булдыра алган кадәр яхшылык эшләсә, яхшылыкның чиге булмас иде». Язучы Фазыл Искәндәр сүзләре бу. Килешәсезме?

Фотолар: Анна Арахамия һәм «Балаларга» иҗтимагый хәйрия оешмасы архивыннан.

Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.
«Сөембикә» журналы белән берлектә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен үстерү мәсьәләләре комиссиясе «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак, һәм аларның иң эчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!





КАДЕРЛЕ КЕШЕБЕЗ



43 ел гомер... Миңа инде 66, әнигә 87 яшь. Гомер мизгел генә икән ул. Мин, Арча педагогика училищесын тәмамлаган кыз, әле яңа шушы авылга укытырга килгән кебек идем. Ә бит Горький шәһәренә китәсе идем, гаиләдә төпчек кыз булгач, әнинең еракка җибәрәсе килмәде, сөйләшеп, районда калдыра алды. Бер белмәгән Курса Почмак авылына эшкә билгеләделәр. «И балам, анда балта-пычак белән сугышалар икән», – дип кайгырып калды әни. Ә минем эчәр суым, яшәр нигезем шушында булган икән... Акыллы иремнән уңдыммы, зирәк кайнанамнанмы? Бу сорауга әлегә кадәр җавап бирә алмыйм. Әни булмаса, менә шундый ирем дә, җайлы-уңайлы бүгенге тормышыбыз да булмас иде, мөгаен. Шуңа 43 ел сизелми дә үткән инде. Әнинең зирәк киңәшләре белән...

«Абыегызны тыңласагыз, тормыш барыр, сансыз булсагыз – таркалыр»

Ярты гасыр диярлек бергә яшәп, күпме сүзләр сөйләшенгән, күпме хатирәләр тыңланган. Әнинең тормышы кино тасмасы кебек күз алдымнан уза... 12 бала үскәннәр алар. 18 яшендә шушы авылның бик чибәр егетенә кияүгә чыккан. Әмма ир хатыны булып бары 17 ел гына яшәп калган. 35 яшендә сигез баласын кочаклап тол калган. Һәм гомере буе тол хатын булып яши. Үз исеменә тап төшерми. Эшкә чыгып киткән җиреннән генә мәрхүм булган иренә тугрылык саклый, гомерен балаларына багышлый. Аларны аякка бастырырга кирәк бит: иң зурысына – 13, иң кечкенәсенә нибары яшь тә ике ай... Ирем Марсель – әнинең уллары арасында иң олысы. 7 нче класс укучысы бертуганнары өчен әти кебек була. Әни балаларын җыя да аңлата: «Бу сезнең абыегыз. Әмма ул абый гына түгел, сезгә әти дә булачак. Абыегыз нәрсә әйтә, шуны эшләгез. Абыегызның, минем сүзне тыңласагыз, тормыш барыр, сансыз булсагыз, берничек тә тормыш алып барып булмас. Ишеттегезме, балакайларым?» – дип, кат-кат әйтә. Марсельнең туганнары әнисе сүзләрен гомер буена исләрендә калдыра. «Дәү абый», дип, әлегә кадәр киңәш-табыш итәргә төп йортка җыелалар. Инде үзләре әби-бабай булсалар да, бер-берсенә ярдәм итеп яшиләр.

«Үз теләгең булса гына авылда кал»

Мин Курса Почмакка эшкә килгәндә Марсель армиядә булган әле. Килгән елны өченче сыйныфларны бирделәр. Завуч ишек артыннан тыңлап торган да: «Кычкырмыйсың да, ачуланмыйсың да, ничек кенә тыңлатасың соң син аларны?» – ди. Яшь булгач, балаларга кызык күренгәнмендер инде. Аларча сөйләшкәнмендер. Җитмәсә, мин бит килгән кеше. Парта арасында йөргәндә күлмәкләремә кадәр тотып-тотып карыйлар иде. Икенче елны инде беренче классны бирделәр. Октябрь айлары иде.
Ирек исемле укучым: «Минем абый армиядән кайтты. Таныштырыйм әле сезне, апа. Безгә килегез әле, яме», – ди. «Мин бит сезнең өегезне белмим», – дигән булам.

Алдалыйм инде. Сентябрь җиткәнче бөтен укучыларымның өйләренә барып танышып чыккан идем үзе. «Багана башына уенчык куярмын, шуңа карап килерсез», – ди. Марсельнең энесе булган бу. Ә без инде Марсель белән танышкан идек. Поездда күргән булган. Минем эшкә килеп барышым, ә аның армиядән кайтып, районга военкоматка хисапка басып кайтышы булган. Армиядән кайтуга, әнисенә тракторга утырырга нияте барлыгын әйткән. Өй тулы кечкенә балалары булса да, әни: «Каласың, миңа ярдәм итәсең», – димәгән. «Абау, балакаем, авылда калыргамыни исәбең?!. Сез генә калдырттыгыз бу колхозда, дип, әтиең дәү әниләреңә дәгъва белдерә иде. Минем өчен генә калма, үз теләгең булса гына кал, миңа үпкәләрлек булмасын», – дигән. Әнине өй тулы бала белән Марсель ничек калдырып китә алсын инде?! Ул бит абый кеше генә түгел, әти кеше дә...

Яңа ел алдыннан мине беренче тапкыр озата кайтты ул. Ике елдан соң зәмһәрир салкын кышта өйләнештек...

«Тәрәз артыннан карап, күнләшеп йөрерлек булсаң, өйләнмисең»

Марсельгә кияүгә чыгуымны белгәч: «Алар шундый усаллар, сине чәйнәп өзәрләр», – диючеләр дә булды. «Авызларыннан кеше аяклары күренеп тормый әле», – дип әйтә идем. Тол хатын усал була инде ул. Усал булмаса, тормышны алып та бара алмый. Тормыш өчен усал булган ул, кешеләргә карата явыз түгел. Ул яшемдә мондый ук тормыш фәлсәфәсен аңлап бетерә алмаганмындыр, яшьлек бит, ярату йөрткәндер. Марсельне ярату күземне томалагандыр дип уйлыйм. «Булачак кайнанаң аждаһа синең», диючеләр дә куркыта алмады. Яраткан кешеңә кияүгә чыкканда кайнананың усал, юаш булуы турында уйламыйдыр ул яшь кызлар. Һәрхәлдә, без яшь чакта шулай иде... Ике яклы өйдә әни һәм алты бала. Марсельнең апасы кияүгә чыккан, энесе армиягә киткән иде. Калганнары – мәктәп балалары. Укытучы кеше булгач, миннән бик оялалар. Безнең туй вакытында Ирек белән Инил, урамда йөреп, борын-кулларын өшеткәннәр иде хәтта. Балаларның тыйнак-акыллы булуы, укытучыга карата ихтирамы шунда ук күренгән инде.

Алтын таулар вәгъдә итеп өйләнмәде миңа Марсель. Ул вакытта андый вәгъдәләр бирешмиләр дә иде. Авылдан китәбез дигән иде шулай да. Мин бит шәһәр кызы. Мал-туар асрап, авыл җирендә тормыш алып баруымны яшьлегем белән күз алдына да китерә алмаганмындыр, мөгаен. Әмма яши башлагач, сеңел-энеләрен ташламаячагын аңлап, бу хакта сүз тишмәдем. Үз әнием дә: «Суның үз агымы була, борчыма кияүне», – диде. Тол хатынның килене булу тагын да җаваплырак, миңа калса. Парлы булсалар, бер-берсе белән киңәш-табыш итәрләр, сөйләшерләр иде. Ә әни ялгызы. Мин моны бер минутка да исемнән чыгармадым, әнинең яралы күңеленә тимәскә тырыштым. Үз әнием дә: «Кодагый – тол хатын. Аның янында ирең белән кочаклашма, кулларыгыздан да тотынышып утыра күрмәгез», – дигән иде.

Килен булып төшүгә үк әни балаларына миңа «Туган апа» дип эндәшергә кушты. Барысы да, хәзер килендәшләрем дә шулай эндәшә. Хәзер уйлыйм, әни шулай миңа карата балаларында хөрмәт тәрбияләгән. Үзләреннән бер баскычка югарырак куйдырган. Әтиләре урынына калган абыйларының хатыны бит дип уйлагандыр, мөгаен. Берәрсе ялгыш кына Равия апа дип эндәшсә, Марсель шундук ачулана иде. «Нинди Равия булсын, Туган апа ул», – дия торган иде.

> Яраткан кешеңә кияүгә чыкканда кайнананың усал, юаш булуы турында уйламыйдыр ул яшь кызлар.

Беренче көннән үк үзем дә әни дип эндәштем. Әнинең аждаһалыгын да, явызлыгын да күрмәдем. Бары тик бик намуслы, гадел хатын булуын аңладым. Мин килен булып төшкәндә аңа бары 42 яшь иде. Әмма аңарда йөзьяшәр өлкәннәр зирәклеге булган. Әле күптән түгел сөйләде. Марсель миңа өйләнәм дип кайткач, әни аны каршысына утыртып: «Сиңа бер сүз әйтәм. Ул – халык арасында йөри торган кеше. Мәктәптә язу-сызулар буенча ир-атлар арасында калган вакыты да булыр, эш буенча ирләр белән дә чыгып китәр, күнләшеп, тәрәзә артында селәгәеңне агызып йөрерлек булсаң, өйләнмисең. Үз-үзеңне кулга алып, шулай тиеш дип кабул итсәң, өйләнәсең, улым», – дип аңлаткан. Шушы сүзләрдән соң кем әнине усал дип атый ала инде?! Бу бит алтын хәрефләр белән язылырлык киңәш. Укытучы булгач, гел мәктәптә, җәмәгать эшләрендә булдым. Әмма әнинең дә, Марсельнең дә миңа бервакытта да кырын караганы булмады. 37 ел мәктәптә укыттым, Марсель тракторда, комбайнда эшләде. Кайда эшләсә дә, беренчелекне бирмәде. «Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мәртәбәле исем дә бирделәр үзенә. Күңеле тыныч кешеләр генә эшенә бирелеп эшли бит ул.

Шәһәр кызы булгач, авыл җирендә эшләгән бөтен эшне дә белеп бетерми идем. Беркайчан да шуны да эшли белмисең, дип әйткәне булмады әнинең. Шәһәр кызы икәнемне белде һәм кабул итте. Үз әнием дә туйдан соң: «Кодагый, мин сиңа кызымны бирдем, син аңа ана бул, бөтенесенә дә үзең өйрәт», – диде. Җайлап кына барысына да өйрәтте инде әни. Югыйсә башта күрше-тирә әбиләре шәһәр кызы авыл эшен белми, дип, миңа түбәнсетебрәк тә карыйлар кебек иде. Тормыш башлаганда кушаматым да: «Клараның укалы калфагы» булды.

«Кайтсагыз – кунак, китсәгез – ерак»

Марсельнең энеләрен барысын да менә шушы өйдә кунак җыеп, армиягә озаттык, дүрт энекәшенең, ике сеңлесенең туен уздырдык, кодалар алдырдык. Ул вакытта сугым саен да кунак җыю бар иде. Яңа елда бөтен гаилә белән җыелабыз. Күңелле итеп яшәгәнбез инде. Низаглы йортта күңеллелек булмый ул. Ә башка чыгу дигән теләк бөтенләй уйга да кермәде. Без өйләнешкәч тә әни бөтен баласын җыеп: «Өйдә килен бар инде, без эшләмибез дигән сүз булырга тиеш түгел. Кайтсагыз, элеккечә үк бөтен эшне җигелеп эшлисез. Ник кайтмый-



Мин килен булып төшкәндә әнигә бары 42 яшь иде. Әмма аңарда өлкәннәр зирәклеге булган.

лар дип сагынып көтәрлек, кайтышыгызга мунча ягып, ризык пешереп торырлык булсын. Бернәрсәгә дә катышмагыз. Кайтсагыз – кунак, китсәгез – ерак», – дип, алдагы тормышны хәл итте дә куйды. Чынлап та, гомер буе эшне бергәләп эшләдек. Килен-кияүләр дә кайтуга эшкә тотынды бездә. Әни бервакытта да эшне бүлмәде.

Беренче улыбызны алып кайтканда әнинең иң кечкенә малае Иреккә 10 яшь иде. Ирек Маратны тирбәтеп үстерде. Бишеккә бау астык та, бер кулы белән тирбәтте, бер кулы белән дәресен әзерләде. Элек хатын-кызларга озаклап бала ялы бирмиләр иде. Балага яше тулыр-тулмас эшкә чыктым. Әйе, бер-бер артлы биш малай алып кайттым мин. Таптым да әнигә калдырдым инде. Әнинең куенында үстеләр. Өченчесе әнинең 50 яшенә бүләк булды. Туган көннәре бер көндә. Өйгә кайтуга ук: «Әни, мә, синең туган көнеңә бүләк бу», – дип тоттырдык аңа Зөлфәтне. Җәй көне каникул вакытында өйдә ундүртешәр бала була торган иде. Әни тәрбияләде инде аларны. Кичен бергәләп юындырабыз. Зур ләгәнгә су салып, беребез юындыра, беребез сөртеп тора, киемнәрен юып куя. Мәшәкатьләр белән балалар үскәнен сизмәдек тә.

«Балаң бәхетле булсын дисәң, әни кеше бөтенесенә түзәргә тиеш»

Әни шулай ди. Ул сүзләр белән килешми мөмкин түгел. Тормыш булгач, төче телләнеп, сөешеп кенә яшәп булмый. Әнә шул сүзләрне искә төшерәсең дә кайдадыр эндәшми каласың, кайдадыр күзне йомасың. Әни дә шулай эшләгәндер. Икең дә сабыр булсаң гына ватылмый ул дөнья. Шөкер, әни дә, мин дә кияү-киленнәрдән уңдык. Үзем биш киленгә кайнана булсам да, әле дә килен кеше булуыма сөенеп яшим. Икенче улыбыз Булат өйләнгәч, килен белән өч ел бергә яшәдек. Килен дә курыкмады: ике кайнана өстенә төште. Бер дә савыт-саба шалтыратышмадык. Әле өй җитештергәч тә, чыкмыйбыз, дип, һаман тартып-сузып йөрделәр. Мәҗбүриләп диярлек чыгардык башка. Булатның хатыны Люция дәү әниләрен үзләре белән чыгарга кодалады. «Берни эшләтмәбез, син өйрәтеп кенә утырырсың», – диде. Әнине яратмасалар, шулай әйтерләр идеме соң?

«Йә ач калырсыз, үзең тот акчаны»

Без акчаны аерым тотмадык. Килен булып төшкәч, акча алуга әнигә кайтарып бирдем. Үз акчам үземдә булсын диган уй башыма да кермәде. Әни дә акчаңны миңа бирерсең димәгән иде. Татар авылларында гадәте шундый булгандыр инде. Начар гадәт түгел дип әйтер идем. Акча исәпне ярата, таратып тотасың икән, ничек тормыш алып бармак та, зур эшләр башкармак кирәк. Күпме алып кайтып бирсәң, әни шуңа риза булды. Бервакытта да: «Ник синеке шуның кадәр генә, моныкы фәлән кадәр», – димәде. Ун еллап акча янчыгы әни кулында булган икән. 90 нчы елларда, акчалар алмашынып, дөньялар болгангач, әни кибеттән кайтты да: «Равия, минем кулдан ашасагыз, йә ач калырсыз, менә сиңа кошелёк, теләсә нәрсә эшлә, җиткер», – ди. Чынлап әйтәм, куркып калдым. Укытучыларга хезмәт хакына тартмасы белән аракы биргән заманнар бит ул. Акча янчыгын миңа бирде дә, бернәрсәгә кысылмады. Акчагызны кая куясыз, нишләтәсез дип сорашып йөрмәде. Әни күпме пенсия алуы белән дә кызыксынмый, хәер акчаларын да җыеп, миңа тоттыра әле ул.

«Нәрсәгә миңа акча? Бик кадерле әни, бик кадерле дәү әнимен»

Чынлап та, бик кадерле бик бәхетле ул безнең әни. Яшьлегендә өлешенә төшкән авырлыкны сынмыйча уза алуының әҗерен күрә. Авылның Ак әбие, абыстае ул хәзер. Әнигә булган хөрмәтне күрсәгез икән. Күпме авыл халкын кәфенләп юып озаткан кеше ул. Аяклары начар йөри башлагач кына бу саваплы эштән туктады. Авыл җирендә теләсә кемгә мәет юдыртмыйлар бит ул. Чиста, хөрмәтле, иманлы кеше башкара ул эшне. Әни 50 яшендә Марсель белән бездән качып кына намаз укый башлады. Арчага – минем әнигә йөреп Коръән сүрәләре өйрәнде. Үз әнием мулла кызы иде, эти дә мәдрәсәдә укыган. Без дини тәрбия алып үскән балалар. Әни белән икәүләп намаз укыйбыз.

Әни 87 яшендә булса да, бик тынгысыз ул безнең. Бервакытта да кул кушырып утырганы булмады. Әле бер таяк белән йөргәндә бакчага чыгып чүп утап та керә иде. Хәзер махсус җайланма белән генә хәрәкәтләнгәч, чыга алмый. Әмма аңа карап тик утырмый. Кер юдырсам – үтүкләп куя, тишек күрсә – тегеп куя, бәлеш-пироглар пешерә башласам – килеп утырып, бөгә башлый. Кулларына күз иярми аның. Киленнәр кайткач: «Кызым, шуны эшләп алыйк әле», – дип, әле дә эш кушып йөри. Әнисез тормышны күз алдыма да китерә алмыйм. Үз әнием белән яшәгәнгә караганда, аның белән ике тапкыр күбрәк яшәлгән бит инде. Җаннар якынаеп беткән. Авырый башласа, котым оча. Әнисез калудан куркам. Безнең өй стенасында зур шәҗәрә бар. Оныклары дәү әниләренең туган көненә ясап бирде. Ел саен диярлек бер яфрак өстәлеп тора аңа. Менә шул агачның тамыры инде ул әни. Тол калуга, бөтен балаларын нигытып бер йодрыкка җыйган да, шуннан бирле тотып тора. Шуңа да бар баласы, 20 оныгы, 34 оныкчыгы (35 нчесе өметтә) – барысы да тәүфыйклы, «әни», «дәү әни», дип, өзелеп торалар. Бәхетле картлык шулдыр инде ул.

Безгә кергән кеше чәй эчми чыкмый. Бу – безнең өйнең гадәте. Әнинең кайнанасыннан килә ул. Ипи пешергәч, капкадан чыгуга кем очрый, шуны чәй эчәргә алып кергән булган. «Чәемне эчеп чыгып китә икән, Аллаһы Тәгалә бик рәхмәтле була», – ди. Әнә шундый киң күңелле, якты йөзле дә әле ул безнең әни.

Равия ШӘЙМУЛЛИНА.
Арча районы, Курса Почмак авылы.

ҮЗЕБЕЗДӘН ТОРА



Марат
КӘБИРОВ,
язучы

И-и, яратабыз инде акчаны без. Яратмый да булмый, өеңнән чыгып кая гына барыйм дисәң дә, акча кирәк. Өеңнән чыкмасаң да кирәк. Һәртөрле квитанция кыяфәтенә кереп талаучылар үзләре килеп җитә. Фатирга, утка, суга... Адәм баласы соңгы ыштанын сала-сала, фәлән хакка фатир сатып ала һәм шул фатирында гомер буе тагын фәлән хәтле акча түләп яши. Кыскасы, акча кирәк. Ансыз булмый...

Без шулай уйлыйбыз.

Бер көн кибеткә чыктым. Кирәкле нәрсәләрне җыйдым инде. Чама белән бер мең тирәсе булырга тиеш. Сатучыга акча сузам. Теге баш чайкый:

– Юк, – ди, бик җитди кыяфәт белән. – Без акча кабул итмибез.

– Ничек инде... Ничек акча алмыйсыз?

– Депутатлар яңа закон чыгарды, – ди бу һаман шул җитди килеш. – Хәзер бөтен нәрсәгә дә елмаю белән түләргә кирәк.

– Елмаю белән? – Минем хәтта тел аңкауга беректе. Сүзне дә әйләндереп әйтеп булмый. – Нинди елмаю?

– Ихлас елмаю, – дип аңлата кыз, мине мәктәп баласына тиңләп. – Сез ихлас итеп елмаясыз. Һәм шул түләүгә исәпләнә. Елмаегыз.

Идәнеңне сепертим! Елмаясы килми. Тамакка төер тыгылды. Сүз дә әйтеп булмый, елмаеп та булмый. Катып тик торам. Артта чират хасил булды. Ашыктыралар.

– Елмай инде, – диләр. – Тормыш авыр чакларда да елмаеп яшәдек бит. Хәзер менә елмай – бәхет килде, акча дип җан кортасы түгел, бөтен нәрсәне елмайганга биреләр.

Ә елмаеп булмый. Аптырап була, аңгыраеп була. Елмаеп булмый. Һушым китүдән телне көчкә әйләндердем:

– Ә акча гына түләсәң ярамыймы?

– Юк, ярамый, – ди кыз, тынгысызлана башлап. – Югарыдан рөхсәт итмәделәр.

Ә арттагылар шаулаша:

– Нәрсә ул акча? Кәгазь!

– Ә елмаю ул – яктылык. Энергия!

Елмаерга теләп ишеткән-белгән анекдотларны хәтерләргә тырышам. Искә төшми. Авызны ерган булам. Нык итеп ерам. Сатучы куркып артка чигенә:

– Сез нишлисез?! – ди ул, коты алынып. – Бу бит җинаять!

– Нәрсә җинаять?

– Ясалма елмаю. Аның өчен, беләсезме, ничә елга утыртып куярга мөмкиннәр?!

Утырту сүзен ишеткәч, алган әйберләрне калдырып чыгып сызу җаен карыйм. Алла сакласын! Һәм базарга йөгерәм.

Хәзер рәхәт бит, кирәкле товар бөтен җирдә бар. Кибеттә якты йөз күрсәтмәсәләр, базарга керәсең, анда да булмаса, тагын башка урынга... Базарга барып кирәкле әйберләрне тотырам да сатучыга теге меңлекне сузам. Ул аптырый:

– Сез нәрсә, күктән төштегезме әллә?!

Хәзер мин аптырыйм:

– Гафу итегез?

– Соң, хәзер бит валюта бүтән төрле.

Минем сизә торган җир җем-җем итеп куя. Ә тел үзенекен итә:

– Елмаюмы?

– Елмаю, – ди сатучы күңеле булып. – Әйдәгез, елмаегыз. Сездән ике ихлас елмаю.

– Ничек ике, – мәйтәм. – Шушының өченме? Монда бит ике кило да юк.

– Яхшы, елмаю ярым.

Ә мин елмая алмыйм. Авыз кибә, тел корый. Болай гына авыз ерсам, утыртып куярлар дип куркам.

– Бәлки, акча гына бирергәдер?

– Ә миңа нигә ул кәгазь? – дип аптырый сатучы. – Кәгазь заманы узды.

Мин, берәр кызыклы хәл юкмы дип, тирә-юньгә караштырам. Юк. Кешеләр элек акчаны ничек сакласа, хәзер елмаюны шулай саклый икән. Бөтен җирдә тәртип, пөхтәлек. Барысы җитди. Елмаеп булмасмы дип, көчәнеп, тагын бераз басып торам да китәргә ашыгам.

И заманның тизлекләре! Әле кайчан гына акча юк дип зарланып бетә алмый торган идек. Бөтен халык шуның артыннан чаба, шул кәгазь кисәге өчен җанын корбан итәргә, иң кадерле кешеләрен сатарга әзер иде. Һәм менә бер көнне... Әгәр бөтен кеше берьюлы: «Акча түгел, ә елмаю мөһимрәк», – дип уйлый икән, димәк, елмаю тәхеткә менә. Барысы да үзебездән тора. Әгәр без барыбыз бер булып: «Акча түгел, ә матурлык, изгелек, күңел хөрлеге мөһим», – дип уйлыйбыз икән...

Шундый уйлар белән өемә кайтып җиткәнне сизми дә калганмын. Гадәт буенча, почта яшнигенә күз салдым. Ә анда гадәте буенча – квитанцияләр. Акча түләргәдер инде дип өметләнсәм, алай булып чыкмады. «Фатирда яшәгән, ут-газ яндырган өчен, килеп, өч тапкыр елмаеп китегез әле», диелгән...

Әйткәндәй, бу язма да сезгә бушлай түгел. Укыдыгызмы? Сездән – бер елмаю!

PRESSA

ЯШӘТӘБЕЗ ӘЛЕ АВЫЛНЫ!



Алсу ШАКИРОВА



Әгерҗе районында урнашкан Уразай авылының бөтен тормышы шушы йортта тупланган диярсең. Дингә кагылышлы сораулармы ул, авылның көнкүрешен, мәчетен, мәктәбен, мәдәният йорты тирәсен колачлаган җәмгыяви мәсьәләләрме – барысы да шушында хәл ителә, диләр авылдашлары, гаилә дуслары. Тәнзилә апа һәм Бибел абый Ибраһимовлар гаиләсе авыл тоткасы монда. Үзләре болай дип әйткәннән читенсенерләр, әлбәттә. Тыйнаклар…






Фото: Анна Арахамия

Китап кушканча

– Үзем колхоз бригадиры,
Комбайнер һәм тракторист.
Кирәк икән – булам танкист,
Ял иткәндә – гармонист...

Менә шушы санап киткәннәреннән гармунчы гына булмадым, – дип көлә гаилә башлыгы Бибел абый. Менә дигән авыл егете булган ул яшьтән үк. Гайсә абый белән Рабига апаның беренче балалары. Сугыштан инвалид булып кайткан әтисе бик кыска гомерле – 24 яшендә үк гүр иясе була.

– Кечкенә чакта колакка көнбагыш тыкканмын. Берничә ел шунда торган да, колак пәрдәсенә зыян салган. Шуның аркасында хәрби хезмәткә алмадылар мине. Аның каравы, җиң сызганып колхоз эшенә тотындым. Ат җигүдән башлаган идем, аннары авылга электр керттек... Комбайн, тракторда эшләүне әйтәсе дә юк инде. Болар янына бригадир булып эшләгәннәрне, пилорамада эшләгән елларны, тимерче, эретеп ябыштыручы булып эшләгәннәрне дә кушсаң, хәйран белгечлек җыела икән...

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, ди халык. Китап кушканча булган лабаса...

54 ел иңне иңгә куеп гомер итәсе ярын Сабантуйда очрата Бибел абый.

– Очрата дип, авылда яшьләр бер-берсен белеп үсә инде анысы. Шулай да үз чорыңа якынрак кызлар белән аралашырга тырышасың. Ә монда күз төште бит! Тәнзилә 9 нчы классны гына тәмамлаган иде әле. Бигрәк бала-чага – миннән кача да алмады инде. Укып бетергәнче сабыр иттек тә, Сабантуйдан соң әни белән сорарга бардык. Никах укытып алып кайттык. Барысы да китапча булды, – дип искә ала Бибел абый.

Гаилә корып җибәргәч, Тәнзилә апа авылның мәдәни тормышын тулысынча үз җилкәсенә ала. Ул эшләгән елларны авыл халкы сагынып искә алырлык булган шул. Шушы җирлек суын эчеп үскән, җыр-моңга, үзешчән сәнгатькә гашыйк авылдашларын үзенең талантлы канаты астына җыеп, Уразай авылы мәдәниятен утыз алты ел буе шаулатып яшәтә Тәнзилә апа. Татарстанда гына түгел, Бөтенсоюз фестиваль-бәйгеләрендә төрле дәрәҗәләргә, лауреат исемнәренә лаек булган авыл үзешчәннәре. Әгерҗе районында беренче булып курчак театрын оештырып җибәрә Тәнзилә апа. Җырларга да бик оста ул. Ә Бибел абый гел янәшәсендә була. Алай гынамы – сәхнәдә куелган һәр спектакльдә диярлек төп рольләрне башкарган әле!

– Авылда спектакль куябыз дип әйтүе генә җиңел. Тавык чүпләп бетермәслек көндәлек мәшәкатьләрен калдырып, репетицияләргә йөрү, аннары ул спектакльләр белән тирә-күрше авылларга чыгып китү өчен вакыт табу җиңел түгел авыл кешесенә. Артистларны эзләү, рольләрне бүлү дә минем өстә. Бибел, әлбәттә, иң беренче риза булып алына бу рольләргә. Аннары башкаларны тарту да җиңелрәк. «Рәйсә апалар, Бибел абыйлар уйныйлармы?» – дип сорыйлар да, уңай җавап алгач, бик теләп риза булалар. Бибел куеласы спектакльгә үзенчә бер дәрәҗә биреп тора иде. Тамашачы да бик яратып карый ул уйнаган рольләрне, – ди Тәнзилә апа.

– Сәхнә шундый әйбер ул – бер тәмен белгәч, төшәсе дә килми. Минем әткәй дә авылдашлар белән куйган «Галиябану» спектаклендә Хәлил ролен уйнаган. Сәхнә өчен һәрвакыт саллы, мәгънәле, классик әсәрләрне сайлый идек. «Тамырлар», «Язылмаган законнар», «Хаҗи әфәнде өйләнә» пьесаларында төп рольләрне башкардым. Әле дә рәхәтләнеп уйнар идем. «Мулла бабай сәхнәгә менгән» дип көләрләр, дим, – дип шаярта Бибел абый.

Ә күзләрендә очкын кабынгандай була...

Тәнзилә апа исә кайнанасы Рабига апаны рәхмәт белән искә ала. Икесе гел бер сүздә булып, киңәшләшеп яшәгән кайнанасы һәрвакыт терәк була. Ул риза булмаса, икәүләшеп клуб, мәдәният, сәнгать дип гомерләренең саллы өлешен эшләренә багышлый да алмаслар иде. Килен белән кайнана арасына читләрнеке түгел, хәтта Бибел абыйның да сүзе үтә алмаган. Шулай булмаса, утыз ике ел бер тавышсыз матур гына яшәп булыр иде микән?! Кайнанасы Рабига апа бакыйлыкка күчкәч: «Синең биемең бар идемени?» – дип аптырап сораучылар да булган әле авылда.

Хәзер инде алар, үзләре әйтмешли, биатай белән бианай. Бибел абый авылның мулласы, уллары Инсаф – «Елабугагаз» идарәсендә эшли, мәчеттә мөәзин. Киленнәре Венера да Тәнзилә апаның бәхетенә, аңа алмашка үскән кыз бала. Бүген ул авыл мәдәният йортын җитәкли. «Аллага шөкер, мәдәниятебез грамотный кеше кулында», – дип сөенә Тәнзилә апа югары белемле килененә. Алай да, сәнгать белән араларны өзми – әле дә төрле чаралар өчен сценарийлар яза. Кызлары Әлфия гаиләсе белән Түбән Камада яши, инде үзләре әбибабай... Төп йортның баскыч төбендәге тальянны күреп, эчтә бер җылылык уяна. «Гармунчы гына булмадым», – дигән иде бит Бибел абый.

Бу тальянда оныгы Инзил «Ай, былбылым»ны көйли хәзер... Үзе өйрәнгән!

Әнә шулай китапча, дөрес итеп яшәргә тырышулары гомерләренең иң мөһим китабын язуга юл сала барган да инде Ибраһимовларның...

Кыска сүзле, оста куллы...

Бүген Уразай авылында сиксәнләп хуҗалык бар. Җәйгә генә кайтып яшәүчеләр дә, лаеклы ялга чыгып, тулысынча күченеп кайтучылар да бар арада. Туган нигезләре белән араларын өзмичә яшәргә тырышучы андый авылдашлар да авылны яшәтергә көч бирә әле. Түбән Кама шәһәреннән кайтып төпләнүче, мәчеткә йөреп бик матур яшәүче Альмира һәм Фаяз Ганиевлар гаиләсен дә бик җылы кабул иткәннәр Уразайда. Әбибабасы нигезе урынына яңа йорт торгызган оныклары – Гөлнара һәм Илдар Махъяновлар гаиләсенә ничек сокланмыйсың?!

– Авыл җанлансын, яшәсен өчен фәкать бер әйбер кирәк. Ул да булса – эш урыннары. Күрше Ямурза авылында «Прикамнефть» идарәсе уңышлы эшләп килә.

Анда йөреп эшләүчеләр күп бездә. Ә менә эшмәкәрләр аз... Калганыннан зарланырлык түгел. Өр-яңа мәдәният йорты, кибетләр бар, Сабантуйлар бик матур уза... Бүген: «Авыл бетте, зиратына кайтып дога кылып кына килә алабыз», – дип, туган авылларын сагынып искә алырга гына калган кешеләр дә бар бит... Минзәләдә, әнә, монда авыл булган, дип, истәлек тактасы куеп киткәннәр бер авыл урынына... Бездән ерак түгел Ырыс авылы су астында калды, агачларының очы гына күренә хәзер. Шул агачларны гына булса да күрик дип кайталар нигезләре булган җиргә... Ә без, шөкер, бик әйбәт яшибез, – ди Бибел абый.

Башлангыч мәктәптә инде ике генә бала укый, диләр... Шуның берсе – Ибраһимовларның оныгы Инзил. Ничек тә дүртенче сыйныфны шушы мәктәптә укытып бетерәсе иде дип телиләр. Ә аннары мәктәп бинасына яңа сулыш өрергә хыяллана Ибраһимовлар:

– Мәктәп эшләп торса, бик күңелле – сүз дә юк. Ләкин ябыла калса да ул бинаны буш тотмаска исәп. Мәктәптә музей ачарга дигән ният бар. Мәдәният йортында якташыбыз – шагыйрь, язучы, Удмуртиянең атказанган журналисты Ринат Баттал музеен ачып җибәргән идек. Кечкенә генә бүлмәдә урнашкан ул. Музейны киңәйтеп, мәктәп бинасына күчерер идек. Авыл тарихына, күренекле якташларыбызга багышлап ачылган музей авылның тагын бер бизәге буласына шик юк. Гомумән, Уразай – Гариф Ахуновның «Идел кызы» романына кергән авыл ул. Гариф абый безнең авыл кияве бит. Романда Зартугай исеме белән язылган авыл – безнеке инде! Бөтендөнья татар конгрессында җаваплы вазыйфа башкаручы егетебез Фәрит Уразаевның, Мәскәүдә «Татар штабы» җитәкчесе Рөстәм Ямалиевның тамырлары безнең авылга барып тоташа, конгрессның Әгерҗе бүлекчәсен җитәкләүче Вәсилә Хәкимова да безнең авыл кызы. Татарлыкны саклаучы никадәр шәхеснең юл башы безнең авылда!

Ниятләгән эш – башланган эш Уразайда. Сүзең кыска булсын, кулың оста булсын! Авылга нур өстәп торучы Аллаһ йортын ике айда җиткереп чыктык, дип куанулары тикмәгә түгел. 1891 елда төзелгән Уразай авылы мәчете 1926 елда ябып юкка чыга... Сиксән ике ел үз хәерле сәгатен көтеп яткан яңа мәчетне төзү идеясен авылдашлары Наилә ханым Нурмиева алып кайта:

– Район кулланучылар берләшмәсендә эшли идем әле, район мөхтәсибе, хаҗи Мөхәммәтазат хәзрәт шалтыратты. Сезнең авылда гына мәчет юк, ди... Иң беренче Бибел абый белән элемтәгә кердем. Җиткерик әле, дим. Бибел абый тормыш күргән кеше, эшнең никадәр авыр булачагын чамалый. Шулай да тотынырга риза булды, ә ике айдан инде мәчеттә беренче азан яңгырады.

Рәхмәт төшкереләр

Тәнзилә апа – Уразайга төшкән әнә шул рәхмәтнең берседер, мөгаен. Авылдашларының: «Исән килеш үзеңә һәйкәл куйдың!» – дип әйтүләре юкка түгел. Сәнгатькә хезмәт иткән елларында тагын бер үтә дә кирәкле эш алып бара ул. Төрле чыганаклардан авыл турында табылган язмаларны, фотосурәтләрне, төрле материалларны әкренләп туплый башлый. Үзешчән сәнгать тормышыннан башлап, авыл кешеләре, авылның үзе, тарихы турындагы барлык мәгълүмат хәйран гына материал булып җыела.

– Җыйган чакта китапка кирәк булыр дигән уй бөтенләй юк иде ләбаса. Музейга булса да бирермен дип җыеп куя идем. Газетада райондашыбыз Раиф Мәрданов үз авыллары тарихын язган дигән хәбәр күзгә чалынды. Туктале, дидем, бу материаллар миннән башка тагын кемгә кирәк булыр, дип, китапка тотындым. Күрше Салагыш авылы музеенда да Уразай турында материаллар бик күп. Аларны да кулландым. Китапка тотынырга да тәвәккәллегем җитмәс иде әле. Наиләнең сүзе этәргеч бирде. «Яз син аны, Тәнзилә апа, бергәләп эшләрбез», –

Белешмә

Әгерҗе районындагы Уразай авылы Кама белән Иж елгалары уртасында урнашкан һәм элеккеге байлар волосте – Салагыштүбә берәмлегенә кергән. Салагыш авылын 1600 елда шушы нәселдән булган Җанчуриннар салганлыгы документларда теркәлеп калган. Әмма ләкин Кама аръягындагы җирләр Җанчуриннар артыннан 1567 елда ук теркәлгәнлеге турында мәгълүматлар саклана. XIV–XV гасырларда, Казан ханлыгы чорында ук, алар бу якларда җир милкенә хуҗа булган дигән фикер бар, һәм шул сәбәпле, бу якларга яңадан кайтып төпләнгәннәр дә. Моның шулай булуын Уразай авылының ике зираты – иске һәм яңа зиратлары, андагы кабер ташлары да раслый. Халык телендә йөргән сүзләргә караганда, Иван Грозный Казанны алганнан соң, чукындыру максаты белән бу якларга да килеп җитә. Ямурза авылы (борынгы документларда Янморза) кешеләрен көчләп чукындыралар, авыл башына тәре баганасы утыртып калдыралар. Иртәгәсе көнгә тирә-як авыл мөселманнары, җыелышып, тәреле баганалы яндырып юк итә... Архив мәгълүматлары буенча, Әгерҗе районының Уразай авылында туган Уразмөхәммәт бәк 1650 елда Сарман районыннан җир сорап гариза яза. Бу язмадан чыгып, Уразай авылының 1650 елдан да күпкә элегрәк барлыкка килүе аңлашыла. Башта Уразай авылы (элек Кече Салагыш дип йөртелгән) буласы урынга Уразмәт атлы кеше гаиләсе белән килеп урнашкан. Бу урында зур күл, куе урманлык булган. Революциягә кадәр Уразай авылында бер мәчет, бер мәдрәсә эшләгән. Гәбделҗәмил Максудов авылның мулласы һәм укытучысы булган. 1926 елда мәчет ябып, авыл мәчетсез калган.

Уразмөхәммәт карт нигез салган Уразай авылы бишенче гасырын яши дигән сүз. Шул чор эчендә патша хөкүмәтенең җәбер-золымнарын, фетнә-баш күтәрү сугышларын, халыкларны буйсындыруларын, көчләп чукындыруларын, милләтне юк итәргә тырышуларын күргән бай тарихлы авыл ул.

«Чал тарихлы Уразаем» китабыннан алынды.

диде. Мин язып әзерләгән материалларны дүрт сумкага тутырып алып китте дә, китап итеп алып кайтып бушатты, – дип сөйли Тәнзилә апа.

«Наилә ханым Нурмиева – авылның беренче сортлы патриоты. Бөтен идеяләрнең генералы ул», – ди аның турында Бибел абый. Озак еллар район кулланучылар җәмгыятен җитәкләгән. Төп яшәү урыны Казан булса да, күңеле һәрчак Уразайда Наилә ханымның. Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлары истәлегенә ясатылган обелиск та – аның хезмәт җимеше. Авылга яңа мәдәният йорты төзү мәсьәләсен хәл итүдә дә читтә калмый ул. «Чал тарихлы Уразаем» китабының дөнья күрүендә дә Наилә ханымның ярдәме бик зур.

– Китапка бер нигез дә, бер нәсел дә кермичә калмады, бөтен авыл тарихын колачладык. Картасын, схемасын да керттек. Авылның горурлыгы булган шәхесләребез дә урын алды. Язу эшләре өч елга сузылды. Фотосурәтләрне авылдашлардан сорап алдым, китереп үк бирүчеләре дә, игътибар итмәүчеләре дә булды. Алары соңыннан, китап чыккач, үкенде инде... Шулай да, мин бу китапка кермәгәнмен дип әйтүче бер кеше дә булмады. Авылдашлар арасында: «Гомер буе күрше булып яшәдек, туган икәнебезне белмәдек», – диючеләр дә бар. Чыннан да, китап бик күп әйберләргә, тарихка күз ачты, – ди «Чал тарихлы Уразаем» китабы авторы Тәнзилә Ибраһимова.

– Уразай авылының тарихы бик еракка – морзалар нәселенә барып тоташа. Менә оныгым Инзил үзенең җиде буын бабасын белә хәзер – Тимерша, Тимергали, Ибраһим, Йосып, Гайсә, Бибел, Инсаф. Бер унбиш ел гына иртәрәк тотынган булсак, тагын да күбрәк белер идек, дим. Үз нәселеңне барлау, бабаларыңны белү алар белән киңәш-табыш итү дигән сүз дә әле ул, – ди Бибел абый.

Иң куанычлысы – Ибраһимовларның дүрт дистә елга сузылган бөртекләп җыйган хезмәте сандык төбенә төшеп ятмаган. Уразайда яшәүче һәркемнең өендә ул хәзер. Моның никадәр кирәкле, мөһим эш булганын китапны тәкъдим итү кичәсендә генә чынлап торып аңлый әле Тәнзилә апа.

– Китап 2020 елда әзер булды. Тагын да шул Наиләбезнең идеясен күтәреп алып, тәкъдим итү кичәсе оештырырга булдык. Ул очрашу хезмәтебезне башка югарылыкка күтәрде, чөнки чарага бабалары шушы авылга нигез салган Бөтендөнья татар конгрессының Татар эшмәкәрләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе Фәрит Уразаев һәм Бөтендөнья татар конгрессы киңәшчесе Ринат Закиров кайттылар. Бу кадәр үк зурлау, хөрмәт көтмәгән идем, – дип сөенә Тәнзилә Ибраһимова. «Чал тарихлы Уразаем» китабының икенче томы булырга тиеш! Тәкъдим итү кичәсенә килгән авылдашлар да, кунаклар да бер фикердә кала.

Хезмәтенә күрә – хөрмәте. Алтын туйларын матур гына каршы алып, инде үзләренең зөбәрҗәт туйларына ишек шакучы Бибел абый белән Тәнзилә апага Ходай сәламәтлек бирсен. Икесе дә хезмәт ветераны алар, эш рәтен беләләр. Яшәтәләр әле авылны!



Фәрит УРАЗАЕВ,
Бөтендөнья татар конгрессының Татар эшмәкәрләре белән эшләү бүлеге җитәкчесе, Милли Шура әгъзасы

Эш буенча эшмәкәрләр белән күп аралашырга туры килә. Аларның һәммәсеннән диярлек: «Шәҗәрәңне беләсеңме? Авылың тарихын яздырдыңмы? Мәчетләр тарихын яздырдыңмы?» – дип сорыйм. Тарихын китап итеп чыгарган татар авыллары киләчәктә: «Җир милке кемнеке?» дигән сорауга төгәл җавап бирә алачаклар. Ул үзенә күрә паспорт ролен үти.

Балигълык яшенә җиткәч, кулыма бабайларның шәҗәрә китабын тоттырдылар. Шуннан бирле һәр блокнотымның беренче битенә җиде буын бабаларымның исемен язып куям. Нәселебез Әгерҗе районы Уразай авылына нигез салган Уразмөхәммәт бабайга барып тоташа. Оныгым инде – Уразаевларның унберенче буыны. Шунысы хикмәт, Уразайга кадәр, тагын унбер бабаның эзенә чыктык. Боларның барысын да теркәп, сигез ел дәвамында нәсел китабын язу белән мәшгуль без. Шәҗәрә буйлап нәсел җирләрен, хокук бирүче документлардагы тамгаларны, авыллар һәм мәчетләр тарихын, аларның социаль катламнарын тикшереп, биш яклап распадык, документаль тикшердек, хәзер монография формасында нәсел китабын әзерлибез.

Нәселең, авылың, милләтең тарихын белү – үзеңне тиңләштерү ул. Шәҗәрәсен белгән кеше үзе артында гасырлар буена сузылган рухны тоя. Буыннар хәрәкәтен, шәхесләр хәрәкәтен өйрәнсәк, татар милләте бернинди җилләргә дә бирешми әле. Тәнзилә апа Ибраһимова менә шундый мөһим хезмәт башкарып чыкты.

Уразай авылы – безнең нәсел шәҗәрәсе тарихында төп нокталарның берсе булып тора. Шуңа күрә «Чал тарихлы Уразаем» китабын тәкъдим итү очрашуына да бик рәхәтләнеп кайттым. Китап уразайлыларның гына түгел, татар милләтенең затлылыгын күрсәтә. Авыл тарихында буыннар чылбырын саклаучы мәгълүмат буларак зур кыйммәткә ия ул. Үз тарихына гына түгел, янәшәдәге башка авылларга да кагылып үтә. Нәсел җирләренә ачыклык кертә... Нәселне җиреннән аеру өчен, 30 нчы елларда Себергә сөргәндә, бабамны «Уразаев Мөхәммәтзариф Уразаевич» дип теркәгәннәр, ягъни әтисенең исемен тарихтан төшереп калдырганнар. Нәсел җебен өзү өчен, нәсел җирләренә дәгъва кылмасыннар өчен эшләнгән бу. Безнең элеккеге нәсел җирләре кайчандыр Кама елгасының ике як ярын, аңа коючы Ык елгасының, Минзәлә елгасының ике як яры буйларын иңләгән. Бу җирләргә кагылышлы документлар өч өлештән торган, алар бүген дә саклана.

Шунысы кызык, Уразай белән янәшә урнашкан Салагыш авылы музеенда һич көтмәгән табышка дучар булдым. Бабаларым нәсел җирләре өчен хокук яклаганда, җирнең картасын булдырып, тамгалар сукканнар. Әлеге картаның төп нөсхәсе 1703 елда суд материалларына теркәлеп куелган, һәм бүген шул 300 еллык карта үзе Салагыш музеенда саклана! Салагыш елгасы суы да, Уразай авылы да, андагы кабер ташлары да, алардагы тамгалар да бик зур мәгълүмат чыганагы. Авыл тарихы милләт тарихына барып тоташа. «Чал тарихлы Уразаем» китабының кыйммәте дә шунда. Мәртәбәле хезмәт башкарган Ибраһимовлар. Уразайга кайткач, урамнарын йөреп чыктым. Авылга кайтучылар бар, йортларны яңарталар – күңелле моны күзәтү. Авыл эчендә җир эшләсә, авыллар яши әле. Җир кадере китмәсен иде...

PRESSA

30 ЧАКРЫМ ТУКЫМА

Алсу ЗАҺИДУЛЛИНА

Барысы да нияттән һәм... 10 метр тукымадан башлана. Үз эшенә алынырга теләк белдергәч, ире Лилиягә бер генә шарт куя: бу дөнья өчен генә түгел, ахирәт өчен дә саваплы шөгыль булсын.

Бүген «Amira» мөселман хатын-кызлар киемнәре кибете хуҗалары Лилия һәм Эльдар ҖИҺАНШИННАРның бөтен тормыш рәвеше шул максатларына хезмәт итүгә багышланган. «Halal life style» бу гаилә өчен заманча төшенчә генә түгел. «Amira» социаль проектына бәйле эшчәнлекләре – хәләл тормыш рәвешенең асыл үрнәге.

Тормыш Лилияне бу эшкә кечкенәдән әзерләгән диярсең. Себер якларында тайга уртасында диярлек туган кыз баланың холкына табигать үзе дә йогынты ясамый калмаган, билгеле. Малайлар эше дип тормый, бакча йортын күтәргәндә дә әтисе белән беррәттән эшли Лилия. Әхәт абый өч кызын да кечкенәдән эшкә өйрәтеп үстерә. Әтисенең инженер-конструкторныкыннан ким булмаган фикерләү сәләте белән теләсә кайсы эшне искиткеч башкарып чыга алуына әле дә соклана Лилия. Үлчәп, өлге кисеп, кызлары өчен бөтен киемне үзе тегә бит ул! Иренми, кызларын да кул арасына кертә.

– Мәктәптә укыган чакта ук әнидән инде киелми торган киемнәрне сорап алам да, шуларны сүтеп, үземнең үлчәмгә өлге ясап, тегеп кия идем. 90 нчы еллар булса да, 1 сентябрьгә мәктәпкә киярга һәрвакыт яңа кием була иде минем – үзем теккән кием, – дип искә ала үсмер чагын Лилия.

Иң беренче тегү машинасын олы кызы Самира тугач ала ул. Тукыма өстенә җәйләп кына тигез юллар салып, хуҗалыкта вак-төяк тегү, бөгү өчен хезмәт иткән җиһаз Җиһаншиннарның гаилә бизнесына беренче юлларны салырга да ярдәм итә (алга китеп булса да әйтик, ул тегү



ENSAR кибете
**Париж Коммунасы ур. 25/39.
10.00–19.00 сәгатьләрдә ялларсыз эшли.
8-917-892-66-21**

AMIRA кибете
**Җиңү проспекты, 206.
8.00–18.00 сәгатьләрдә ялларсыз эшли.
8-917-892-66-23
odejda_amira13**









машинасы әле дә җаваплы вазыйфа башкара – элмәкләр ясыйлар анда).

– Әнием кебек инглиз теле укытучысы булып эшли идем. Гади кибетләрдә кием бәясе алмаслык та түгел, ә менә мөселман хатын-кыз киемнәренең бәясе тешли торган. Күз алдына китерәсезме: минем бер айлык хезмәт хакына бер күлмәк тия. Шул ук күлмәккә 20 сантиметр тукыма гына өстәп тегәләр югыйсә... Нигә бәясе биш тапкырга арта икән дип баш ватканнан соң, үзем тотынып карарга булдым. Кием мәсьәләсе мине генә түгел, дусларымны, танышларны да борчый иде бит.

Яулык астыннан кия торган баш киемнәренә тотынырга хәл итәләр. Аларның шулкадәр кирәк булуын аңлап, үзләре дә хәйран кала – бөтен кеше сорый! Аннары беренче күлмәкләрне тегәргә алыналар. Моның өчен башта 10 метр тукыма сатып алалар, аннары 20, 50, 100... Хәзер «Amira» җитештерү бүлеге ай саен 30 чакрым тукыма эшкәртә!

– Шундый масштабка чыгасыбызны ул вакытта күз алдына да китермәгән идек. Иң мөһиме – клиентларга ательеда кием тектерү белән чагыштырганда, бәясе арзанрак булсын дип тырыштык. Бернинди инвестицияләр турында сүз дә булмады, хезмәт хакыбызга башлаган эш иде бу безнең. Үземне хәтерли башлаганнан бирле руль артында инде мин: барып сайлыйм, төяп алып кайтам тукымаларны. Эльдарның үз эше дә җитәрлек, ул вакытта мәчеттә имам вазыйфасын башкара иде. Ә төпчегебез София – нибары бер айлык кына, – дип искә ала ул елларны Лилия...

Гаилә бизнесы белән идарә итү, аны социаль проект буларак алып бару эшенә Эльдар үзе алынгач, уңыш озак көттерми. Тугыз еллык хезмәтнең нәтиҗәсе бүген искитәрлек. Россия буйлап алты кибет ачыла, утыз кешелек 300 квадрат метрлы җитештерү цехы эшләп килә. Дөнья буйлап онлайн сату системага салынган, маркетплейслар үзләштерелгән. Ай саен унбиш меңгә якын эшләнмә саталар. Кибет исемен язуга, теләсә кайсы социаль челтәр аша исемлектә «Amira» кибете иң беренче килеп чыгуга ирешәләр. Клиентлар өчен онлайн заказ бирү бик уңайлы: минутында ук диярлек менеджер сезгә җавап бирәчәк. Складта сез теләгән киемнең булу-булмавын төгәлләп, кирәкле киемне шул ук көнне җибәрәләр дә. Бәби көтәсезме сез, бала имезүче әниме, үлчәмегез стандарт размерларга туры килмиме – боларын да менеджер белән туры элемтәдә хәл итәргә мөмкин. Үзегез теләгән тукыманы сайлап, үлчәмнәрегезне әйтеп, махсус тектерү мөмкинлеге дә бар. «Россия почтасы» «Amira»ны VIP клиентлар исемлегенә керткән. Заказлар цехтан туп-туры аэропортка юл тота һәм икенче көнне үк диярлек клиентка барып ирешә. Ничә намаз күлмәге, буркини, «слимфит» күлмәк сатканнарын исәпләп чыгарырга кызыгалар үзләре. Мөмкин микән? Болар – хит! Болар – «Amira» горурлыгы! Дөньяның астын өскә китергән пандемия да хәерле эшкә киртә тудыра алмый хәтта.

– Ковид белән бәйле чикләүләр чорында ябылганнан соң, алты кибетнең икесен генә яңадан ачтык. Аның каравы, онлайн сату системасын үзләштердек. Татарстанда яшәүче мөслимәләр генә түгел, Россия, БДБ илләреннән үк безнең эшләнмәләргә заказ бирә башладылар. Географиянең киңәюе клиентлар санын да арттырды. Безнең традицияләргә бөтенләй бәйле булмаганнар да безнең киемнәрне сайлый икән! Мөселман кием сферасы хәзер зур үзгәрешләр кичерә. Элек матур принтлар белән катлаулы конструкцияле, декорлы, бәйрәм күлмәкләре тегелсә, хәзер клиентлар гади киемгә өстенлек бирә. Яшьләр арасында популяр булган «Sports casual» стилен аларның әниләре дә бик якын итә. Элек киемнең озынлыгын үкчә биеклеген исәпкә алып тексәк, хәзер кроссовкалар белән киелгән заманча образ өчен кыскарак тегәргә туры килә. Сату үзәкләрендә тәкъдим ителгән киемнәргә анализ ясыйбыз, шул стильдә иҗат итәбез. Бездә дә шул ук база коллекциясе бар, мөмкин кадәр дөньяви киемнәргә якынлаштырылган алар. Гардероб концепциясен үзгәртми диярлек, шәригать буенча киенеп йөрү мөмкинлеге дә бирәбез.

Лилия үзе һәрвакыт диярлек җитештерү үзәгендә кайный. Озак еллар дәвамында төзелгән командалары инде эшне аннан башка да алып бара ала югыйсә. Бөтен тәҗрибәсен эшләүче кызларга түкми-чәчми тапшырган хуҗабикә һәр бүлек эшен иң беренче чиратта үзе өйрәнеп, үзе җайга салган. Эльдар киңәше белән дизайнер-конструктор белгечлеген үзләштерергә дә җитешкән.

Эшләре генә түгел, гаилә дә үсеш кичерә бу елларда. «Amira»да беренче адымнарын өч кызлары белән башлаган булсалар, бүген алты кыз үстерәләр! Мәрьям, Сара һәм Ясмин инде гаиләгә бөтенләй башка шартларда килгән балалар. Гаиләнең яшәү рәвеше кызларга да сеңми калмаган. Олылары инде үзләрен производствода сынап карыйлар, көчләреннән килгәнчә ярдәм итәләр. Самира заказлар кабул итә белә, SMM-белгеч буларак, социаль челтәрләрне дә алып бара. Сеңлесе Әминә белән үсмерләр арасында «Worldskills» чемпионатында «Мода технологияе» номинациясендә җиңү яуларга да өлгергәннәр. Кием тегү процессын тулысынча башкарып чыга алырлык кызлар үсеп килә Җиһаншиннарда!

– Кешенең яшәү рәвеше тулысынча диярлек әти-әниләр үрнәгендә төзелә. Эш буенча да сизелә ул: гомер барган саен, хатын-кыз әнисе, әбиләре киенеп йөрү рәвешенә, шул гореф-гадәтләргә әйләнеп кайта. Күзәткәнегез бармы: үз тамырларын онытып, башка халыклар мәдәниятенә кызыгып, Европача яшәргә тырышучылар еш кына тормышта үзләрен югалта, адаша. Безне без итүче сыйфатыбыз нәкъ менә шул нәсел үрнәге, буыннар чылбыры, туганлык җепләре бит инде. Тагын... Намус белән эшләү! Үзеңә, туганнарыңа, дусларыңа, күршеләреңә, хезмәткәрләреңә карата намуслымы син? Уңай җавап бирә алсаң, димәк, эшләп алган ризыгың да хәләл булачак. Балаларга шуны сеңдереп каласы иде... Беребез дә мәңгелеккә килмәгән. Яннарында булмасак та, күз алларында безнең үрнәк калсын дип телибез. Бик мөһим бу...

Шунысы кызык, Җиһаншиннар җитәкчелек иткән коллективта беркайчан да ачык вакансияләр булмый икән. Эшкә урнашырга теләүчеләр чират тора, диләр. Ә тукыма чакрымнары... Утыз белән генә чикләнмәс кебек әле!

Фото: Анна Арахамия

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

PRESSA

Аның үзен дә китабының исеме белән – «Карурман миләүшәсе» дип атыйсы килә. Серле, нәфис, якты ул. Һәм талантлы! Лирик-психологик хикәяләрендәге мәхәббәт тарихлары, кайнар хисле үзенчәлекле шигырьләре, фәлсәфи мәсәлләре белән укучылар күңелен яулаган Лилия Фәттахова – Яңа Чишмә якларыннан, Чаллы Башы кызы. Казан дәүләт педагогика университетының тарих-филология факультеты, Яңа Чишмә гимназиясе, район мәгариф бүлеге, Чаллыдагы «Шәһри Чаллы», «Көмеш кыңгырау» газеталары редакцияләре... Болары – Лилиянең кичәгесе. Бүген ул «Мәйдан» журналының баш мөхәррире. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия лауреаты.


Лилия ФӘТТАХОВА

ШИГЫРЬЛӘП ТАМДЫЛАР ЯШЬЛӘРЕМ

Сизәсеңме, иркәм?

Ямь-яшь айны
якты сагышыма
урадым да
бәллү-бәллү итәм...
Яратуым сыман нарасый ул.
Син күрдеңме, иркәм?

Төпсез галәм
йөрәк тибешемне
ишетте дә тынды...
Сөенчегә –
йолдыз белән чиккән
кулъяулыгын сонды...

Юк ла инде,
бәхетемнән генә
күз яшемне сөртәм...
Тулган айдай йөзем.
Багам күккә...
Сизәсеңме, иркәм?

* * *

Ялгышамдыр...
Ә кем ялгышмый соң?!
Мин фәрештә түгел...
Кешедер...
Өлешемә тигән юлларымда
Көл астында
утлы күмер калса,
Бу да, бәлки, иң зур эшемдер...

Турыла!

Юлларыңны йөрәгеңә карап
Турыла син... Йөрәк укларына!
Кемнең барлыгына дертләп куяр,
Һәм сискәнер... кемнең юклыгына.

Юклык ешлыгында дөм-караңгы.
Кемнәр адашмаган ул ешлыкта?
Кемнәр, хаталардан сукмак түшәп,
Килеп егылмаган шыр бушлыкка?!

Ә син саклан кабат ялгышудан.
Кабаланмый гына ашык, яме.
Икебезгә тик бер сорау хәзер:
«Йөрәк угың миңа төбәлгәнме?»

Хушлашу

Акыл аңлый шулай кирәклеген,
Йөрәк кенә кабул итә алмый.
Бербөтенгә әйләнәлми калган
Китек дөньям әрнү булып ауный.

Бу көзен дә әйтер идем инде!
Яшен коя, карның өнен алып.
Ноябрьнең соңгы көне сыкрый
Сыза барган бер сөюне танып...

Хушлашабыз. (Нинди котсыз сүз бу!
Дөньяң түгел, җаның кыеп үтә.)
Хушлашабыз... Вакыт чырагында
Туар көннең бәхтен өтә-өтә...

* * *

Сүз катмыйча торалырмын әле,
Торалмам шул сине уйламыйча.
Кузгатмыйча күңел бураннарын,
Шул буранга кереп югалмыйча.

Сиңа дигән хисләр, өермәдәй,
Йөрәгемнән чыгып качар кебек.
Нәзберек тә, самими дә дөньям
Ишекләрен тутырып ачар кебек.

Сүз катмыйча торалырмын әле,
Боерырмын шашкын йөрәгемә.
Уйламыйча ничек түзим икән?
Уйларым да «син» дип тибә менә.

* * *

Адашып карадым...
Үземә-үзем үк
алдашып карадым.
Мин, дидем, болай да бәхетле.
...Шигырьләп тамдылар яшьләрем.
...Ә Сөю дәшмәде.
Ул йөргән юлларда ялган юк.
Ул йөргән юлларда
кыл кылга ялгана,
Бәхеткә ялгана Җанүзәк.
Ә болай... кирәкми.
Ә болай... әрнетә.
Ә болай – күңелдән
кыл өзү...

Ярасыннан дәвасынача

Язы-көзе бергә
минем көнделдә.
Җәе-кышы...
Сыешалар алар
хәтта бер көнгә –
Чиратлашып...

Беләм,
тагын үпкәләттем үзеңне.
Беләм...
Таныйм.
Иске яра касәфәте инде бу –
Һаман каный...

...Тып-тын гына
җиргә яфрак коела.
Алар миңа
ишләрем күк тоела...
Ватык сәгать түгел ул,
Вакыт – төзек.
Ярасыннан дәвасынача түзик...

Таныш без

Мин бит сине
Бик күптәннән беләм.
Төрле чагың беләм,
Сер капчыгы!
Тик һаман да әле
белмим кебек:
көн туугa
тагын ни ачылыр?!

Башка беркем белән
бу кадәрле
таныш түгел,
тынышалсам да мин.
Сиңа карышуы авыррак,
чит кубызга –
карышалсам да мин...

Уйларыңның
иңен-буен беләм,
тирәнлеген беләм –
белми, димә!..
Хисләреңнең пәрәвезе генә
ниләр тартачагын
белмим менә.

Алтын табам кайчак,
Кайчак – чүп-чар
пәрәвезнең
елтыр челтәреннән.
«Минме соң бу?!» дим дә...
танып алам...
Үзем шул бу...
Беләм бик күптәннән.

Бүлем-бүлем түгел дөнья

Нинди читлек эчендә син,
минем җаным?!
Рәшәткәләп күрмә әле
син дөньяны.
Бүлем-бүлем түгел дөнья,
бербөтен ул.
Син дә, әйдә, шул дөньядай
бербөтен бул.

Нигә һаман боек соң син,
минем җаным?
Мәрткә китәр-китмәс ага
тәндә каным...
Фани гомрең кыскартмачы
тагын да син,
пышылдама колагыма... сорап Ясин...

Кайсы уйның элмәгеннән
чыгалмыйсың?
Кайсы яраң әрнүенә
чыдамыйсың?..
Күбәләктәй очар өчен җилпенмәле...
Бу – бары тик
ялгызлыкның читен мәле...

* * *

Утны яктылык дип уйлап,
Шул яктыга таба
Ашыга-ашыга канат җилпи
Күбәләк-җан.
Канатының өтеләсен тойсаң,
Туктат аны, инсан!

Уен тәмам

Уен тәмам, дидем.
Алкышладым.
Кызды учым –
Учтан кыйналып.
Учтан үчне алыйм инде, әйдә!..
Башланган роль бетсен уйналып.

Уен тәмам, дидем.
Алкышладым!
...Фальш сиздем.
Соңлап булса да...
Пәрдәләрне үзем төшерермен! –
Сүзсез рольдә уйнап булса да...

Уен – тәмам инде.
Сизәм – тынга
бераз ялган капкан. Сулатмый...
Бар ул җирдә тормыш, диләр иде...
Дөрес микән соң ул?..
Чынлапмы?!.

Нинди төстә икән?

Нинди төстә икән
синең дөньяң?..
Менә бүген?
Менә шул минутта?
Ут төсендәдер ул –
Юкка гына
салмыйсыңдыр мине
уттан утка...
Челтер чишмә төсендәме икән?..
Әйе... әйе...
Үтә күренмәле! –
Миңа анда бар да
ачык кебек.
Тик...
сөюең генә күренмәде...

Карурмандай микән
синең дөньяң?
Куе кара?!
Юк, юк!
Яшелдән ул!
Тере аның
һәрбер күзәнәге.
Тик... беразын
никтер яшергән ул.

Томан төсендәме
синең дөньяң?
Менә бүген...
Менә шул минутта?..
...Сер пәрдәсен
тыным белән ертам...
Тик... куркыта бераз.
Тик... куркыта...

Уйламаган борылышлар

Уйламаган борылышлар...
Көтелмәгән шатлык...
Чал Чулманның тын ярында
Без дә учак яктык.

Янып бетсен әрнү-сагыш,
Тик... янмасын йөрәк.
Көлләрдә дә гөл күрүче
Уяу җаннар сирәк...

Уйламаган борылышлар...
Көтелмәгән шатлык...
Чал Чулманның тын күгендә –
Каурый-каурый аклык...





Люция ФАРШАТОВА

Ул – бөтен барлыгы белән журналист. Укучылары аны «Ватаным Татарстан» газетасы хәбәрчесе Люция Фаршатова буларак яхшы хәтерлидер. Чөнки аның бармаган районы, кузгатмаган темалары калмады. Хатлар бүлеге, авыл хуҗалыгы, сәясәт һәм мәгариф бүлекләре... Ул колачлаган өлкәләр болары. Медицина, пенсия, халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча никадәр сораулар, гаиләдәге мөнәсәбәтләр, гыйбрәтле язмышлар турында күпме хатлар килә редакциягә. Ә Люция – гел юлда, гел командировкаларда. Кешеләр, вакыйгалар, язмышлар, газета кысаларына гына сыймыйча, күңелдә хикәя булып бөреләнә башлый.

Люция Фаршатованың тормышчан хикәяләрен яратып укыйлар.

СОҢАРГАН ТУЙ

(Хикәя)

Зы-ың-ң! Чы-н-ң-ң-ң!!!

Телефон тавышына әллә нишләп сискәнеп китте Резедә. Дөп-дөп итеп йөрәге дулап алды, чигәләре тартышып, сулыгып-сулыгып куйды. Әйтерсең ул ни дә булса хәбәр итә. Көненә дистәләрчә мәртәбә шалтырый бит юкса ул телефон. Нигә бу юлы шулкадәр мәет юраган козгын тавышыдай килбәтсез яңгырый соң аның тавышы? Әнә тагын: зы-ы-ың-ң-ң!

– Хәзер алам, ай Аллам ла, хәзер-хәзер, янгын чыкмагандыр ласа. Һай, кайларда шалтырый соң үзе? Йокы бүлмәсеннән киләме соң тавышы, залданмы? Ә-ә, биредә икән.

Резедә камырлы кулларын сөртә-сөртә телефонын алды. Улы икән лә, тавышы шулкадәр газиз.

– Әни, әни, дим, син өйдәме? Берәр нәрсә булмагандыр бит? Ник дип, озак алмый тордың бит. Без хәзер Инна белән безгә кайтмакчы идек.

Резедәнең кинәт кенә хәле киткәндәй булды. Лып итеп урындыкка утырды да, беркавым хәл җыеп торганнан соң гына улына дәште.

– Әйе, улым, тыңлыйм.

– Әни, син мине ишетәсеңме соң, ник дәшмисең?

– Ишетәм, балам, ишетәм. Ярый-ярый, бик әйбәт булыр, пәрәмәчләрем дә өлгерде, кайтыгыз, улым. Тукта, кем белән кайтам дидең әле, йөргән кызым белән дисеңме?

– Әйе, әни, Инна белән. Үзең ич, таныштыр да таныштыр дип аптыратып бетердең.

– Ие, улым, таныштыр дим шул...

Ниндидер хәерсез көн, ахры, бүген. Резедә, каударланып, әле чәйнеккә барып тотынды, әле көзгегә күз салды. Халатына күзе төшеп, аны алыштырырга дип йокы бүлмәсенә йөгерде: булачак киленне болай гына каршыларга ярамас, бераз бизәнеп-төзәтенеп алырга кирәк. Борынына көйгән ис бәрелеп, кухняга йөгереп чыкса, газга эретергә куйган мае көеп маташа икән. Тиз генә газны сүндереп, калган камырын һәм итен җыештыра башлады. Пәрәмәчләренең бер генә табак икәнен күреп, кунак алдында оятка калмыйм тагын диядия, яңадан камырына тотынды. «Бигрәк аз булган бит бу, сеңелләр дә, сезнең якка барасыбыз бар, кайтканда кереп чыгарбыз дигән иде ләбаса», – дип сөйләнә-сөйләнә берничәне ясап кына өлгерде, ишек ачылган тавыш ишетелде.

– Әйдә-әйдә, курыкма, минем әни заманча әни ул, берни дә булмас. – Иң беренче улының тавышы ишетелде, аннары кыюсыз гына җаваплаган кыз бала тавышы колагын сагайтты.

– Барыбер куркам.

Аларны каршыларга ашыккан Резедә кызның тавышында ниндидер таныш аһәң ишеткәндәй булып, йөрәген тагын нидер «чеметеп» куйды. Ник икәнен үзе дә аңламыйча, күрешергә дип сузган кулын да тиз генә алъяпкычы астына яшерде. Аннары гына, ялгыш эшләгәнлеген искәреп, ике куллап күреште.

– Исәнме, кызым. Әйдә-әйдә, түрдән уз.

– Исәнмесез-с-с, – диде кыз, комачтай кызарып.

Һай Аллам, кайда ишеткәнем бар соң минем «з» авазын болай үзгә итеп әйткәнне, дип уйлап алды ана. Үзе, елмаерга тырышып, яшьләрне табын янына дәште.

– Әйдәгез, балалар, пәрәмәчләрем яңа пешеп чыкты. Әле Тәти апаң белән Алма апаң да кереп чыгабыз диделәр. Кибетләргә чыккан булганнар икән, сусаганнар, чәй куеп тор, дип шалтыраттылар, – диде ул озын буйлы, чибәр улына сокланып карап.

Чәй табыны әзерләгәндә Резедә тагын каушап калды. Әле тиз-тиз чәй ясады, әле плитәдә пешеп ятучы пәрәмәчләре янына йөгерде. «Әй Ходаем, тагын көеп яталар икән инде. Нинди көн булды соң бу?» – дип, үзалдына тиргәнә-тиргәнә яшьләр янына залга чыкты. Башка вакытта теле телгә йокмый, гел шаярып сөйләшә торган Ринаты да нигәдер боегып калган шикелле. Гадәттә сүзгә кесәгә керми торган ананың да, тел очында сораулары күп булса да, теле аңкавына ябышкан кебек.

Әллә ни чибәр түгел икән үзе, каен гөмбәседәй аксыл чырайлы дип уйлады Резедә, суынган чәен болгата-болгата. Бөдрәләнеп торган кап-кара чәчле, янып торган кара күзле чибәр улы дөньясын онытып нәрсәсенә гашыйк булды икән соң моның? Хәер, күзләре матур икән, каймалы, озын керфекләренә дә бернинди тушь-мазар кирәкми, болай да сөрмәләнеп торалар. Иреннәре дә кабарынкы, сусыллар. Мондый матур иреннәрне күптән түгел генә күрде ич әле ул. Кайда соң?..

Әй Ходаем, нишләп утыра соң ул, бәлки, бу кыз булачак киленедер, сөйләшергә, елмаерга кирәк ләбаса. Ә аның нигәдер үксеп-үксеп елыйсы килә. Улына да үпкәсе бар аның. Соңгы арада вакытын гел шушы чәчби белән үткәрә, өйгә соң гына – йокларга гына кайта. Аналарның язмышы шундыйдыр инде, бар гомерен шуларга багышлап үстерә дә багалмасын, аннары чит-ят кулларга биреп җибәрә. Тукта, нишләп җибәрә, аның улы киленне бирегә алып кайтачак. Фатирлары өч бүлмәле ләбаса: сыярлар. Әй лә, барыбер аныкы булмый инде ул, әнә бит сөйгәненә ничек яратып карый. Булдыра алса, йотар иде. Илгизәре дә шулай ярата аны, ярата... иде. Улы әтисенә охшаган. Үзсүзле булуы белән дә, тышкы кыяфәте белән дә. Аның кебек үк баһадир гәүдәле, каратут матур йөзле.

– Әни, әни, дим, нәрсә булды соң сиңа? Безне күрмисең дә, ишетмисең дә.

Улы аңа дәшә икән бит, ә ул дөньясын онытып утыра. Болай ярамый, үзеңне кулга ал, дип боерды үз-үзенә Резедә. Һәм көчләп елмайды.

– И-и улым, менә сезгә карап яшь чакларым искә төшеп китте әле. Була торган хәл, игътибар итмәгез. Бигрәк матур чагыгыз дип сокланып утырам.

– Әни, ни... Без сиңа өйләнешергә гариза бирүебез турында әйтмәкче идек. Бер айдан туебыз.

– Туй дисеңме, улым, кем өйләнә?

– Без, дим, ич, аңыңа кил инде, әни. Без кайтканнан бирле «әллә кайда» йөрисең.

– Ничек... сез?

– Әйе, без. Бер айдан туй, ресторанда. Акчаны әти түлим, диде.

– Ничек... әтиең түли, шул сөйрәлчек әтиеңме?

...

– ЗАГСка гариза бирдек дисеңме? Кемнән рөхсәт сорадыгыз? Әнигә бу хакта туйга бер ай калгач кына әйтәләрмени? И-и бала, бала...

– Сине алдан борчыйсым килмәде, әни. Аннан... Син рөхсәт тә итмәс идең.

– Итмәс идең дип... Синең тагын ике ел укыйсың бар бит әле. Аннары минем әле туй ясарлык акчам да юк. Күрәсең бит, фатирга ремонт ясыйбыз. Аның да әле очы-кырые күренми.

– Менә шул-шул...

– Нәрсә шул? Иң беренче бу хакта мин белергә тиеш түгел идеммени, мин бит – синең анаң! Тукта, нәрсә дидең әле, туйга акчаны әти бирә, дисеңме? Димәк, син иң беренче бу хакта аңа әйттең, аның белән киңәштең, ә?

– Ярар инде, әни, Инна барында алай сөйләшмик.

– Иннамыни? Белмәсенмени? Ул синең әниең дә барлыгын белгәндер бит кияүгә җыенганда? Әйдә, башта әниең белән сөйләшик, аның рөхсәтен алыйк, дип, иң беренче ул әйтергә тиеш иде мәнле бала булса.

– Мин нәкъ шушындый сөйләшү буласын белгәнгә сиңа әйтмәдем дә инде. Аннары...

– Нәрсә аннары?

– Юк, болай гына...

– Әйтеп бетер, бер булгач булсын инде.

– Инна бит...

Шул вакыт ишектә кыңгырау шалтырады. Ринат, авыр сөйләшүдән котылганына сөенеп, ишек ачарга юнәлде. Гадәттәгечә шау-гөр килеп сеңелләре килеп керде. Коридорда ук алар: «Ниһаять, сине дә күрер көн булыр икән, апаны саргайтып үтерәсең бит инде!» – дип, энекәшләрен «кыздырып» алдылар да залга үттеләр.

– Бәрәч, бу чәчби нишләп утыра биредә? – дип кычкырып җибәрде кинәт кече сеңелләре Мәүлидә Иннаны күргәч.

– Апакайлар, таныш булыгыз, Инна – минем булачак хатыным. Без тиздән өйләнешәбез, – диде Ринат ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.



Аннары кыюсыз гына: «Барыгыз да туйга рәхим итегез», – дип өстәде.

– Булачак хатының шушымыни? – диде Мәүлидә зәһәрләнеп.

– Мәүлидә апа, чамалап!

– Апай, нәрсә карап торасың, нигә куып чыгармыйсың аны? Бу бит, бу бит...

– Кем? – диделәр Резедә белән Нурия беравыздан.

– Соң, Илгизәреңне тартып алган хатынның кызы бит бу.

Ниһаять, исенә төште Резедәнең: чынлап та иренең сөяркәсенең кызы ич бу. Ә ул кайчаннан бирле тавышы да, иреннәре дә таныш кебек дип баш вата. Теге вакытта иренең офисына аңлашырга баргач, кабинетында сөяркәсе дә, шушы кыз да бар иде шул. Үзе генә барырга шикләнеп, чая, батыр икәнлеген күздә тотып, сеңлесе Мәүлидәне дә ияртkән иде ләбаса. Әйтәм аны иртәдән бирле күңеле нидер сизенеп үрсәләнде, кулыннан эш төште – менә нигә булган икән. Улы, бердәнбер газиз улы әнисенең көндәше кызына өйләнергә йөри диген, ә?

– И-и Аллакайгынам, башка сыя торган хәбәрмени бу? Син, син... – Җөмләсенең башын пышылдап, ахырын үтә кычкырып әйтте дә гөрселдәп идәнгә ауды.

* * *

...Айнып, күзләрен ачканда ике сеңлесе дә янында елашып утыра иде. Резедә башта аптырап калды, як-ягына каранып, үз өендә икәнлеген белгәч кенә бераз тынычланып, башын калкытты.

Аңына килгәнен күреп сеңелләре елый-елый ах-ух килә башладылар, Аллага шөкер, үтте, диештеләр.

– Сез ник елашасыз, берәр нәрсә булмагандыр бит? – дип, сорауларга күмеп ташлады аларны апалары, урыныннан торырга маташып.

– Аллага шөкер, Аллага шөкер, – дия-дия, Нурия кайнар чәй алып кереп апасына сузды. – Ятып тор, апа, зинһар торма, йә тагын башың әйләнә башлар. Хәзер Исламнар да килеп җитә. Әнә, килделәр дә.

Бигрәк уңды инде сеңелләре ирләреннән, дип сөенеп куйды Резедә. Менә, ичмасам, алар чын мишәр кызлары. Ирләрен ничегрәк биетәләр әнәтерәк. Ул гына андый була алмады, гаиләдә ир баш булырга тиеш, дип, һаман Илгизәрен беренче урынга куеп килде. Ә ул әнә... Үз эшен булдырып, баеп киткәч кенә...

Ирен бизнес-көндәшләре канга батырып кыйнап, ишек төбенә китереп ташлаганда җиңел булдымы әллә Резедәгә? Ә берничә тапкыр «янып», муеннан бурычка баткан чакларында рәхәт булдымы? Ярый әле сеңелләре белән кияү-балакайлар, дусларыннан, таныш-белешләрдән бурычка акча җыя-җыя, ярдәмнәреннән ташламады. Кесәдә бер тиен акча булмаган чакларында сумка-сумка ашамлыкны алар ташымаса, нишләрләр иде икән? Ә Илгизәр берни дә барып чыкмаудан кайгырып эчүгә сабышкач ниләр генә күрмәде ул... Ниһаять, тернәкләнеп, кешечә яши башлагач кына... Ичмасам, сөяркәсе яңа байларныкы кебек яшь, чибәр булса икән әле. Их... Әрнүдән янә үрсәләнеп елый башлады хатын.

– Йә инде, апай, тынычлан, елама, таш яуса да өйләндермибез без аны ул чәчбигә.

– Кемне өйләндермисез? Нинди чәчбигә? Соң инде, кайтмый хәзер Илгизәр бирегә, пропискадан да төшкән, үз өлешеннән дә баш тарткан, шалтыратып әйтте.

– Син нәрсә инде, апай, нинди Илгизәр? Улың, Ринат... көндәшеңнең кызына өйләнергә йөри бит әнә.

Ире Ислам белән апасы Нурия икесе берьюлы Мәүлидәнең аягына бастылар. Туктап тор, янәсе.

– Нәрсәсен яшерәсең инде аның, – дип кызып китте төпчек сеңел. – Апай, шөкер, аңына килде. Кстати, син төп-төгәл биш сәгать уянмыйча йокладың, «скорый» да килеп китте, хастаханәгә бирмәдек, – дип дәште ул апасына. – Хәзер инде туйны булдырмау хәстәрен күрергә кирәк.

– Нинди туй? Кем өйләнә соң?

Ул күзләрен тутырып әле бер сеңлесенә, аннары икенчесенә, кияүләргә карады. Аннары йөрәк турысын каты итеп нидер кысып алгач, «аһ!» итеп куйды да башы тагын мендәргә салынып төште. Сеңелләре, бер-берсенә карашып, аптырап калды. Хәтта нинди чая Мәүлидә дә телен тешләде.

Әһә, исенә төште, әле генә улы, бердәнбере, бәгырь җимеше кан дошманының кызына өйләнәчәген хәбәр итте ләбаса. Ничек оялмый ул, ничек җөрьәт итә?

Резедә янә такмаклый-такмаклый еларга кереште.

– Булмый туй, булмый! Әйтегез аларга, мин исән чагында берниндн дә туй булмаячак!

...Туй, чынлап та, кичектерелде. Тере мәеткә әйләнгән Резедәне сеңелләре бер генә көнгә дә ялгызын гына калдырмадылар. Ринаты та өйләренә иртәрәк кайтырга тырыша хәзер. Тик үз эченә йомылганнан-йомыла бара шул балакай. Әнисе белән исәнләшә, хәлен сораша да, үз бүлмәсенә кереп бикләнә. Ябыкты бахыр, коры сөяккә калды. Илгизәр телефон аша да, килеп тә берничә тапкыр аңлашырга теләгән иде дә Резедә аны куып чыгарды. Әнә инде әйтәсе сүзен хат белән юллаган. Сеңлесе, ишегегезгә ниндидер конверт кыстырып киткәннәр, дип алып керде. Бергәләп ачып карасалар – Илгизәр кулы.

«Резедә! Беләм, син мине гафу итү генә түгел, күралмыйсың, һәм син мең мәртәбә хаклы, – дип башлана хат. – Тик, зинһарлап сорыйм, хатымны укып чыгарга көч тап. Нинди генә карар кабул итсәң дә, синеңчә булачак. Аңла, зинһар, син дә бит минем иң якын, кадерле кешем. Иң авыр вакытларымда таянычым булдың, моны үлгәнче онытачагым юк. Тик нишлим соң, йөрәккә боерык биреп булмый бит. Син – акыллы һәм көчле хатын, мине аңларсың дип уйлыйм.

Бергә яшәгән матур елларыбыз хакына сорыйм, ялварам, балаларның бәхетенә балта чапмыйк, аларның ни гаебе бар инде? Алар бит безгә кадәр үк



Рәсем: Наталья Васильева

таныш булганнар. Мин бу хакта инде Алсинә белән яши башлагач кына белдем. Ринат белән киләчәк турында йөз мәртәбә аңлаштык. Башта мин дә аларның өйләнешүләренә каршы идем. Әниең моңа беркайчан да риза булмаячак, ул икебезгә дә бик нык рәнҗиячәк, дип, кат-кат аңлатырга тырыштым. Тик бер-берсен оныта алмадылар бит. Белмим, язмыш шаяруымы бу, безне шулай җәзалавымы?

Риза булсаң, барлык матди чыгымнарны – балаларныкын да, синекен дә үз өстемә алам. Карышма гына, мин сине ташламыйм, дип, ничә мәртәбә әйттем бит, тыңламыйсың гына. Минем бит бар да хәтердә, берсен дә онытмадым. Бүгенге барлыгымда синең дә өлешең зур, бик зу-ур! Ярый, син каршы булсаң, туй ясамабыз, тик никахка каршы килмә, зинһар. Яшәп карасыннар, бәлки, бер-берсеннән суынырлар да әле.

Уйла. Уйла? Уйла!»

– Кабахәт, юха елан! – диде Мәүлидә, хатны бергәләп укып чыккач.

– Юк, түгел, алай димә инде. Язмыш бу, язмыш. Аның мине ни өчен болай рәхимсез рәвештә җәзалавын да аңладым шикелле. Хәтерлисеңме, югары оч Хәкимулланы?

– Хәтерләмәскә. Соң ул Нурия апаның классташы иде ич, синнән өч яшькә кечкенә. Буйга да синнән күпкә кайтыш иде. Син аны гел, үскәнем, үскәч килерсең, яме, дип үрти идең. Кит инде, монда Хәкимулланың ни катнашы бар. Үткән эшкә салават дип әйтә иде әбкәй, хәтерлисеңме?

– Алай димә, канәтем, күрәсең, бик нык рәнҗегәндер ул миңа. Илгизәрнең хыянәте дә шуның өчен җәзадыр. Начар кеше түгел бит ул. Әнә, нинди хат язган...

– Син нәрсә инде, апай, гафу иттеңме әллә җизнине?

– Сүз безнең хакта түгел бит, сеңелкәем. Бала – бәгырь ите, дип, юкка гына әйтмәгәннәр шул, кай яктан гына кагылсаң да авырта. Һай, авырта... Ярый инде, шулай язган икән, өйләнешсеннәр. Соңарып булса да, туе да булсын. И-и Ходаем, ничекләр генә ул кызны киленем итеп кабул итәрмен дә, ничекләр яшәп бетәрбез? Бир сабырлык, бер Аллам, бир түзем...

PRESSA



ҖЫР – ЯЗМЫШ УЛ!



Роза
МУЛЛАНУРОВА

Башкортстанның Яңавыл районында, Асаулы дигән бәләкәй бер авылда дөньяга килгән ул. Бу төбәк Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов, Нил һәм Илдар Юзеевларны – татар халкына билгеле, тагын бик күп күренекле шәхесләрне яшел бишегендә тибрәтеп үстергән як. Шул йолдызлыкта – сәнгать дөньясында безнең Филүсә дә тыйнак, әмма берәгәйле үз урынын белә дип хыялландымы икән? Бу – Язмыш! Җыр сәнгате, моң белән бәйле, бәхетле дә, һәм сынауларга, сикәлтәләргә гаять бай да кеше язмышы бу!

Бүтәннәр әйтергә дә кыймаган четерекле темаларны каләм очына алып, үз фикерен кыю белдерә.

Тугыз балалы гап-гади гаиләдәге сабыйларның ул – җиденчесе. Һәм, әйтергә кирәк... иң җиллесе! Филүсәнең Фәзнәви абыйсы Чкаловта армия хезмәте үткәннән соң патефон күтәреп кайта. Авылда беренче патефон бу. Борып җибәрәсең, көмеш тавышлы җырчыларның ягымлы аһәңле, моңлы тавышлары үзеннән-үзе агыла башлый. Тылсым, җыр тылсымы бәләкәй Филүсәне тәмам әсир итә. Һәм ни гаҗәп, беренче сыйныфка укырга кергәндә ул инде Фәридә Кудашева, Зифа Басыйрова, Галия Гафиятуллина, Фәхри Насретдинов, Рәшит Ваһапов башкарган күп кенә җырларны отып, әкрен генә көйләп сабакташларын шаккаттыра. Берничә елдан авыл йортларына радио керә. Башкортстан һәм Татарстан радиосы тапшыруларын үсмер кыз мөкиббән булып тыңлый. Иң кызыгы – җырларны алар тавышына охшатып җырларга өйрәнә. Авылларында сигезенче сыйныфны тәмамлагач, Ямады урта мәктәбендә укый башлый. Бәхет капкалары кемгә кайчан ачыласын беркем белми, әмма җырга-моңга сизгер, нечкә күңелле Филүсә өчен мәктәп еллары бушка үткән гомер түгел. Чөнки... Россиянең атказанган укытучысы, һәвәскәр композитор, оркестр-хор җитәкчесе булып танылачак Әгерҗе егете, заманында Иж-Бубый мәдрәсәсендә гыйлем җыйган Якуб Зарипов Ямады мәктәбендә укыта. Җыр-моңнарны нечкә тоемлау сәләтенә ия кызга аерым игътибар күрсәтә, аны музыка грамотасына, җырларга өйрәтергә омтыла. Һәм Филүсәгә Стәрлетамак культура-агарту училищесына юл ачыла. Аны, көллиятне тәмамлауга, Дүртөйле шәһәре мәдәният бүлегенә эшкә чакыралар.

Ә күңел, күңел Казанга тарта. «Азамат»ны көйли-көйли ул да татарның мәккәсенә юл тота.

Еракларга гына күренә микән
Ирендеккәй тавының ак ташы.
Кая гына бармый, ниләр күрми
Ир егеткәй белән ат башы...

Борынгы җырлар күңелләргә уелган, ә күрәселәр... алга килә ул!



Кызы Мөнирә белән туган авылының салкын чишмәсе янында.

Дөрес, җырчы булырга хыялланган Филүсә Арсланова атлы яшь кызны Казан колач җәеп үк булмаса да, бигүк төксе каршыламый. Татар җыр һәм бию ансамбленең хор төркеменә эшкә урнашу насыйп була аңа. Радио аша гына ишеткән җырчылар белән якыннан аралашу, зур хыяллар белән янып яшәү чоры булгангамы, бу еллар хәтеренә мәңгегә уелып калачак аның.

Хорда җырлап йөри, әмма белем, осталык җитмәве үзен һәрдаим сиздерә. Казан дәүләт мәдәният институтына укырга керә. Укуын тәмамлауга тырыш, максатчан кызны остазы Җәвид Абдраим улы Котдусов җитәкләп диярлек консерваториягә алып килә. Югыйсә балачактан музыка мәктәбендә укып, осталыгын чарлаган, бик чиста тавышлы җырчыларга гына консерватория ишекләрен киереп ачуы беркемгә дә сер түгел. Милли кадрлар әзерләү теләге белән янган консерватория ректоры Нәҗип Җиһанов тарафыннан да остазның теләге яклау таба. Ләкин... авыл кызының җиңел генә бу югары уку йортына килеп керүе читтән генә бәхет кыйпылчыгына юлыгу булып күренергә мөмкин: кечкенәдән музыка белән ныклап шөгыльләнмәү үзен һәрдаим сиздерәчәк әле. Әмма тырышлык таш яра, дип юкка әйтмиләр бит. Тырыша Филүсә. Балта остасы әтисе, ишле, димәк, эшле гаиләне бербөтен итеп тәрбияләгән әнкәсе үрнәгендә үскән бит ул. Үҗәтлек, тырышлык белән алдыра. Гастрольләр йомшак, ипле тавышлы җырчыга осталыгын чарларга булыша. Халык җыр ансамбле оештыра, күңел биреп, яратып сәләтле яшьләр белән эшли. Җыр серләренә аларны өйрәтү һәм үзе дә җырлау, ягъни осталыкны камилләштерү – болар, әлбәттә, эзсез үтми. Консерваториядә, хор дирижерлыгы бүлегенең дүртенче курсында укыганда ук аны Казан мәдәният институтына укытырга чакыралар. Хор дирижерлыгы кафедрасы доценты, тәҗрибәле педагогның Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеменә лаек булуы очраклылык түгел. Тормыш, үз эзенә төшеп, җай гына ага. Филүсә мәхәббәтен очрата, кияүгә чыга. Кызлары туа. «Бер кайгысыз бәндә булса, ул чын кеше түгел», ди-

Фото: Анна Арахамия

ме Тукай. Ире бәхетен читтән эзли башлый. Еллар буена сузылган хыянәтне кичерә алмый Филүсә...

Ялгыз калгач, йомшак, гүзәл зат – хатын-кыз нишләсен? Ул – ана! Бәла-каза килгән чакта тешен кысып түзәрлек, бирешмәслек көч-гайрәтне каян ала ул? Бу – сер. Геройшагыйрьгә ияреп: җырым белән җиңдем дошманны, дисә генә инде...

Уйлана Филүсә. Җырлап юана. Уйларның очы-кырые, бүтән чара юк.

Татарны моң яшәтә, ул безгә борынгылардан күчкән диярргә яратабыз. Бүтән халыкларда ул юк, дип тә өстәп куябыз. Ә безгә – безнең җырларга ул моң каян килә? Ачы язмышы татарны моңлы, сагышлы иткәнгәме? Мәңгелек проблема – бәхет нәрсә ул, ничек бәхетле булырга дигән сорау-җавап та борынгылардан килә ич. Ә Филүсә Арсланованың моңа җавабы гади һәм үтә табигый: кешеләр арасында яшисең икән, аларга кирәкле, файдалы эшләр башкару, кешелекле булу, якын-тирәдәгеләрнең җылысын, дустанә мөнәсәбәтен тою... Шул чакта гына син ялгызлык дигән чирдән азат.

Филүсә Арсланга иҗатта да, тормышта да ихтыяр көчен батырларча бер йодрыкка төйнәп яшәргә туры килә. Әмма сынатмый. Үзенә һәм сайлаган юлына хыянәт итми. Вокал сәнгатенең бөтен нечкәлекләрен белеп, җыр һәм хор сәнгатенә профессиональ югарылыкта бәя бирә. Бүтәннәр әйтергә дә кыймаган четерекле темаларны каләм очына алып, үз фикерен кыю белдерә.

Ә Вакыт туктамый, ага. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең 70 еллык юбилее якынлаша. Һәм көннәрдән бер көнне ансамбль җитәкчеләре аңа үзе җырлап, киң сәнгать дөньясына аяк баскан коллективның тарихын язарга тәкъдим итәләр. Чөнки сәнгать дөньясының эчендә кайнап яшәвен, каләм тибрәтүен күреп, белеп торалар. Ансамбльнең концертлары, шәхесләре турында мәкаләләре вакытлы матбугатта еш басыла. Тарих төпкелләренә чумып, филармония, ансамбльгә багышланган язмаларны барлап, җыеп, Милли архивта казынып, Филүсә Арсланова ветеран җырчы-биючеләр, музыкантлар – татар сәнгатен тудыручылар белән очрашып, халкыбызның җыр-бию, музыка, уен кораллары турында гаятъ бай мәгълүмат туплый.

Татар җыр һәм бию ансамбленең 70 еллык тарихын сурәтләгән, республика тарихын, аның мәдәниятен чагылдырган, фидакарь шәхесләрнең хезмәтенә, талантына зур бәя бирелгән беренче китап була ул.

«Бу кадәр зур һәм җаваплы гамәлне, тәҗрибәле галимнәр төркеме эшләрлек четерекле, авыр фәннитикшеренү эшен берүзе һәм югары фәнни дәрәҗәдә башкарган нечкә тоемлы сәнгать белгеченең иҗат батырлыгы һәртөрле мактауларга һәм сокланууга лаек», – дип яза галим Әнвәр Хәйри.

Остазы, профессор Җәвид Абдраим улы – гаҗәеп тавышка ия опера җырчысы буларак исеме тарихка кереп калган Шәфика Котдусованың нәсел дәвамчысы турындагы монографик хезмәте, Кырым татарлары, бүгенге эстрада язмышына багышланган язмалары аны уйланучан, төпле фикерле, эзләнүчән автор итеп таныта. Филүсә Тимергали кызы фольклор үзгендә дә нәтиҗәле эшли, хор белеме буенча татар телендә программалар төзи, музыка дәреслекләрен тәрҗемә итә, хор музыкасын укыта. Иҗат юлын ансамбль солисты буларак башлаган җырчы башкарган байтак әсәрләр – «Сандугач», «Каз канаты», «Ана җавабы» кебек җырлар дәүләт телерадиокомпаниясе фондында әле дә саклана.

Быел – гомер бәйрәме алдыннан «Халкыбыз мирасы» нәшриятында Филүсә Арсланованың гаять киң колачлы хезмәте – «Моң эчендә асылташ» исемле китабы дөнья күрде. Татар халкының музыка сәнгате сәхифәләре, Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле һәм Татар дәүләт филармониясе, Ходай биргән олы талантларын милләткә хезмәт итүгә багышлаган асыл затлар – композиторлар, хормейстерлар, балетмейстерлар, җырчылар, биючеләр, музыкантлар, галимнәр турында эчтәлекле мәкаләләр, истәлекләр, тәнкыйди язмалар тупланган бу җыентык илебезнең төрле төбәкләренә чәчелеп яшәгән милләттәшләребез өчен кадерле, зур бүләк булыр.



Башкортстанның Дүртөйле халык театрының «Туй бүләге» спектаклендә. Уфа телевидениесе. 1969 ел.



Дүртөйле Сабан туенда. 1969 ел.

Фотолар: гаилә архивыннан.

ҺӘР КИТАП – АЕРЫМ БЕР ГАЛӘМ

Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ,
Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясенең «Татарстан» филиалы җитәкчесе



КИТАП УКУ УЛ...
– Гадәти тормыш мәшәкатьләреннән арынып, хыял дөньясына чуму, шашып чапканда тукталып, яшәү мәгънәсе, бер-береңә карата булган мөнәсәбәтләр турында уйлану мөмкинлеге. Китап яңа нәрсәләрне белергә, моңарчы битәрләп йөргән сорауларга җавап табарга булыша. Кырыс чынбарлыктан беразга гына булса да качып тору чарасы да ул.

УКЫРГА МӘХӘББӘТ УЯТКАН КИТАП...
– Мөгаен, Абдулла Алишның «Сертотмас үрдәк» китабы булгандыр. 1986 елда, 6 яшемдә авыл китапханәсенә язылгач, яшел төстәге олы бер шкаф каршына китереп бастырдылар. Анда өсле-өсле итеп юка гына балалар китаплары өелгән иде. Бераз актарындым да: «Миңа балачага китабы кирәкми, зурларныкын күрсәтегез», – дидем. Шуннан миңа «зурлар» форматындагы «Сертотмас үрдәк»не тоттырдылар. Әле дә хәтеремдә: тышлыгында – авызын ачып, агачлар, гөмбәләр арасында каңгырып йөрүче соры үрдәк рәсеме төшерелгән иде.

МИНЕ /ДӨНЬЯГА КАРАШЫМНЫ/ ҮЗГӘРТКӘН КИТАП...
– Алар шактый. Балачакта Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында»сын укыганда Бөек Ватан сугышына бөтенләй икенче яктан, тоткын күзлегеннән караш шаккаттырган иде. Аяз Гыйләҗевның «Йәгез, бер дога!»сын СССР әдәбияты күләмендә лагерь тормышына багышланган иң тирән әсәр дип саныйм. Әмирхан Еники хикәяләре күңелгә уелып калган. Бигрәк тә «Әйтелмәгән васыять» әсәре, чөнки үзебез дә әбиләр тәрбиясендә үстек. Рус әдәбиятыннан Василий Гроссманның «Жизнь и судьба»сын, Уильям Ширернең «Взлет и падение Третьего Рейха», Михаил Шолоховның «Тихий Дон» әсәрләрен атар идем. Гомумән, һәр сыйфатлы китап күңелдә тирән эз калдыра, үзенчә тетрәндерә.

ҮСМЕР ВАКЫТЫМДАГЫ ДУСТЫМ-КИТАП.
– Үсмер чакта Рафаэль Сабатининың капитан Блад маҗаралары белән мавыгып алдым. Әлбәттә инде, Жюль Верн, Артур Конан Дойл, Александр Дюма әсәрләрен укый идек. Аннан соң ул чорда чит илнең заманча әдәбияты да керә башлады. Уэс Крэйвенның «Кошмар на улице Вязов», Томас Харриснең «Молчание ягнят», Стивен Кинг китаплары... Кингның һәрбер романын калдырмый укып бардым, 25 яшьләрдә генә ул чирдән арына алдым. Хәзер дә укыштыргалыйм, әйтик, чагыштырмача күптән түгел чыккан «11/22/63» романы Кеннедины үтерүгә кагылышлы вакыйгаларны тасвирлый, ләкин Кинг аңа үзенә хас бәяләмә бирә, үзенә генә хас стильдә бәян итә.

ӨСТӘЛ КИТАБЫМ...
– Берничә мәртәбә укып та, һаман туймаган китабым – Марио Пьюзоның «Крестный отец» сагасы. Бу әсәр дөнья күләмендә культ дәрәҗәсенә күтәрелгән. Укымаган, күрмәгән кеше ялгышмасын – ул җинаятьчеләр дөньясы турында гына түгел. Гаиләдәге, җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләр, бурыч, намус, әдәп, әхлак хакында. Бары тик әлеге сыйфатлар безнең өчен гайре табигый шартларда – мафия кланы мисалында ачыла.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...
– Мәктәп-студент елларында ярты-йорты укылган «Война и мир»ны хәтердә яңартып ятуым. Шулай ук Мөхәммәт Мәһдиевнең «Мәңгелек яз»ын янә киштәдән алдым. Рауль Мирхәйдәровның «Иртәләгән сагыш»ы да кул астында. Гадәттә, кәефкә карап, берьюлы берничә китап укыйм.

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДАГЫ ӨЧ ЯРАТКАН ӘСӘРЕМ ҺӘМ АВТОРЫМ...
– Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә», Аяз Гыйләҗевның «Йәгез, бер дога!», Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрләре.

БАЛАЛАРЫМНЫ МАТУР ӘДӘБИЯТ УКУГА ТАРТКАН КИТАПЛАР...
Һәрбер чорның үз әдәбияты, үз каһарманнары бар. Мин аларны аңлап та бетермим кебек. Күңелне борчыганы – татар телендә яшүсмерләр әдәбияты бик ярлы булу.

БАСМА ҺӘМ ЭЛЕКТРОН КИТАПНЫҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ...
– Электрон китапның нәрсәсе белән уңайлы икәнлеген әйтеп тормыйм, аны һәркем белә. Ләкин мин электрон китаплар укымыйм. Миңа китап кирәк. Аны кулга алып, башта арткы битләреннән аннотациясенә күз төшерәсең, тиражын, кайда, кайчан басылуын карыйсың. Аннан соң гына укырга керешәсең...

УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ...
– Ана телебездә иҗат иткән һәр авторны укырга киңәш итәр идем. Соңгы вакытта үземә тирән йогынты ясаган әсәрләрдән Айн Рэндның «Источник», Ирвин Яломның «Когда Ницше плакал», Лючия Сен-Клер Робсонның «Верхом на ветре. История Синтии Энн Паркер и последних дней команчей», Алексей Иванов китапларын санап үтә алам.



Фото: Анна Арахамия

30 октябрь– сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне. Илебезнең күпме халкы, нахакка гаепләнеп, туган җиреннән сөрелә, газапларга дучар ителә... Әлеге фаҗига безнең өйнең дә ишеген какты.

1949 елның июнь аенда безгә килгән кайгы авыл өстенә таралды: «Тимерче Шәйхулланы төрмәгә алып киткәннәр!» Берничә көннән әтине авылга кире алып кайттылар. Без дә аны күрергә бардык. Ләкин әтиебез янына якын да җибәрмәделәр. Икенче көнне ашъяулыкка ризыклар төреп, Апас төрмәсенә киттек. Тик әти белән күрешү насыйп булмады. Аны инде Казанга алып киткәннәр иде. Ике көннән биш баласы белән әнине дә алырга килделәр. Олы абыебыз Сәгъдуллага – 19, Хәкимулла абыйга – 16, апама – 8, миңа – 6, сеңлемә 3 яшь иде... Башта – Казанга, аннан товар вагоннарына төяп, тагын каядыр җибәрделәр. Вагон шыгрым тулы. Эшелон көчле сак астында көнчыгышка таба сөйрәлә. Ач тоткыннарны жәлләп, тимер юл станцияләрендә халык безгә ризык бирмәкче була: кайсысының кулында – пешкән бәрәңге, кайсыныкында – икмәк сыныгы... Ләкин сакчылар беркемне дә якын җибәрмиләр. Сүгенү тавышы, бурзайларның буылып өрүе колакларны тондыра.

Бер ай бардык без. Ниһаять «Большой Невер» станциясендә төшереп, йөк машиналарына төяделәр. Үзебезгә төбәлгән автомат көпшәләренә карап, тын гына барабыз. Елый-елый күз яшьләре күптән кипкән инде... Безне Тында бистәсеннән 200 чакрым төньяктарак, биш-алты гына гаилә яшәгән Лапри дигән җиргә алып килделәр. Әтием тимерчелектә эшли башлады. Авылдагы кебек, алны-ялны белмәде, намуслы хезмәт итте. Аны мактап язган уңай характеристикалар миндә әле дә саклана. Апам беренче класска Тында бистәсендәге интернатта яшәп укырга керде. Ике арада 200 чакрым булса да, еш кайтырга тырыша иде ул, чөнки безгә аның янына барырга рөхсәт итмәделәр.

Ике елдан соң безне дә Тындага күчерделәр. Андагы халык та төрле республикалардан сөрелүчеләр иде. Күршебездә генә яшәүче Надежда Хрубилова укытучыбыз булды. Аның кызы Алевтина белән без дуслар идек. Татарстанга кайткач та озак еллар хат алыштык әле.

Алты елга якын Себердә яшәгәннән соң, безгә Татарстанга кайтырга рөхсәт бирделәр. 1955 елның марты иде ул. Мөмкинлек булу белән, туган ягыбызга кайттык. И-и туган җирнең үзенә тарту көче! Ә күпме кардәшебезнең кабере чит-ят җирләрдә калды.

Әтиебезнең «эше»е кырык елдан соң – 1989 елда Татарстан прокуратурасы тарафыннан кабат каралды. Гаделлек җиңде – әтине акладылар. Ул документта болай диелгән: «Сезнең үтенечегез Татарстан прокуратурасы тарафыннан тикшерелде. 1898 елда туган Миңнуллин Шәйхулла Миңнулла улының һәм аның гаиләсенең ТАССР-ның Апас районы Иске Әнәле авылыннан Амур өлкәсенә мәҗбүри җибәрелүе прокуратура тарафыннан дәлилсез дип табылды». Әтием, әнием һәм безнең исемнәр репрессия корбаннарының «Хәтер китабы»на кертелде. Ул язмышлар – тере хәтер, киләчәккә кисәтү.

Ике сугышта кан түккән, авыр яраланган биш бала атасына 52 яшендә туган җиреннән аерылып, әнә шундый кайгы-хәсрәтләр күрергә язган булган. Әтиебез – 73 яшендә, әниебез 89 яшендә Казанда вафат булдылар. Урыннары оҗмахта булсын.

Хәния МИҢНУЛЛИНА,
хезмәт ветераны,
сәяси репрессияләр корбаны.
Казан шәһәре.

Быел районыбызның үзәк китапханәсе үзенең 125 еллыгын билгеләп үтә. Татарстанда иң өлкән китапханәләрдән санала ул. Шушы дәвер эчендә төрле үзгәрешләр кичергән, бер бинадан икенчесенә күченгән әлеге оешма кечкенә китапханәдән заманча мәгълүмати үзәккә әйләнде.

Була шундый кешеләр, нинди генә авырлыклар килсә дә, бирешмиләр, башларын имиләр. Минзәлә районы үзәк китапханәсенең бүлек мөдире Римма Рәсим кызы Әхмәтханова (Вәҗетдинова) – шундыйлардан.

Ул – Актаныш районы Пучы авылы кызы. 1988 елда урта мәктәпне тәмамлый. Китапларга булган мәхәббәте аны



китапханәгә эшкә алып килә. Китапханәче эше – мәңгелек бәйрәм кебек. Чынлыкта бу һөнәр беренче карашка гына җиңел күренә. Бик белемле булуны таләп итә ул. Римма да Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясенә укырга керә. Аны кызыл дипломга тәмамлап, яңадан яраткан китаплары арасына кайта. Менә инде утыз елдан артык бу сөйкемле ханым, гади китапханәчедән бүлек мөдиренә кадәр хезмәт юлын узып, үзенең яраткан эшен башкара. Аудиториянең игътибарын үзенә җәлеп итүе, китап укучылар белән җанлы сөйләшүләр алып бара белүе белән башкалардан аерылып тора ул. Еллар узган саен, Римма да үзенең һөнәри осталыгын камилләштерә бара: эш алымнарын төрләндерә, китапханәләрнең инновацион эшчәнлеген өйрәнеп, квалификациясен күтәрә.

Озак еллар Минзәлә районы «Җирлекара үзәк китапханә» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең хезмәт күрсәтү бүлеген җитәкләүче югары квалификацияле белгеч үз тәҗрибәсен яшь коллегалары белән дә бик теләп уртаклаша. Римма Рәсимовна җитәкчелегендә берничә дистә китапханәче тәрбияләнгән, алар өчен ул эшкә җаваплы караш һәм югары профессиональлек үрнәге булып тора. Үзен тулаем яраткан эшенә багышлап, ул талантыннан, җан җылысыннан китап укучыларга да өлеш чыгара. Минзәләлеләр һәм шәһәр кунаклары өчен табигать кочагында чаралар, китап укучылар өчен конференцияләр, шәһәрнең иҗтимагый оешмалары базасында күчмә очрашулар, әдәби программалар... Китапханәдә эш гөрләп бара. Язучылар иҗаты пропагандалана монда, әдәби кичәләр, конкурслар, китап презентацияләре үткәрелә, турыдан-туры эфирлар уза. Болар барысы да бүлек мөдире һәм хезмәткәрләрнең тынгысыз хезмәте нәтиҗәсе. Еш кына бәйрәмнәрне дә үзе алып бара бүлек мөдире. Күпьеллык һәм нәтиҗәле хезмәте өчен ул берничә тапкыр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, район башлыгының, мәдәният бүлегенең Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләнде һәм Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» билгесенә ия булды. Үз һөнәренә бүген дә тугрылыклы Римма Рәсим кызы.

Нәҗия ПУЧКОВА,
Татарстан Журналистлар
берлеге әгъзасы.
Минзәлә районы.

Татар халкы элек-электән аш-суга осталыгы белән дан тоткан. Безнең үзебезгә генә хас милли ризыкларыбыз бик күп. Аларның үзенчәлеге халыкның тормыш рәвешенә бәйле булган.

Аш-су осталарыбыз әле хәзер дә яңа төр ризыклар, оригиналь рецептлар уйлап таба. Шуңа да карамастан, чәкчәк, кош теле, гөбәдия, бәлеш кебек нигъмәтләр һәрвакыт табыныбыз түрендә. Өчпочмак, коймак, кыстыбый, токмачлы ашны да еш әзерлибез.

Токмач кисү – зур осталык сорый торган эш. Ул хатын-кызның никадәр уңганлыгы турында сөйли. Кәләш сорарга килгәндә дә иң элек кыздан токмач кистереп караганнар бит. Ә бүген кызларыбыз токмач кисә беләме? Өйрәтәбезме аларны җептәй нечкә генә итеп токмач кисәргә?

Быел безнең Тукай районы Теләнче-Тамак авылы китапханәсендә бик кызыклы бер чара узды. Токмач кисү дәресе иде ул! Авылдашыбыз Нәсимә апа дәресне башлап, үзенең бала вакытында ничек итеп токмач кисәргә өйрәнгәнен сөйләде, киңәшләрен бирде.

Аның чыгышыннан соң яшь ханымнар кечкенә кызлары белән камыр басарга керешә. Кызларның бу эшкә өйрәнү теләкләре шундый көчле иде: дәртләнеп, камыр да бастылар, уклау тотып җәяргә дә керештеләр. Кызлары камыр җәйгән арада әниләре үзләренең кызыклы истәлекләрен сөйләде. Бирегә килгән ханымнарның нинди уңган хуҗабикәләр булуын без инде беләбез. Кызлары да әниләренә охшаган, бигрәк җитезләр! Ни арада җәеп,



ни арада токмачны кисеп тә куйдылар! Шулкадәр юка итеп җәйгәннәр, токмачлары да нәзек кенә.

Районыбызның «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Ләйсән Хәниф кызы да бу эшләрдән читтә калмады, камыр да басты, токмачын да кисте. «Татар хатыннары элек-электән уңганлыклары белән дан тоткан, камыр ашларын да бик тырышып һәм җиренә җиткереп әзерләгәннәр. Токмачлы аш – иң популяр милли ризыкларыбызның берсе. Әниләребезне токмач кисәргә – әбиләребез, ә безне әниләр өйрәтте. Без дә кызларыбызга, оныкларыбызга моны мирас итеп, өйрәтеп калдырырга бурычлы», – диде ул.

Бәйрәмебезгә «Ак чәчәк» балалар бакчасы нәниләре дә килгән иде. Алар шигырьләр сөйләде, җыр-биюләре белән күңелне күтәрде.

Токмач кисү дәресе тәмамлангач, хуҗабикәләрнең татлы ризыкларыннан авыз итеп, тәмләп чәй эчтек. Ләйсән барлык катнашучыларга «Ак калфак» оешмасы исеменнән бүләкләр дә тапшырды әле. Бик күңелле чара булды ул. Аш-су да – милли мирасыбызның бер өлеше. Без аны киләчәк буыннарга шушы нәниләребез аша гына җиткерә алабыз. Әлеге кызчыклар берзаман үсәр, алар да әни булыр, кызларын аш-су осталыгына өйрәтер.

«Татар милли ашлары – иҗат ул», – дип әйткән иде республикабызның беренче президенты Минтимер Шәймиев. Бик дөрес сүзләр бит. Шундый мирасыбызга онытылырга ирек бирмәү – үз кулыбызда. Белгәннәребезне буыннан-буынга тапшырып калдырыйк.

Рамилә СӘГЪДИЕВА,
Теләнче-Тамак китапханәсе мөдире.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адр ес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

«МИН СИНЕҢ ИРЕҢНЕ БӘХЕТЛЕ ИТӘМ...»

Тормышның яңа борылышында үзебезне нәрсә көткәнен без беркайчан белмибез. Уйламаган җирдән аякка уралган ниндидер борчулармы, әллә бөтенләй көтмәгән сөенечләрме? Тормыш борылышлары безне күкләрдән җиргә төшерә ала. Ә кайчак – киресенчә: бәхетсезлегең бәхет юлына бер адым гына булуын аңлата. Чүпрәле районының «Туган як» газетасы баш мөхәррире Резидә Җамалтдинова һәм аның ире Рамилнең очрашу, танышу, кавышу тарихы – шуңа бер мисал.
Ачыктан-ачык сөйләшәбез.

Фото: Анна Арахамия



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Ерактанрак башлыйм, шунсыз аңлашылмас... Мин әби белән генә үстем. Әнәй мине Үзбәкстаннан алып кайткан. Ул якларга бәхет эзләп чыгып киткән булган. Әти белән дә шунда танышканнар. Мин аның Ринат исемле икәнен генә беләм, үзен бер тапкыр да күргәнем булмады. Дөрес, миңа 2 яшь булганда аның хезмәт иткән частена барганбыз. Әнәй: «Син аны берничек хәтерли алмыйсың, бәләкәй идең бит», – дия иде. Тик мин әтинең үземне күтәреп күккә югары чөйгәнен беләм кебек... (*Елый.*) Ә аннары әни башка авылга кияүгә китте. Безнең Иске Чокалы авылыннан 20 чакрымдагы Каракитәгә. Әби белән икәү генә калдык... Бу вакытта миңа 5 яшь иде. Әйтмичә китте... (*Елый.*) Нигә ташлап киткәнен аңламагангадыр, бу минем өчен бик зур хәсрәт булды. Хәер, әби өчен дә... «Болай да ятим идең, инде бөтенләй ятим калдың бит, кызым», – дип, аның елаганын хәтерлим. Үскәч: «Әнәй, нигә мине үзең белән алмадың?» – дип сораганым булды. Турыдан-туры әйтмәсә дә, аңладым: яңа гаиләсе кабул итмәгән. Төп йортка килен булып төшкән, ә ул чакта халык кырысрак иде бит. Аннан, мине алып китсә, әби дә үзе генә кала торган булган бит – анысын да уйлагандыр. Әни тагын дүрт бала тапты. Соңыннан бер сөйләшкәндә аның: «Кызым, ачуланма инде», – дигәне булды. «Юк, әни! Син бит мине дүрт туганлы иттең – югыйсә дөньяда берүзем булыр идем», – дидем... Әни үзе дә килә иде, каникулларга мине дә кунакка алып бара иде. Җәй көне дә барып тора идем аларга. Иң кызыгы: анда баргач – әбине, кайткач, әнине сагынып елый идем...

Сигезенче классны тәмамлагач, әнәй янына укырга Каракитәгә киттем – аларда унъеллык мәктәп бар. Сентябрь ае. Халык бәрәңге ала. Мин дә әбигә булышырга дип кайттым... Без аның белән шунда – ындырда таныштык. Мин үзебезнең бураэнаны казып килем, ул – үзләренекен. Ә аннары ындыр башында икәү сөйләшеп торабыз... Ул инде армиядән кайткан, озын буйлы, кап-кара чәчле. Чибәр! Ындыр башында гына яшәсә дә, мин аны моңарчы белми идем. Әби безне күрде дә, шунда ук барысын да аңлады бугай: «Кызым, сиңа кирәк кеше түгел ул, сөйләшмә! Бар, анаң янына кайт!» – диде. Аны тыңламыйча булмый иде... Әби соңыннан әйтә: «Син киткәнне күрде дә, көрәген ташлап, артыңнан чапты», – ди. Ул көнне әби дә мине Чүпрәлегә кадәр озата барды. Район үзәгендә, сарыкларына дип, өч сумлык ипи алды. Шуларны күтәреп кайтып китте, мин калдым. Ул китүгә, дуслары белән яныма Расих килеп басты. «Әйдә, үләнәм бүген сиңа!» – ди. Үзе эчкән... Ир-атлы гаиләдә үсмәгәнлектән, байтак кимчелекләрем бар минем... «Тыңламасам, дуслары шул кызны да алып кайта алмады диячәк. Ярар, ияреп кайтыйм, иптәшләре өйләнде дип уйласын. Әбидә кунармын да кире китәрмен», – дим үз-үземә. 9 сентябрь бу. Мин – унынчы класс укучысы, 15 яшь... Кайттык. Кулымда химия, биология, физика китаплары салынган мәктәп сумкасы. Аягымда итек, үзем ялан-аяк. Әнисенең чип-чиста юылган идәннәренә аяк очына гына басып менәм, үзем: «Эзем калмаса ярар иде», – дип уйлыйм. Кергәч, дәреслекләр салынган сумкамны мич арасына куйдым. «Мин өйләнеп кайттым, әнәй. Аракың бармы?» – диде ул. Боларга эчәргә сәбәп кирәк булган икән... Расих миннән 6 яшькә олы иде. Армиядән соң калып, бер ел Германиядә хезмәт иткән, өстендә чит ил киемнәре – теләсә кайсы кызның күзе төшәрлек... Әнисе табынга бер шешә аракы чыгарып утыртты. Бер сүз дәшмәде. Улының холкын белгәнгә авыз ачып нидер әйтмәгән инде ул: эчсә, өйдәге бөтен әйберне кыра иде. Шешәнең төбенә төшкәч, кунаклар таралды, бу да ятып, гырылдап йоклап китте. Мин дә янына менеп яттым... Иртүк уяндым да, мич арасыннан мәктәп сумкасын алып, чыгып киттем – исәбем Каракитәгә бару. Тыкрыкта каршыма әби очрады. «Кайда кундың?» – ди. Ык-мык килем... Әби кычкырып-кычкырып ачуланырга кереште: «Син бит кияүгә киткәнсең! Иртүк Зәйтүнә килде, «кызың бездә» дип әйтергә...» Аның мине орышкан тавышына тирә-күршеләр җыелды. «Әби, ул миңа кагылмады да!» – дим, акланам. «Алай булса, бар анаңа!» – ди әби. Күршеләр сүзгә кушылды: «Алай булмый... Кызыңның хәзер кешедән калган дигән аты китә», – диләр. Әби дә икеләнеп калды. Шулай итеп, мин кире борылып кайттым. Һәм 10 ел яшәдем. Нәкъ бер елдан – 9 сентябрьдә олы малаем туды. Аннан икенчесе. Ә мәктәп... Укып бетердем мин аны! Кичке мәктәптә укыдым. Гел «бишле»гә генә!

Ирем район үзәгенә барып, «Сельхозтехника»га эшкә урнашты. Безгә күп катлы йорттан фатир бирделәр. Беренче бала туганчы кайнана белән яшәдек әле. Дога булып барсын: ул мине бар эшкә дә өйрәтте. Әби дә килеште инде, нишләсен... Кайнанам аны бер мунчасыннан да калдырмады – дуслашып киттеләр.

Аңлагансыздыр инде, ирем эчәргә яратты. Безнең арада мәхәббәт булдымы, әллә юкмы... Никах укылгач, ике арада хисләр кабына, диләр. Аның белән яшәгәндә яратуның нәрсә икәнен белмәдем, юк, ярата алмадым... Ияләшү аша килгән бер якынлык булды инде ул. Үз ирең бит – балаларыңның әтисе... Без баштан ук яхшы тормадык. Әмма бераздан тагын да зуррак проблемалар башланды.

Берсендә әнисен алып Ульяньга кунакка китте ул. Олы улыбыз беренче класска барган ел. Кайткач, кинәт югалды. Комбайнда эшли иде – эшендә юк. Дусларында да. Беркайда! Бөтен җирдән эзлим. Әнисенә кайтам – ул бер сүз дә дәшми. Бик кайгырдым! Берәр җиргә китеп, акчасын эчеп бетереп, кайта алмыйча ятамы икән, дим. Ульяньга барып, вокзаллардан эзләп йөрдем. Милициягә дә бардым. Бер ай хәбәре булмады!.. Ә аннан кайтты – бернәрсә булмаган кебек. Ярый, бер югалды шулай, ике... Тели китә, тели кайта – фатир аныкы, яклаучым юк... Сизәм: суынды – борыла да ята аркасы белән. «Нәрсә булды соң?» – дим. «Минем тагын хатыным бар», – ди. Ә мин икенчегә авырлы! Читтән караган кешегә аптырарлык хәлләр. Тормышыбыз әллә ни мантымады инде безнең. Булган әйберне дә, эчеп кайткач, ватып-җимереп бетерде. Кул да күтәрде.

Без очрашканда әнисендә яман шеш булган. Мәрхүмә кайнанамны күреп калуым – бер могҗиза!

Олы малайга да бик нык эләкте. Каеш белән кыйный иде. Мәктәптән соң гына кайтабыз. Өйдә ут булса: «Әнәй бар, башта син кер, исерек түгелме икән? Ул йоклагач керермен», – дип, урамда кала иде. Аны кыйнатмас өчен үзем кыйналам – малайны кулыннан тартып алып өлгерәм, үзем чыгып качарга өлгермим... (*Елый.*) Мин дә олан гына бит әле... «Бала көтәм» дигәч, бер сүз әйтмәде. Алдырырга соң иде инде... Ул арада: «Мин синең иреңне бәхетле итәм», дигән хат килеп төште... Иремне яратмый идем, әмма бу хат килгәч, төн буе керфеккә керфек какмыйча чыктым... Ир бирмәк – җан бирмәк, диләр, дөрес икән... Расих югалды, дип, әбигә кайтып әйткәч: «Ирсез калдың», – дигән иде ул миңа. «Әби, исерек бит ул, кемгә кирәк?» – дим. «Чиләгенә капкачы табыла, – диде әби. – Эчсә соң, ул озын буйлы, матур...» Дөрестән дә шулай булды. Кем белән йөргәнен белмим, эч поша... Берсендә газетага нәрсәдер төреп кайткан, ә анда урам исеме язылган. Ульянга барып, ул урамның бөтен йортларын әйләнеп чыктым. Боларның фатирларына шалтыратам – ачучы юк. Күршеләре ачыкты. Нәрсәгә килгәнемне ачыктан-ачык сөйлим бит инде: ирем китте, үзем менә бала көтәм, дим. «Әйе, озын буйлы бер чибәр ир-ат яши монда. Ә үзенең ирен полиция алып китте, утыртты бугай ул аны», – диләр.

Ә бер кайтуында үзгәреп кайтты бу: араларында нидер булды, күрәсең. Икенче малай туды – аны да яратты. Кулына тотып күтәреп йөргәне: «Күзләрең нинди, улым?» – дигәне исемдә. Берара әйбәт кенә яшәдек. Ә Ульяннан бертуктамый хәбәр килә – аны переговорга чакыралар. Бармый. «Нигә бармыйсың соң, әйтеп кайт», – дим. «Кирәк булса, үзең сөйләш», – диде. Киттем! «Исемеңне әйт әле», – дим. «Расих әйтмимени сиңа исемемне – Гуля мин. Әллә икенче олан табып безне куркытмакчы буласыңмы? Алимент түләрбез!» – ди. «Барасы килми аның... Үзе эчә, үзе эшләми, нәрсәгә кирәк ул сиңа?» – дим. «Булсын, эшләмәсен, эчсен, әмма мин аны түрдә генә утыртып торам», – дип җавап бирде. Юк, еламадым. Ул вакытта елаулар беткән иде инде. Хәзер менә ул чактагы үземне жәлләп елыйм... (*Елый.*)

Бездән ерак түгел әнәйнең апасы тора иде. Берсендә аларга мунчага төштек. Чабынып чыккач, чоландагы сәкегә утырдым. Ул вакыт таза идем – 130 килограмм. Сәке җимерелеп төште, ә аста апаның банка-банка компотлары... Аркамны төне буе тектеләр. Аннан палатага кертеп салдылар. Бер апа белән икәү генә идек. Иртән әниләре янына улы белән килене килде. Гел «Рамил» дип сөйләшәләр. Үз хәлем хәл булса да, боларны да тыңлап ятам. Минем әби үлгән ел иде ул – палатадашым шуңа да бик якын тоелды... Кунаклары киткәч, сөйләшә башладык. «Бөтен оланнарым бар да уңышлы булды, менә Рамилем генә... Шунысы өчен үзәгем өзелә... Хатыннан уңмады, яптырды... Аягына егылып инәлдек, әмма ул улым өстеннән бик каты торды, «утырсын», диде. Килен төнге сменадан кайтканда, улым йоклап китеп, каршыларга чыкмаган. Тавышланганнар...» – ди. Ул сөйли, ә мин үземнекен уйлыйм. Расих йөргән хатын да ирен утырткан дип ишетеп кайттым бит. «Алар шулай инде, үз ирләрен утыртып куялар да, аннары кешенекеләр кирәк була», – дим. «Әйе, кызым, безнең киленне дә йөри, диләр. Улым аның янына кире кайтмакчы була да, белмим шул. Йөри торганы Чокалыдан, озын гына буйлы, мыеклы, диләр...» Апаны бүлдердем: «Расих исемлеме?» – дим. «Шулай бугай», – ди ул. «Апа, минем ирем бит бу... Киленеңнең исемен әйт әле?» – дим. Апам утырды да сүзсез калды: «Таем, ялгыш әйттем, белсәм, сөйләми идем», – ди. Шул көнне ишеттем: иремнең беренче мәхәббәте икән ул хатын.

Кечкенә малайга 1 яшь булганда, бу тагын югалды. Бөтен нәрсәгә күнәсең икән: кайтуына, китүләренә дә ияләшенде... Көннәрдән бер көнне бер дус хатын: «Расихың йөри торган хатынның ире, кайтып, монда эшкә урнашкан. «Сельхозтехника» аңа фатир да биргән – безнең подъездда тора. Яхшыга охшаган ул ир. Ап-ак керләр юып элә. Хатынын алып кайтырга җыенадыр – гаиләсез кешегә фатир бирмәсләр», – ди. Эчемә ут керде. Бу нинди яшәү була инде хәзер? Алар бит барыбер ташлашмаячак, оланнар каршында йөреп торырлармы икән?.. Уйладым-уйладым да, бер көнне кич белән эштән кайткач, киттем мин бу ир янына. Кердем, ашап утыра. (*Елый.*) Ике мойвасы калган. «Әйдә, табынга утырыгыз», – ди. Бардым да ишеккә сөялдем. «Мин – Расих хатыны...» – дим. «Беләм, әллә кайчан күрсәттеләр инде», – ди. «Хатыныңны алып кайтырга җыенасың икән. Расих та шунда яши бит әле», – дим. Озак кына карап торды да болай диде: «Ярар, алар бергә яшәсеннәр, ә без бергә булыйк, туган...»

Декабрьнең егерме сигезе иде бу. Ә апрельдә без никах укыттык...

Яраттым мин аны... Башта язылышмыйча тордык әле. Ул безгә күчеп килде. Рамил белән кушылгач, тормышыбыз бик нык үзгәрде. Ниһаять, акча күрдем. Расихның кесәсеннән 3 тиенләп җыя идем бит... Гаҗәеп тырыш, булдыклы кеше иде Рамил. Эретеп ябыштыручы булып эшләде ул.

Ранисым аның үз әтисе түгеллеген белмәде дә. Без өйләнешкәндә 2 яшьлек кенә иде бит әле. Шунда ук «әти», диде... Берсендә йөгереп кайткан, елый: «Анда Радикның әтәсе кайткан... Бер апа әйтә, ул синең дә әтәң, ди. Юк бит, әнәй?! Минем әти – үземнең әти бит!» Укырга кергәч кенә белде... Аны үз фамилиясенә күчермәгәнгә Рамил соңыннан бик үкенде.

Олы күңелле иде Рамил: аңа оланнарым гына түгел, бөтен туганнарым сыйды. Сеңлем укып бетереп кайтты – безнең белән бергә шул ике бүлмәле фатирда торды. Мине редактор итеп куйгач, энем редакциягә шофер булып килде. Менә ничәү булдык!

Раниләне шунда ук алып кайтмадым әле. Рамилнең дә беренче гаиләсе уңышлы килеп чыкмаган, минеке дә. Икеләнү, шикләнү аңарда да, миндә дә булгандыр... Авылда, аның төп йортында бәрәңге чәчә идек. Ындыр тутырып! Рамил бик тырыш иде. Үзе дә тик торуны белмәде, безне дә эшсез тотмады. Малайлар хәзер дә: «Әтигә рәхмәт, безне эшкә өйрәтте», – диләр. Читкә киттем... Авылда аларның күршеләрендә фасоль белән карраучы бер әби бар иде. «Борчак әби» дип йөртәләр иде аны. «Әйдә, әбигә кереп чыгыйк әле, безгә нәрсә әйтер икән?» – ди Рамил. Кызык бит, иярдем. «Сез бер-берегезгә ышанмыйсыз. Ышанырга кирәк – алдыгызда зур якты юл күренә», – диде әби... Раниләне бик яратты Рамил. Еласа, урамда булса да йөгереп керә иде. Әтисе белән бик якын иделәр. Кызым да әтисе шикелле олы йөрәкле.

Малайларны үзе кайчак ачуланса да, берәүдән дә аларга сүз әйттермәде. Шушы ызбаны салып ятабыз. Олы малай: «Өйләнәм, безгә никах укытсагыз шул җитә», – ди. Төзелеш барганда акча югын белә бит инде. «Тап акча, түләрбез!» – диде Рамил. «Әгәр син булмасаң, без ачтан үлә идек, әтәй», – дигәне булды Радикның. Соңрак «әтәй» сүзен ул да әйтте... Үз әтиләре белән аралашмадылар: китте дә, өзелде.

Улын бик сагына иде Рамил. «Аңласа, армиядән соң кайтыр әле», – дип көтте ул аны. Кайтты! Аннан соң да кайткалап йөрде. Институтка укырга керде: студент чагында, йорт төзесәк тә, акча белән дә булышкаладык. Бер кайтуында бозау суйган идек, ит биреп җибәрдек – дүртәр-бишәр бозау тота идек. Икенче кайтуында, терлек карап кердем, ә ул телефоннан сөйләшә. Мине күргәч, аптырабрак калды һәм трубканы куйды. Шул арада телефон кабат шалтырады. Алды да, шунда ук миңа бирде. Әнисе икән... Мин икәнен белгәч, тезәргә керешт: «Без синең итеңә калганмы? Син аңа акча бир! Йортлар салдың – дәүләтең бар!» – ди. «Йортны Рамил сала. Һәм ул шул ук Рамил... Синеке иде ул. Тик сиңа бит түр башында утыручы ир кирәк булды», – дидем.

Мин озак еллар типографиядә эшләдем, әмма язарга ярата идем. Күрделәр – җаваплы секретарь урынбасары итеп алдылар. Ә аннан... редактор итеп куйдылар. «Тик быел ук укырга керәсең!» – диделәр. Читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамладым. Ирем риза булмаса, өч бала, зур хуҗалык белән югары белем ала алмас идем. Мондый җаваплы вазыйфаны да башкарып булмас иде.

30 ел бергә яшәп калдык без.

12 ел элек эчендә шеш килеп чыкты аның. (*Елый*.) «Әллә авыр күтәргәнгә, һаман бетми», – дип зарланды. Авыру эзләп йөрмим, дип, табибка бармады. Өч елдан соң бервакыт ябыга башлады. «Нәрсәгә миңа табиб, бер җирем авыртмый», – ди. Начальнигы белән сөйләшеп кенә УЗИга алып керә алдым. «Монда хәлләр җитди булырга охшаган, Казанга барырга кирәк», – диделәр.

Больница коридорында табибны көтәбез. Вакытында бармадың, дип ачуланам. Ә ул мине ишетми дә: бөтен барлыгы – тиздән врач чыгасы ишектә. Әллә ничек ашкынып, ымсынып көтә. «Күрерсең, менә хәзер чыга да, сез монда ялгыш йөрисез, башка җиргә барырга кирәк сезгә диячәк», – ди. Әйтмәделәр...

Дәваларга керештеләр. Химиядән үзе баш тартты. Оптимист иде ул, көчле кеше иде. «Миндә рак түгелдер», дип яшәде. Эштән туктамады. Диагноз куелгач та, өйнең түбәсен алыштырып япты, батареялар кертте. Шаян сүзлелеген югалтмады, үз эченә бикләнмәде, дуслары белән аралашудан туктамады...

Редакциянең туксан еллыгын уздырабыз. Рамилнең хәле авыраеп, аны больницага салдылар. Казанга җибәрәбез, диләр. Ә миңа бәйрәм ясарга кирәк – бөтен республикадан кунаклар килде. Төшеп бастым аны озатырга. Ул каталкада ята, ә минем чәчләр ясалган... (*Елый*.) «Абау, син нинди матур! Бар инде, уздыр бәйрәмеңне!» – ди... Юбилейдан соң ук аның янына чыгып киттем. Биш көн сакладым. Гомеремнең иң бәхетле биш көне иде ул! Икәүдән-икәү... Сөйләштек тә сөйләштек... Ул миңа караган, мин – аңа. Башта коридорда яттык, палатада урын юк иде. «Ире терелсә ярар иде, дип, әй, теләк теләдек сезгә... Бер-берегезне бигрәкләр яратасыз!» – дип килеп әйтүчеләр булды. «Операция ясап булмый, гафу итегез», – диделәр. Боларны аңа белгертмәскә кирәк иде...

Ул шулкадәр яшәргә теләде! Без бәхилләшмәдек тә. Хәер, мин үзем сүзне гел читкә бордым. «Нишләрсең инде, карчык?» – дип, өзгәләнеп әйтте ул берсендә. Минсез нишләрсең диюе иде... (*Елый*.)

Туган көнемдә күршеләр керде шулай. «Карчык, әйткәнем юк иде, әйтәм: мин сине биш оланың белән дә алган булыр идем», – диде ул шунда. Ике балалы хатын сиңа нәрсәгә диючеләр булгандыр инде... Кушылдык та, тормышны өр-яңадан башладык. «Без бит синең белән феникс кошлар кебек – көлдән яңадан яралдык», – дигәне дә булды аның.

Әнәй гел: «Рамилгә кадәр китсәм ярар иде», – дип теләде. Бер ел менә аралары... Әтәй ун ел элек мәрхүм булды. Рамил белән бер-берсен яратты алар, икәү сөйләшеп туймыйлар иде. 15 яшемдә кияүгә чыксам да, үги әтәй миңа туйларга кадәр ясады. Килен булып төшкән нигездә дә кайнатам булмады. «Миңа гомердә дә әйтергә язмаган икән бу сүзне», – дим. Бирнә әйберләрен алырга килгәч, үги әтәйгә: «Рәхмәт, әтәй!» – дидем. Кулыннан әйберләре төшеп киткән иде... Аннан ул үзе дә миңа «кызым», дип дәште...

Матур китте Рамилем. Ике көн буе яуган яңгыр туктады да, ялтырап кояш чыкты. Ул үзе дә кояш кебек иде бит... Кешеләргә гел яхшылык эшләргә ашкынды – «шырпы сорап керүчегә дә учак биреп чыгарды». Соңгы көнне улы да кайтып җитте. Тик Рамил инде сөйләшә алмады – башын борып, күзләрен тутырып карады гына...

Балалар урнашкан, оныклар – ә алар тугызау безнең – тәгәрәп үсеп килә. Бер-береңнең кадерен белеп яшәр чакка җиткән идек... Бакча, аның тавышыннан шаулап-гөрләп торган өй буп-буш... Әбинең ялгызлыгын күреп, картайган көнемә язмасын, дип тели идем. Язмыштан кача алмыйсың икән... Рамил белән бәхетле идем, ышанам: аны да бәхетле иткәнмендер.

ТИК СИНЕ ЭЗЛИМ МИН...

Бер генә минутка

Бер генә минутка,
барсын да оныт та,
Кил әле, кил әле яныма.
Ягымлы карашың
кояштай карасын
Сагыштан әрнегән
җаныма.
Тик сине эзлим мин,
тик сине юксынам,
Бөтенләй югалтсам,
нишләрмен?!
Кайларда йөрмәдем,
сиңа тиң күрмәдем,
Гел сиңа талпынды
хисләрем.
Син тере шатлыгым,
тормышым маягы,
Йолдыз син күңелем
күгендә.
Бик соңлап кайтсаң да,
кайчан да, кайчан да,
Урының йөрәгем түрендә.



Лилия
ГӘРӘЕВА

Халкыбызның яраткан җырлары арасында «Бер генә минутка» дип аталганы да бар. Көе дә җайлы, хәтердә кала торган, сүзләре дә үзеннән-үзе җырлап тора... Якын кешеңне бик-бик өзелеп сагынганда, күңелне юатыр өчен күпләр шушы җырны җырлап моңайгандыр. Узган гасырның 80–90 нчы елларында аеруча популяр иде ул. Радио-телевидениедән дә, магнитофон тасмаларыннан да гел яңгырап торды.

Халык телендә «Бер генә минутка» дип аталса да, чынлыкта әлеге шигырь «Урының йөрәгем түрендә» дигән исем белән туа. Шигырьнең авторы – үзешчән язучы-шагыйрә Динә Камалетдинова. Динә ханым – Буа районы Иске Суыксу авылы кызы. Бүген дә шунда яши, язганнары әледән-әле татар матбугатында дөнья күреп тора.

...1967 елның җәе. Бар дөнья шау чәчәк кенә! Ак керфекле ромашкаларның сары күзләре кояш булып балкый. Ромашкалар таҗыннан сөю юрап, бер урарга иде лә болыннардан! Сөйгән ярың белән тулган айга карап, киләчәк турында туйганчы бер хыяллан идең! Юк шул, күңелендә сөю һәм... сагыну Динәнең. Бик еракта, Чиләбе өлкәсендә шул егете. «Бергә китик», – дип чакырса да, аңа ияреп китә алмый кыз. Үпкәләшеп аерылышалар. Ике арага ерак чакрымнар сузылып ята. Күңеле белән Чиләбегә ничә барып, ничә кайтты икән Динә?! Юк шул, китә алмый ул. Бердәнбер кызын ялгызы үстергән әнисен ничек калдырып китсен?! Иң зур хыялы булган Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетына укырга кергәч тә, әнисен ялгыз итмәс өчен, читтән торып укырга мәҗбүр була Динә. Үз авылларында колхозга эшкә керә, сыер да сава, учётчица булып та эшли...

Кичке савымнан соң җәйләүдән кайтырга автобус көтеп торган 20 яшьлек кызның сагынулары, шигъри моңга әверелеп, бәгырьләрен көйдерә. Сөйгәненең күзләренә бер генә караса да, сагышлары басылыр иде кебек... «Бер генә минутка, барсын да оныт та, кил әле яныма...» Хит дәрәҗәсенә күтәрелгән җыр әнә шулай – башына ак яулыгын кыеклап бәйләп, чәчәкле күлмәк итәкләрен җилдә җилфердәтеп болыннан кайтып килгән гап-гади бер авыл кызы күңелендә ярала. Ул еллар – иҗатының иң ялкынлы еллары була Динәнең.

1969 елда Татарстан китап нәшриятында яшь шагыйрь-шагыйрәләрнең әсәрләре тупланган «Беренче карлыгачлар» җыентыгы басылып чыга. Арада Динә шигырьләре дә бар. Күп тә үтми, Фасил Әхмәтов әлеге китаптан күреп, аның «Мәхәббәтемне эзлим» шигыренә көй дә яза. Бу җыр Гали Ильясов белән Эмиль Җәләлетдинов репертуарыннан озак еллар төшми әле.

«Бер генә минутка» җырына килсәк, аны телгә алу белән күпләрегезнең күз алдына иң беренче булып Фирзәр Мортазин киләдер, мөгаен. Әлеге җырны сәхнәгә нәкъ менә ул алып менде. Фирзәрнең танылып килгән чаклары иде, ул җырлаган җырларны тамашачы шунда ук күтәреп алырга гына торды. «Җыр язарга берәр матур шигырь эзли идем. Кулыма «Беренче карлыгачлар» җыентыгы килеп керде. Ошаттым мин Динә Камалетдинованың шигырьләрен. Өстәвенә, якташлар да булып чыктык... 1981 елны яздым мин бу җырның көен. Беренче тапкыр аны Буа шикәр заводы клубы сәхнәсендә башкарган идем. Тамашачы яратып кабул итте. Берәр концертта башкармый калсам, сорап җырлаттылар», – ди җырчы.

Ә Динә апа үзе «Бер генә минутка» җырын беренче тапкыр Буа районы радиосы аша ишетә. Шунда ук районга шалтыратып, җырчы егетнең кем булуын белешә. Фирзәр белән таныш та булмыйлар әле ул чакта. Соңыннан җырчы Динә ападан яңа шигырьләрен соратып ала. Аның репертуарындагы шактый җырлар Динә Камалетдинова сүзләренә язылган – «Танырсыңмы?», «Туган йорт», «Әниемә», «Кил генә»...

«Фирзәр Мортазинның кайбер концертлары тоташтан дип әйтерлек минем сүзләремә язылган җырлардан гына тора иде, – дип искә ала Динә Камалетдинова. – «Бер генә минутка» җырын халык чынлап та яратты. Бер танышым сөйли: «Ташкент урамы буйлап барам, синең җырны җырлыйлар...»

Фирзәр Мортазин яшәү биргән «Бер генә минутка» җырын соңрак Зөһрә Сәхабиева, Хәмдүнә Тимергалиевалар да яратып башкара. Бүген исә аны Марсель Вәгыйзов, «Сак-Сок» төркеме, Марат Галимов һәм башка яшь җырчылар җырлый.

Тәүге сөйгән яры белән кавышу насыйп булмаса да, үз бәхетен барыбер таба Динә Камалетдинова. 1972 елда Иске Суыксу авылы егете Фаязга кияүгә чыга. 1974 елда – кызлары Гөлнара, 1975 елда – Рафаэль, ә 1981 елда кече уллары Рушан дөньяга килә. Матур гына тормыш итеп ятканда язмыш аны тагын бер сыный – иңнәренә бик яшьли толлык шәлен яба. Өч балага әни дә, эти дә булырга туры килә яшь ханымга.

«...Беренче мәхәббәт онытылмый икән, – ди Динә апа. – Сирәк кенә сөйләшкәлибез. Аның үз гаиләсе, минем үземнеке... Инде оныкларым җитеп килә. Әле менә хаҗдан бүләк итеп тәсбих алып кайткан...»

Ак яулыгын таратып бәйләгән мөлаем бу ханымнан аклык бөркелә. Шигырьләре кебек, үзе дә гади, ихлас, аңлаешлы ул. Бер көне – табыштан, бер көне сагыштан торган тормышында төп таянычы иҗат булган аның. Бүген дә иҗаттан тәм табып яши Динә Камалетдинова.

Фотолар: гаилә архивыннан.



«ДУСТЫҢ ДА УЛ, КАЙЧАК ДОШМАНЫҢ ДА...»



Альберт ШАКИРОВ,
журналист, продюсер;
гаилә стажы – 8 ел;
ике кыз әтисе (Сәйдә – 7 яшь, Зифа – 3 яшь).

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Беренче урында күзләр дип уйлыйм, аннан – буй-сыны. Ләкин болар беренче караш ташлаган вакытта гына. Үтеп барышлый гына күзгә чалынган хатын-кызлар турында әйткәндә. Әгәр чынлап аралашуга, танышуга килсәк, үз-үзен тотышы, холкы – беренче урында. Нинди генә буй-сын, күзләр булмасын, сөйкемле сөяге, зәвыгы юк икән, андый хатын-кыз берничек тә игътибарны җәлеп итәрлек була алмый минем өчен. Матур кием белән генә шәрә күңелне һәм сай акылны каплап бетерә алмыйсың.

2 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр.

– Алиһә белән торып булмыйдыр ул. Андыйларга кайбер ирләр түзеп торса гына. Өйдә комфорт тудырсын дип кенә хатын алган ирләргә дә авырдыр: син аңа тормышка карашларың турында сөйлисең, ә ул кер чайкарга пычрак киемсалым җыеп йөри... Сәер ул мондый караш. Хатын-кызларны алай гына бүлеп карап булмый. Алар бик катлаулы һәм күпкырлы затлар. Гаиләдә хатын дус та, кайчак дошман да, илһамландыручы да, акча беткәч сукранып ярага тоз сибүче дә. Йорт-җирне ялт итеп тоткан вакытлары да бар, кайчак «иртәгә!» дип, кырын яткан чаклары да. Алар да кеше бит. Ниндидер бер идеальлек кенә көтү яки таләп итү иртәме-соңмы күңел кайту белән тәмамланачак.

3 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Була гына түгел, тиеш тә. Ир кешенең башкалар күрми-белми торган сыйфатларын да, төрле халәтләрен дә, чәчәкле трусиктан өйдә йөргәннәрен дә хатыны гына күреп тора. Хатынны дус буларак та якын итмәсәң, мондый күренешләргә коры мәхәббәт кенә чыдый алмый. Алиһәләр, сөяркәләр кебек кенә яшәп яткан хатынга нәрсәгә күңеле йомшарган, борынынннан төк күренеп торган ир? Ә минә хатын – сөяркә, хуҗабикә генә түгел, дус та булган хатын – аннан да кызык таба беләмени: кирәк булса үзе үк йолкып алып кеше арасына да чыгарып җибәрә. Ир-ат белән хатын-кыз арасын әйтә алмыйм, әмма ир белән хатын арасында дуслык кирәк.

4 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Тәкъдим ясаганчы, телефоннан нәрсәгәдер сүккәнемне хәтерлим... Шуннан Казан үзәгенә чакырып, хәзерге Милли китапханә янында тәкъдим ясадым. Әллә кайларга менеп, әллә нинди фасоннар чыгарып та ясыйсы килгән иде ул тәкъдимне, ләкин никтер вакыт юк иде. Әллә авылга кайтып китәсе бар иде шунда... Ул вакытта акчасы да чамалы булгандыр инде. Иң мөһиме – тәкъдимне кире какмады.

5 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Юк, алай түгелдер. «Килен – кайнана туфрагыннан ярала», дигәнгә ышанам үзе. Анысы – хикмәтлерәк сүз. Киленнәр, дөрестән дә, бераздан кайнаналарының гадәтләрен, сыйфатларын йоктыра башлый. Бер яктан, моңа кайнана белән аралашып тору ярдәм итсә, икенче яктан, ир кеше үскән гаиләсендә күргән тәртипләрне үз гаиләсендә дә алга сөрә. Менә шулай яраклашып, ияләнешеп беткән очракта, килен кеше үз әнисеннән алган тәрбиядән тыш, кайнанаынын да сеңдерә. Читтән карап торган кеше, дрессировка үткән киленнең эшләгәнен, сөйләшкәнен кайнанага охшатмый кемгә охшатсын? Әни белән хатынның уртак гадәтләре исә әллә кайчан бар инде: мин чәй эчәм дип килгәндә генә гомергә каты чәйләре – заваркалары булмый.

6 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Бик тыныч һәм горур тотарга тиеш дип уйлыйм. Хәзерге заманда белеме яки мөмкинлеге булган белгечне иреннән узмасын дип тыеп тору җинаятьтер ул. Дөрес, монда ир кеше генә түгел, хатын да үзен ничек куя бит әле. «Сине кем ашата» ише битәрләүләр ишетелә башласа да күңелле түгел... Гаиләдә кемнеңдер күбрәк акча эшләве ул кеше артыграк эшли дигән сүз түгел. Замана һөнәрләре көнә өч-дүрт сәгать эшләп тә яхшы керем алып тору мөмкин-

леге бирә. Әгәр дә ир-ат тырышып, намуслы эшләп, тәртипле йөреп тә хатыныннан азрак акча ала икән, бу нindiдер кимсенү өчен сәбәп була алмый. Әлбәттә, яхшырак эшкә, күбрәк хезмәт хакына омтылырга кирәк, әмма бөтен кешегә дә барысы да берьюлы бирелми. Гаиләдә тавыш гел акча җитмәүдән чыкса да, аның сәбәпләре күпкә тирәндәрәк.

7 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Уңай карыйм. Чамасын, урынын, сүзләрен дөрес сайлап җиткерсәң, монда бернинди дә әдәпсезлек юк, Тукайга да Зәйтүнә Мәүлетованың үзе килеп хисләрен белдерүе тарихка кереп калган бит. Ләкин монда аның дәрәҗәле гаиләдән чыккан укымышлы, зыялы туташ икәнлеген дә онытмаска кирәк. Кызганыч, безнең заман җәмгыяте бик дорфа, кырыс, тупаска әйләнеп бетте. Янында егете яки ире басып торган хатын-кызга комплиментлар әйтү дә тәрбиясезлек итеп кабул ителә һәм аңлау тапмый. Хатын-кызның кыюлыгы, үз хисләре турында сөйләргә батырчылык итүе дә ешрак бозыклык булып кына күренә. Ләкин болар табигый әйберләр. Гап-гади комплимент та – уйнаш, дуслык, сердәшлек тә сөяркәлек булып күренә икән, бу – карап торучыларның наданлык билгесе. Шуңа стереотиплардан азат булып, мәхәббәт, романтика дигәндә дә хатын-кызга сайлау, үз фикерен беренче белгертү хокукын калдырсак – яхшырак.

8 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип санийсыз?

– Сабыр һәм тыныч, үз көчләренә ышанган ирләргә хатын-кызлар күбрәк игътибар итә дип уйлыйм. Ни дисәң дә, ул гаиләнең иминлеген, бөтенлеген тәэмин итәргә тиешле кеше. Ул тапкан мал Таиландка очарга мөмкинлек бирмәсә дә, көндәлек тормышка җитеп бара икән, димәк, бар да тәртиптә. Хатын-кыз ир-атта иң беренче чиратта шул терәк, яклаучы сыйфатларын эзли дип саныйм. Аннан соң фикердәш, сердәш эзли. Мәхәббәт тә коры җирдә үсеп чыга алмый бит, аңа да нindiдер этәргеч кирәк.

9 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Алай хатын-кызлардан игътибар көтеп йөрим дип әйтә алмыйм. Өйләнгән бит инде мин... Шуңа үз итеп аралашканда уен-көлке белән генә күз кысышасың инде. Шулай булгач, юмор хисенә, тел байлыгына, зирәклеккә басым ясыйм дип уйлыйм. Хатын-кызлар булган җирдә аралашканда дип әйтүем. Юмор булганда барыбер җиңелрәк. Аннан соң, кайсыдыр сыйфатларыңны бик өстен дип санап, үзеңне шул яктан гына күрүләрен көтеп йөрү дә бик дөрес халәт димәс идем. Нindiдер комплекслары булганнарга хас әйберләр ул.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Ирләрнең дә төрлесе була бит. Бардыр курка торганнары да. Хәзер уңышлы карьера төзегән, әмма аерылышкан яки кияүгә чыкмаган хатын-кызлар күп. Шуңа әйтәләрдер. Хатын-кыз нинди эштә эшләсә дә, нинди югарылыкларга ирешсә дә, хатын-кыз инде ул. Аның холкыннан беркая да китә алмыйсың. Әйе, уңышлы карьера төзеп, бик көчле, усал, буй җитмәс булып күренә торганнары бар, әмма бу – аларның саклану ысулы. Аларга игътибар итүчеләр күп, статусына кызыгып танышырга теләүчеләр дә җитәрлек. Әйе, көчле, чибәр хатын-кыз сайлана. Шуңа күрә, суган әрчегәндәге кебек, аның бер кат кабыгын гына салдырып карауга күзләре әчетә башлаган ирләр качу ягын карый икән, куркалар. Андыйлардан читтә булуың хәерле. Ә менә ул хатын-кызның тышкы образын гына түгел, эчке дөньясын да күрә, аңлый белүче ирләр бармак белән санарлык хәзер. Куркаклар күбрәк, һәм моңа хатын-кыз гаепле түгел.

11 Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган очракны искә төшерегез әле.

– Аерым бер очракны әйтә алмыйм, әмма, гомумән алганда, аларның гел бер төркемгә җыелу омтылышын аңламыйм. Хатын-кызлар серләрне дә төркемдә генә саклый дип тә әйтәләр – дөрестер ул. Балалар белән урамга чыксалар да кайдадыр җыелышу ягын карыйлар хәтта. Әлбәттә, кичен арып, бөтенесеннән туеп, балаларның акырышканына чыдый алмаган хәлгә кайтып төшәләр. Зарланалар. «Кемнеңдер баласы бигрәк шук, сүз тыңламый. Безнекенең уенчыгын алды да бирмәде...» – диләр. Ләкин берничә көннән тагын шул төркемгә җыелу, бала карау башлана. Менә шул төркемкөтүне бер дә аңлый алмыйм. Аның эчендә нинди процесслар барадыр.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез?

– Мин юл кую ягында. Аеруча принципиаль әйберләргә кагылганда яки күптәнге ачулар җыелган вакытта гына аяк терәп бәхәсләшә алам. Хатынның бик кызган вакыты булса да, минем әйтә торган сүзем гел бер: «Кычкырышырга вакытым юк». Бу дөрестән дә шулай. Буш бәхәс, талашу – вакытны кирәкмәгәнгә сарыф итү дип исәплим. Талашкан вакытта бернинди дөреслек тә табылмый. Ике як та бербересенең хаклы булуын исбатларга тырышудан башка ният юк анда. Ул дәрәҗәгә барып җитмәскә тырышсаң, әйбәтрәк. Әлбәттә, бик читен, авыр хезмәт, әмма гаилә дискуссия мәйданы түгел, сөйләшү, аңлашу урыны булырга тиеш. Кешенең, юкка нервланып, ачуы кабарып йөргән вакытлары да була торгандыр, андый чакта дәшмәвең хәерле. Үзе бер тынычлана ул, аннан сөйләр җайлап. Бу – ир-атка да, хатын-кызга да кагыла. Дәшмичә җиңә белергә кирәк.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора. Сез нишлисез инде?

– Барысы да вакыттан тора. Әгәр плитә янына басарга вакыт юк икән, заказ бирәсең дә, үз эшләреңне карыйсың. Чыдар әмәлең калмаса, тиз генә йомырка кыздырып ашыйсың. 30 минут вакытың бар икән, аш куярга, пылау ише берәр нәрсә әзерләргә була. Ашарга пешерү күп вакыт алмый бит ул. Продуктларыңны бер әзерләп куйсаң, вакытында кәстрүлгә салып кына торасы. Калганын плитә эшли. Шуңа монда бернинди дә проблема күрмим. Өйгә якынча кайчан кайтасымны хатын сорап-белешеп куя. Ул вакытка ашарга әзер булмаса, йә кичке аш пешерү бөтенләй планга кермәгән булса, бу хакта миңа җиткерә. Андый вакытта йә берәр җирдә тамак ялгап кайтам, йә үзем белән тиз генә пешерерлек балык, гөмбә ише әйбер алырга тырышам. Чыгу юлы һәрвакыт бар. Ашау – чир генә ул.



Фото: Анна Арахамия

«АЛТЫН ВАКЫТ»НЫ ИСТӘН ЧЫГАРМЫЙК

«Бу авыруны дәвалап була, – ди белгечләр. – Бары тик вакытны уздырмаска кирәк». Ә моның өчен һәрвакыт икенчел профилактика турында истә тоту зарур. «Икенчел профилактика гына күкрәктәге яман шеш авыруына каршы көрәштә бердәнбер «корал», – ди танылган табиб-маммолог, онколог, «Онкопрофи» маммология медицина клиникасы җитәкчесе, Татарстанның атказанган табибы Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН. Аның белән әлеге үтә дә четерекле һәм бик тә мөһим темага сөйләшәбез.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА



Клиника сайты: oncoprofi@mail.ru
Клиника адресы: Казан, Себер тракты, 23
ВК адресы https://vk.com/oncoprofi_clinic_kazan

Vkда язылган өчен барлык төр медицина анализларына – 15% ташлама

Язылу өчен телефон: 8 (843) 215-00-03
8.00–20.00 сәгатькә кадәр.

Реклама

Хәсән Маратович, хәзер сәламәт күкрәкле хатын-кызлар сирәк очрый кебек. Моның сәбәбе нәрсәдә икән?

– Сезгә каршы килеп шуны әйтәм алам: авыручыларга караганда, сәламәт кешеләр әллә никадәр күбрәк. Әйе, статистикага күз салсак, ул яман шеш авырулар арасында беренче урында тора. Әмма, башка илләр белән чагыштырганда, бездә азрак. Россиядә 100 мең хатын-кызга 178 авыру туры килсә, шул ук АКШта бу сан – 250. Ә авыру арту нәрсә белән аңлатыламы? Халыкның гомер озынлыгы артты. Бу – факт. Күкрәктә яман шеш авыруы килеп чыгуның

бердәнбер сәбәбе – нәселдәнлек. Дөрес аңлагыз, әбидән, әнидән күчеп килгән бу авыру авыручылар арасында бары 2 процент кына. Калган 98 процентында шеш күкрәк каналларындагы эпителий күзәнәкләрендәге геннар мутациясе аркасында килеп чыккан. Ә моның нәрсәдән килеп чыкканын галимнәр әлегә әйтә алмый. Әйе, дөрес туклану, сәламәт тормыш рәвеше алып бару яхшы, әмма алар да бу авырудан тулы профилактика була алмый. Мәсәлән, авылда яшәүче хатын-кызларда шеш күбрәк табыла. Ә бит аларның туклануы шәһәр халкына караганда сәламәтрәк. Мин моны бары тик шәһәр кешеләренең икенчел профилактика белән ныграк шөгыльләнүе белән генә аңлата алам. «Күкрәкчә кигәннән яман шеш барлыкка килә», дигән халык арасында йөргән фикер дә уйдырма. Юк, ул шеш барлыкка килүгә берничек тә тәэсир итми. Аннан соң бюстгальтер киеп йөрү күкрәкләрне салынудан саклый дип тә уйлый кайбер хатын-кызлар. Бу да сафсата! Күкрәк зур икән, бюстгальтерны тәүлек дәвамында киеп йөрсәң дә ярдәм итмәячәк. Әйе, кечкенә күкрәкләр, үз формасын озаграк саклый. Дөрес, бала табу, бала имезү дә тәэсир итми калмый. Тагын шунысын да әйтәм: күкрәкләрдә шеш барлыкка килү берничек тә аның үлчәме белән бәйле түгел!

Дөрес аңладыммы: хатын-кызларны күкрәктә ямаш шеш авыруыннан бары икенчел профилактика гына коткара ала?

– Бары тик! Ягъни табибка барып күренеп тору, УЗИ йә маммография тикшеренүләре ясату гына коткара ала! Әгәр дә авыруны башлангыч стадиясендә (беренче, хәтта икенче стадиядә дә!) ачыклыйбыз икән, аны дәвалау мөмкинлеге 100 процент. Чөнки авыру билгеле бер процесс буенча бара: шеш барлыкка килә, үсә, лимфа төеннәргә керә, алар буенча башка органнарга күчә. Шеш кечкенә булганда аның лимфа төеннәргә керү мөмкинлеге бик кечкенә. Дәвалану өчен бу «алтын вакыт» инде.

Ә шеш озак үсәме?

– Төрле кешенеке төрлечә. Шуңа күрә 30 яшьтән өлкәнрәк хатын-кызларга елга бер мәртәбә маммологка күренеп тору мөһим! Шеш барлыкка килә икән, 12 айдан соң без аны күрә алачакбыз. Бу – адекват интервал.

Күкрәк алдыру хатын-кызлар өчен психологик яктан бик авыр процесс...

– Сезнең белән килешәм. Бу әле хатын-кызларның дәваланырга йөрмәүләренең бер сәбәбе дә. Шеш кечкенә булса, без күкрәкне саклап та кала алабыз. Әгәр алырга туры килсә, хәзер ясалма күкрәк кую киң үсеш алган. Күкрәкне операция барышында ук реконструкцияли алабыз. Бу мәҗбүри медицина имминиятләштерүе буенча бушлай һәм имплантлар гомерлек.

Хәсән Маратович, күкрәкне алдыруга барып җитмәс өчен, үз-үзеңне тикшереп тору да мөһимдер?

– Иң яхшысы – табибка бару, әлбәттә. Әмма үз-үзеңне тикшереп тору да кирәк. Ә аны дөрес эшләр өчен мондый киңәш бирәм. Табибта бер кат тикшерелеп кайтканнан соң, күкрәгегезне ныклап капшап чыгыгыз. Моны ятып, күкрәкне бер кул белән басып, икенчесе белән капшарга кирәк. Шул рәвешле, сәламәт күкрәкнең нинди булуын исегездә калдырачаксыз. Үзегезне ай саен тикшереп торыгыз. Моны күрем циклының 6–16 нчы көннәрендә эшләргә кирәк. Күрем килүе туктаган хатын-кызлар кайчан да тикшерә ала. Кечкенә генә төен хасил була икән, аны шунда ук сизәчәксез. Бу инде кичекмәстән табибка барырга кирәк дигән сүз.

Ә нинди тикшеренү узу яхшырак: УЗИмы, маммографиямe?

– Ул хатын-кызларның яшенә бәйле. Яшь икән, әлбәттә, УЗИ тикшеренүе яхшы. Чөнки аларның күкрәк консистенциясе тыгыз, аның аша рентген нурлары үтмәячәк. 45 яшьләр тирәсендәге хатын-кызларның күкрәген караганнан соң нинди тикшеренү узарга кирәклеген табиб билгели. 45 яшьтән соң маммография билгелиләр. Ә маммографияне күкрәктә яман шеш авыруын диагностикалауның алтын стандарты дип әйтү – 45 яшьтән соң авыру мөмкинлеге арту белән бәйле. УЗИ шешне күрми дигән сүз түгел әле бу. 5–7 миллиметрлы шешне ачыклый алабыз инде.

Үсмер кызның әнисе буларак, мине тагын бер сорау борчый: аларның күкрәгендә яман шеш барлыкка килә аламы?

– Юк. Хәтта 18 яшьтә дә бу авыру очрамый диярлек. 22 яшьтә барлыкка килүе дә миллионга бер генә булырга мөмкин әле. Әйткәнемчә, күкрәктә яман шеш авыруының иң югары ноктасы 40 яшьтән соң гына. Дөрес, һәр яшьнең үз авыруы бар. Үсмерләрдә һәм яшь кызларда фиброаденома очрый. Куркырга кирәк түгел, ул – яман булмаган шеш. Әмма тикшерелеп тору зарур. 18 яшьтән соң кызларга маммологка ике елга бер тапкыр күренеп торырга киңәш итәм.

Хәсән Маратович, халык медицинасы белән дәвалануга фикерегез нинди?

– Әгәр дә пациент хастаханәдә тулы күләмдә дәвалану курслары алган булса, мин каршы түгел. Әмма бер шарт бар: ул организм өчен зыянлы булырга тиеш түгел. Мәсәлән, елан көпшәсе (болиголов) төнәтмәсе эчүгә каршы мин. Ул бавыр өчен зыянлы.

Безне укучы хатын-кызларга теләкләрегез...

– Сәламәт булсыннар! Минем теләгем бер генә инде: үзегезнең генә түгел, әбиләрегезнең, әниләрегезнең, кызларыгызның сәламәтлеген кайгыртыгыз. Моның өчен күп вакыт та кирәкми бит. Елга бер табибка барып күренү дә җитә. Безнең илдә шундый сәер гадәт бар: яман шеш табарлар, дип, табибка бармыйлар. Ә чит илләрдә, киресенчә, яман шеш авыруыннан куркып, табибка йөриләр. Күкрәктә яман шеш башка авырулар кебек үк авыру, бары тик стадиягә генә бәйле. Шуңа күрә дә, алдан әйткәнемчә, «алтын вакыт»ны кулдан ычкындырмаска кирәк.



Фото: ru.freepik.com



Сорауларга Республика балалар клиник хастаханәсенең аллергология бүлеге мөдире Гөлнара ЗЫЯТДИНОВА җавап бирә.

Ирем 30 яшендә аллергиядән азаплана башлады. Төчкерә, борынынннан ага. Аллергия нәсел буенча әтидән балага күчәргә мөмкинме? Улыбызда аллергия булмасын өчен нишләргә?

Аллергия – күп факторлы авыру. Шул факторларның берсе – генетик бирешүчәнлек. Әти-әнинең берсендә генә аллергия күзәтелсә, балада аның булу мөмкинлеге 30–40 процент тәшкил итә. Баланы озаграк имезгән саен, анда аллергия башлану куркынычы кими дигән нәтиҗә чыгара кайбер тикшерүләр. Имезүче әнидә аллергия булса, рационнан аллергия китереп чыгара торган продуктларны алырга киңәш итәм. Әнидә аллергия булмаса, махсус диета сакларга кирәкми.

Баллы ашаганнан соң кайвакыт баланың тәненә вак бетчәләр чыга. Берничә сәгатьтән бетә үзе. Организмга аллергияне үзенә җиңәргә мөмкинлек бирергәме, әллә хәзер үк дәвалый башларгамы?

Бетчәләрне табибка күрсәтергә кирәк. Чөнки баллы ризык аллерген була алмый. Сөт, йомырка, балык, диңгез продуктлары, бодай, соя, чикләвекләр югары аллергик продуктлар дип санала. Составында консервантлар, буягычлар булган продуктлар турында сүз барадыр дип уйлыйм. Алар псевдоаллергик реакция китереп чыгарырга мөмкин.

Үз өебездә балада бернинди аллергия дә күзәткән юк иде. Ә минә әбиләренә кунакка баргач, төчкерә башлый. Моның сәбәбен ничек ачыкларга?

Сезгә аллерголог-иммунолог консультациясе кирәк. Анамнез җыеп, аллергик фонны төгәлләгәч, балада аллергия булу-булмау куркынычын ачыклагач, аллергия китереп чыгара торган факторлар табыла, өйдәге мохит үзенчәлеге билгеләнә. Аннары табиб сәбәбен ачыклар өчен аллергологик тикшерү уздыра. Шуннан соң дәвалау һәм профилактика буенча киңәшләрен бирә. Сезнең очракта, бәлки, әбиегезнең өендә аллергия китереп чыгара торган сәбәпләр бардыр – өй тузаны талпаны, йорт хайваны, күксе гөмбәләр һәм башкалар.

Бала аллергик булса да, педиатр прививкалар ясатырга куша. Прививка аллергияне тагын да катлауландырмыймы?

Аллергия авырулары прививкадан баш тарту өчен сәбәп түгел. Әлбәттә, авыруның кискенләшкән чорында прививканы кичектереп торырга кирәк. Бу чор узгач, тиешле прививкаларны ясатыгыз.

Нәниләргә күчтәнәч!
Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



Кадерле әниләр!
«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.



Сорауларга «Азино» балалар сырхауханәсе мөдире, табиб Гөлнара СЕМЁНОВА җавап бирә.

1 яшьлек балабыз еш авырый, ел дәвамында өч тапкыр рентген узарга туры килде. Рентген нурлары балага зыянлымы? Заманча аппаратларның йогынтысы юк диярлек, ди табиб.

Медицина тарафыннан уздырылган манипуляцияләрнең бер еллык нурланыш дозасы – 1 миллизиверт. Рентген снимогы 0,1 миллизиверт кына тәшкил итә. Башка төр нурланышлардан күпкә кимрәк бу сан. Балага билгеләнгән һәр тикшерү нигезле була һәм аңа дөрес дәва бирү өчен кулланыла, зыянга караганда, файдасы күбрәк.

Чыныктыру өчен 1 яшьлек баланы чишмә суы белән коендырырга ярыймы?

1 яшькә кадәр баланың терморегуляциясе камилләшергә өлгерми әле. Аларга организмда җылылыкны сакларга авыррак, шул сәбәпле, тиз туңалар һәм шулай ук тиз җылыналар. Бәләкәй балаларга процедуралар өчен 24–28 градуслы су кулланырга кирәк. Чишмә суы 4–6 градуста гына була. Баланы андый суда коендыру тире сосудлары спазмнарына һәм баланың туңуына китерәчәк. Бала сәламәтлеге өчен бик куркыныч бу!

1 яшьлек балабыз төнлә генә түгел, көндез уйнап йөргәндә дә тешләрен шыгырдата. Бу гадәттән ничек арындырырга? Сәбәбе нидә булырга мөмкин?

Тешләрне шыгырдату бруксизм дип атала. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда ешрак күзәтелә. Бала үсә төшкәч, бу күренеш үзеннән-үзе уза, ләкин кайбер очракларда теш эмаленә зыян салырга, чигә-аскы казналык буыннары патологиясенә китерергә мөмкин. Теш шыгырдату бабасырлар белән берничек тә бәйле түгел. Бер тикшеренү дә бу закончалыкны исбатламады. Шуңа күрә теш шыгырдаткан балага гельминтларга каршы дарулар бирү тыела. Бруксизмның сәбәбе стресс та булырга мөмкин, андый балаларга психолог консультациясе кирәк. Бала тешләрен аеруча нык шыгырдатса, махсус саклаучы кап киеп йөрергә туры киләчәк. Аны сайлауда стоматолог ярдәм итәр.

СОРАУ—ҖАВАП

Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

КӨЗЕН ТУКЛАНУ РАЦИОНЫ

Сизәсездер, кояшлы эссе җәйдә без азрак ашыйбыз. Ит, чикләвек кебек энергия бирә торган ризыкларга да артык исебез китми. Күбрәк җиләк-җимеш кулланабыз. Ә инде көннәр суынып, көзге җилләр исә башлауга туклану рационыбыз да үзгәрә. Күбрәк һәм туклыклырак ашыйбыз. Салкын вакытта энергия күп китә чөнки. Ә көзен ничек дөрес тукланырга? Бу хакта сорауларны интегративлы медицина табибы, диетолог, нутрициолог, healt-коуч Айгөл ФАЗЛЫЕВАга бирдек.

Көз көне организм нинди витаминнарга мохтаҗ?

Кешенең җәй көне ничек тукликануы белән бәйле. Әгәр дә ашау тәртипсез рәвештә булган булса (фастфудлар, иртәнге ашны ашамау), организмда җәйдән соң да витаминнар дефициты күзәтелергә мөмкин. Туклану рационы дөрес төзелгән булса, кирәгенчә йокланса, саф һавада күп йөрелсә, стресс кичерелмәсә, ашкайнату-эчәк тракты дөрес эшләсә, әлеге проблема булмаска да мөмкин. Җәй буе кеше үзендә күп энергия барын тоеп, кәефе яхшы булып, көз җитүгә хәле китә башласа, димәк, аңа кояштан алган Д витамины җитми дигән сүз.

Көзен ит ише ризыкларны күбрәк ашарга кирәкме?

Иттә организмдагы барлык процессларны булдыру өчен кирәкле аминокислоталар бар. Шуңа күрә дә рационда ит булырга тиеш, әмма һич тә кичке ашта түгел. Чөнки ул авыр эшкәртелә торган продукт. Идеаль вариант: итне яшелчәләр белән төшке аш вакытында ашау. 40 яшьтән соң ашказаны согы эшкәртелүе кими, бу исә ит продуктларын эшкәртүне авырлаштыра. Әмма безнең организмга аксым кирәк. Ә ул тавык, күркә итләрендә, балыкта, диңгез продуктларында, йомыркада, кузаклыларда бар.

Депрессия вакытында сары төстәге җиләк-җимеш, яшелчәләрне ашарга киңәш итәләр. Көз көне дә мондый «сары» ризыклар ашау мөһимме?

Әйе шул, сары, кызгылт-сары төстәге ризыклар кәефне күтәрә дигән фикер бар. Шулай да мин тәлинкәдә салават күперенең барлык төсләре булуы яклы. Ягъни ашау төрле булырга тиеш. Шунда гына баланс сакланачак. Ләкин бер шарт бар: ашкайнату системасы сәламәт булырга тиеш.

Көзен көн кыскара. Кояш витаминын ничек җиткерергә?

Д витамины диңгез продуктларында, йомырка сарысында, сыйфатлы атланмайда бар. Аларны актив рәвештә көндәлек рационга кертегез. Әлеге ризыклар башка витамин һәм минералларга да бай.

Су балансын саклау көзен дә мөһимме?

Су балансын саклау ел әйләнәсендә актуаль. Гади генә итеп аңлатканда, ул кан үзенчәлеген, терморегуляцияне яхшырта, кан басымын нормальләштерә. Ашкайнату системасы өчен дә файдалы. Онытмагыз: ашкайнату согы составында да су бар. Су – безнең организмны табигый чистартучы. Ул токсиннарны куа.

Көзен нинди витаминнар кабул итү мөһим?

Ул һәр кеше өчен индивидуаль. Мин витаминнарны теләсә ничек куллануга каршы. Анализ нәтиҗәләре буенча белгеч белән киңәшләшкәннән соң гына билгеләнергә тиеш алар.

Көз көне ашау рационы ниндирәк булырга тиеш?

Өстәлебездәге продуктлар сезонлы булса яхшы. Салкын вакытта майларга бай ризыклар: атланмай, майлы ит (бу, билгеле, артык авырлыктан, кан басымыннан интеккән, ашкайнату-эчәк трактында авырулары булган кешеләргә кагылмый), чикләвекләр (килешәсездер, без аларны җәй көне азрак ашыйбыз) ашарга киңәш итәм. Моннан тыш, ашаган ризык җылы йә кайнар булсын. Шулай ук бу вакытта тозлы кәбестә ашау файдалы. Ул пробиотик булып тора, С витаминына да бай.

Фото: Любовь Коваль

СТРЕССНЫ ЧЫГАРАБЫЗ

Ашыгу-кабалану, җитешмәү, стресс, даими киеренкелек – болар хәзерге тормышның төп күренешләренә әйләнеп бара. Мондый халәт кешене депрессиягә җиткерергә дә мөмкин. Үз-үзеңә ярдәм итмәсәң, беркем ярдәм итми, диләр. Эмоциональ яктан артык нык арып китсәгез, йә юкка гына нервларыгыз кузгалса, дару эзләргә ашыкмагыз, тиз генә стресска каршы күнегүләр эшләгез. Алар психоэмоциональ киеренкелекне бетерә, тынычландыра, эшчәнлек сәләтен, игътибарны арттыра. Ашау һәм йокы да җайланачак. Күнегүләрне матурлык экспертыбыз Ләйсән САБИТОВА өйрәтә.











■ Бу күнегү өчен каеш йә фитнес резинкасы кирәк булачак. Каеш белән соңгы кабыргалар турысыннан гәүдәне урап алабыз. Диафрагма белән сулыйбыз. Сулыш алганда кабыргалар ярдәмендә каешны этәбез, сулышны чыгарганда каешны кысабыз. Күнегүне саграк эшләгез, артык нык кысып, кабыргаларга зыян сала күрмәгез.

■ Куллар белән арканы «камчылыйбыз». Кулларны кисештереп, уң кул белән – сул яктан, сул кул белән уң яктан буйдан-буйга арканы сукккалыйбыз. Гәүдәне әле – уң, әле сул якка боргалап та бу күнегүне эшлибез.

■ Туры итеп басабыз. Борын аша сулыш алганда кулларны өскә күтәрәбез, сулышны чыгарганда кулларны аска төшерәбез, гәүдәне дә 90 градуска иябез.

■ Аякларның әле берсен, әле икенчесен ике куллап каккалап чыгабыз: башта – тездән өстән, аннары гына тездән астан. Игътибар итсәгез, бу күнегүне спортчылар бик еш эшли. Болай итеп алар мускулларын киеренкелектән чыгара. Без дә шулай итеп мускулларга ярдәм итәбез.

■ Йодрык белән җиңелчә генә ике кулны да суккалап чыгабыз.

■ Бармак очлары белән әкрен генә йөзне, башны каккалыйбыз. Ахырда чәчләрне, төбеннән тотып, тартып-тартып алабыз.

■ Кул-аякларны селеккәләп, стресска каршы күнегүләрне тәмамлыйбыз.








QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Кабактан – чуду

Көзен, кабаклар өлгергәч, укучыларыбызга әлеге яшелчәдән берәр яңа рецепт тәкъдим итү журналыбызның күркәм бер традициясенә әйләнде. «Аш-су» сәхифәсенең бүгенге кунагы Ләйсән НУРГАЛИЕВА бу юлы безне кабактан чуду пешерергә өйрәтә. Чуду – Дагстан халкының милли ризыгы. Аны төрлечә әзерлиләр. Язын – кычыткannнан, җәен – кузгалактан, ә көзен, әлбәттә инде, кабактан! Ләйсән – Казан кызы, Әмир белән Әминәнең, бәләкәй Аланның әнисе. «Гаиләбез ишле, теләсәң-теләмәсәң дә оста кулинар булырга туры килә, – ди ул. – Аш-суга маһирлык татар хатын-кызларының геннарына салынгандыр инде. Мин үзем дә пешеренергә бик яратам, төрле халыкларның кухнялары белән кызыксынам. Әбием дә, әнием дә чып-чын аш-су осталары. Кайнанамнан да күп нәрсәгә өйрәнәм, без аның белән күршеләр генә, табыныбыз уртак».

Ләйсәннең мавыгуы кулинария гына түгел. Музыка мәктәбенең фортепиано сыйныфын тәмамлаган ханым өчен җыр-моң дөньясы да ят түгел. Сәяхәт итәргә, күргән-белгәннәре хакында социаль челтәрләрдә фикер алышырга да ярата ул. Аның сәхифәсе тәмле рецептларга да бай. Әйдәгез әле, без дә Ләйсәнгә ияреп, җиңел кулдан тиз генә кабаклы чудулар әзерлик. Ышаныгыз, үзегез өчен кабакның тәмен яңача ачачаксыз.

Кирәк

Камыр өчен: 1 стакан кайнаган салкын су (200 мл) / 2 аш кашыгы үсемлек мае / тәменчә тоз / 350 г он (он кимрәк яки күбрәк кирәк булырга да мөмкин).
Эчлек өчен: 0,5 кг кабак / 1 баш суган / бер уч әстерхан чикләвеге (8–10 данә) / тәменчә кара һәм кызыл борыч / тәменчә тоз / үсемлек мае.



Эш барышы


■ Онны зуррак савытка илибез. Уртасын чокырлап, су, тоз, үсемлек мае салып, камыр басабыз. Камыр үзебезнең кыстыбыйга әзерләгән кебек булсын. Әзер камырны тастымал белән каплап, бераз ял иттерәбез.
■ Суганны вак кына турап, үсемлек маенда алтынсу төскә кергәнче кыздырабыз.
■ Кабакны чистартып, уртача угычтан уабыз.
Кул белән кыскалап, суын сыгабыз.
■ Чикләвекне коры табада аз гына кыздырып алабыз. Суынгач, кул белән угалап, кабыгыннан арындырабыз һәм ваклыйбыз. Аны тактага салып, уклау белән вакла-вы җайлырак. Чәчелмәсен өчен, пергамент кәгазе белән капларга мөмкин.
■ Кабакка кыздырылган суган, вакланган чикләвек, тоз, кара һәм кызыл борычны салып, барысын бергә яхшы-лап болгатабыз.
■ Камырны 10–12 тигез өлешкә бүлеп, бәләкәй шарчы-клар әвәлибез. Һәр шарчыкны кыстыбыйга җәйгән шикелле уклау белән түгәрәкләп җәябез.
■ Чудулар тигез, матур булсын өчен, җәйгән җәемне тәлинкә белән тигезләп кисәргә дә була.
■ Җәемнең бер як яртысына юка гына итеп эчлекне ягып, икенче яртысы белән каплыйбыз. Кырыйларын бармак бите белән баскалап ябыштырабыз. Чәнечке очы белән дә ябыштыра аласыз.
■ Чудуны кызган коры табага салып, ике ягын да кыздырабыз.
■ Кайнар чудуларны бүлмәдә торып йомшарган атлан-май белән майлап, зур тәлинкәгә өя барабыз. Атланмай-ны эретеп тә майларга мөмкин.
Кабаклы чуду кайнар килеш тәмле. Хуш исле чәй пеше-реп, барысын да тизрәк табынга дәшегез. Кабак яратмыйм, дигән кеше дә битараф кала алмас бу ри-зыкка.


















Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



PRESSA

Өйнең яме — гөлләрдә



Кичке якта яфракларын өскә таба күтәреп, иртән төшергәнлектән, халык калатеяны «гыйбадәт гөле» дип атый. Чуар матур яфраклы бу гөлнең төрләре күп. Ул чәчәк тә ата, ләкин аларны купшы дип әйтеп булмый. Тропик үсемлек буларак, җылыга һәм яктылыкка мохтаҗ.
Җәй көне туры караган кояш нурларыннан аны сакларга кирәк.
Иң яхшысы – җиңелчә күләгәле якты урын сайлау. Температураның кисәк уйнавын һәм үтәли җилләрне авыр кичерә. Аның өчен җылылык ким дигәндә 16 градус булырга тиеш, түбәнрәк температурада ул чирли, корый. Суның сыйфатына да сизгер. Йомшак суны тондырып һәм җылытып кына сипкәнне ярата. Язын һәм җәен суны мул итеп, гөлнең туфрагы дымлы булып торырлык итеп сибәләр, ләкин тәлинкәгә җыелган суны түгәргә кирәк, югыйсә тамырлары чери башлый. Һаваның дымлылыгы 90 процент булганда гына калатея үзенең бар матурлыгын күрсәтә ала. Ләкин бүлмәдә мондый дымлылыкны тотып булмый, шунлыктан гөлне еш коендырырга яки яфракларына су бөркергә туры килә. Бу ысул шома һәм каты яфраклы калатеялар өчен генә ярашлы, бәрхет яфраклы төрләре өчен түгел. Яздан башлап калатеяны декоратив яфраклы гөлләр өчен әзерләнгән ашламалар белән туклындырырга кирәк. Ашлауны ике атнага бер башкаралар. Яшь гөлне – ел саен, картракларын ике-өч елга бер күчереп утырталар. Калатеяга артык зур булмаган киң һәм сай чүлмәкләр яхшы. Туфракның исә рододендроннар өчен булганы отышлы. Үрчетергә теләсәгез, күчереп утыртканда зур гөлнең тамырларын бүлгәләргә мөмкин. Яшь тармакларны да тамырландырырга була.



Башка гөлләр үстерү турында да укыгыз.

Бугенвиллея – иркен һәм якты урынны ярата. Кояш кимендә биш сәгать туры караган көньяк тәрәзә төбендә яхшы үсә. Яктылык җитмәсә, сабаклары озыная, яфракларының төсе тоныклана. Үтәли җилләрне өнәмәсә дә, бүлмәдә һава тонып торганны яратмый. Кышын җылылык 10 градустан түбән төшми торган якты лоджиядә үстерергә була. Урын алыштырганны авыр кичерә. Җәй көне температураның 22–25 градус булуы кулай. Көзен һәм кышын, тынлык чорында температура 12–16 градус та җитә. Бу вакытта аның яңа чәчәк бөреләре формалаша. Салкынча урын таба алмасагыз, кышын да гөлне 12 сәгать буена ясалма яктыртырга туры киләчәк. Бугенвиллея һаваның дымлылыгына сизгер. Җәй көне гөл тирәли су бөркеп, дымлылыкны арттырырга була, ләкин чәчәкләргә су тидерергә ярамый. Гөлнең туфрагы гел дымлы, ләкин артык юеш булмаска тиеш. Тондырылган йомшак һәм җылымса суны туфракның өсте кипшергәч кенә сибәләр. Суны тәлинкәгә агып чыгарлык итеп сибәргә кирәк, ләкин тәлинкәдә су калдырмагыз. Кышын су сибүне сирәгәйтәләр. Яфракларын койса, сугаруны бөтенләй туктатып торырга кирәк. Язгы-җәйге чорда ике атнага бер фосфор, калий, тимергә бай ашламалар белән тукландыру сорый, шул чагында гына мул итеп чәчәк атачак. Яшь гөлне ел саен яз көне күчереп утырталар. Аңа савытның тарын һәм биеген сайлагыз. Картрак гөлләрне өч-дүрт елга бер, туфрагы белән бергә бушатып кына күчерергә кирәк. Бер савытка төрле төстәге ике сорт утыртсагыз, аеруча матур күренәчәк. Язын гөлне корыган, авыру ботаклардан арындыралар, ә көзен сабакларын кыскартып кисеп, гөлне формалаштыралар. Бугенвиллеяне яшь тармакларны тамырландырып үрчетүе отышлырак ысул санала.





Монстераның атамасы – монстр сүзеннән. Җилпәзә сыман зур яфракларыннан куркыныч күләгәләр төшкәнгә шулай атаганнардыр, мөгаен. Мәңге яшел әлеге лиана бүлмәдәге һаваны ионлаштыра.
Ул бик шәп синоптик та – яңгыр алдыннан яфракларында тамчылар пәйда була. Ләкин бу тамчылар, гомумән, гөл үзе дә агулы. Монстера кояш нурлары туры карамаган якты урында яхшы үсә. Яктылык җитәрлек булмаса, яфраклары вагая, бөтәрләнә, төсе тоныклана. Температурага артык таләпчән түгел, шулай да җылыда тизрәк үсә. Оптималь температура – 20–25 градус. Кышын җылылык 10 градустан да түбән булмаска тиеш. Үтәли җил йөргән урынны да яратмый. Җылы вакытта суны даими сибеп торуны сорый.
Яфракларына су бөркегәнне ярата. Яхшы туфракка утырткан яшь гөл тукландыруга мохтаҗ түгел.
Зур гөлне исә яздан җәй ахырына кадәр ике атнага бер тукландырып торырга кирәк. Монстераның зур-зур яфракларына терәү дә кирәк булачак. Үсеше акрынайганнан соң, гөлнең өске очын кыскартып, ян тармакларның үсешен активлаштыралар. Һәрбер яфракның үз һава бүлбесе үсеп чыга. Аларны өзәргә кирәкми, гөл төбенә генә салырга кирәк. Тәрбия җитсә, монстера чәчәк тә атарга мөмкин. Беренче ике елны гөлне ел да күчереп утырталар. Аннары моны ике елга бер генә башкаралар. Ә мөнә биш еллык гөл дүрт елга бер генә күчерелә. Шулай да туфракның өске ягын ел да алыштырсаң яхшы. Монстераны ян тармакларны тамырландырып үрчетәләр. Тизрәк тамырландыру өчен, һава бүлбеләре булган яшь тармакларны алырга кирәк.

Фото: ru.freepik.com

тест: проблемаларыгызны үзегез чишәсезме?

Үз мәшәкатьләрен үзләре хәл итеп, башкалардан ярдәм көтмичә яшәүчеләр була. Ә кемдер юк кына мәсьәлә алдында да коелып төшә. Үз-үзебезне тикшереп карыйбызмы, кайсы төркемгә керәбез икән?

1. Үз проблемаларыгыз турында сөйләргә яратасызмы?
а) юк, чөнки бу миңа булышмый (3 очко); б) тыңлар өчен җайлы кеше булса, сөйлим (1); в) һәрвакыт түгел, һәркемнең үз мәшәкате үзенә җиткән (2).

2. Берәр күңелсезлеккә очрасагыз, артык борчыласызмы?
а) һәрвакыт һәм бик нык (4); б) нинди хәл булуга бәйле (0); в) бу хәл белән килешәм, чөнки иртәме-соңмы бар да узачак (2).

3. Бик нык кәефегез төшсә, нишлисез?
а) үземә берәр төрле рәхәтлек табам (0); б) якын дусларым янына барам (2); в) үз-үземне жәлләп, ялгызым гына калам (4).

4. Якын кешегез үпкәләтсә?
а) үз-үземә бикләнәм (3); б) аңлашырга тырышам (0); в) бу хакта башкаларга да сөйлим (1).

5. Үземне бәхетле тойганда:
а) бәхетсезлек турында уйламыйм (1); б) бу бәхетнең вакытлыча булганын уйлап борчылам (3); в) тормышта бәхетсезлекнең дә еш очравын исемнән чыгармыйм (5).

6. Психиатрларга ничек карыйсыз?
а) аларның пациенты булырга теләмәс идем (4); б) алар күп кешегә ярдәм итә алыр иде (2); в) һәркем үзенә үзе булыша ала (3).

7. Сезнеңчә, язмыш:
а) сезне гел сыный (5); в) сезгә карата миһербансыз (2) б) сезнең яклы (1).

8. Яраткан кешегез белән ачуланышып, ачуыгыз узгач, ни уйлыйсыз?
а) ул кеше белән кичергән күңелле мизгелләрне (1); б) аннан берәр ничек үч алу турында (2); в) аның аркасында күргән авырлыкларны (3).

Балларны саныйбыз.

7–15 балл. Сез тормышыгыздагы күңелсезлекләр, хәтта бәла-казалар белән җиңел генә килешәсез, чөнки аларга дөрес бәя бирә беләсез. Авырлыклар килде дип, үз-үзегезне жәлләп утырмыйбыз, гәрчә бу көчсезлек бик күпләргә хас сыйфат. Сабырлыгыгыз сокланырлык.

16–26 балл. Сез еш кына язмышыгыздан зарланасыз. Проблемагызны һәм күңелсезлекләрне башкаларга да тагарга тырышасыз. Сезне кемдер жәлләргә тиеш. Сезгә, бәлки, үзегезне бераз кулда тота белергә өйрәнергәдер?

27–36 балл. Сез әле үз проблемагызны үзегез генә хәл итә белмисез. Күңелсезлеккә очрагыз, үзегезне жәллисез, эчегезгә йомыласыз. Проблемаларны мөстәкыйль хәл итәр өчен сезгә кыюлык җитми. Проблемалар бер сездә генә түгел, бөтен кешедә дә бар.

йолдызнамә ноябрь

Кучкар. Перспективалар турында уйлар вакыт. Якыннарыгызның ярдәменә таяныгыз, бергәләп тотынсагыз, күбрәккә ирешә алырсыз. Акчалар белән сак булу сорала. Сәламәтлеккә дә игътибарлырак булсагыз иде.

Үгезбозау. Эчке үсеш чоры. Мөнәсәбәтләрнең яңа дәрәҗәсенә ирешерсез. Ияләнгән юлдан бераз читкә тайпылырга да туры килүе ихтимал. Моннан куркырга кирәкми, яңалыклар сезнең файдага булачак.

Игезәкләр. Вакыйгаларның үзәгендә кайнарсыз. Хисләрнең таркаурак чагы, игътибарлырак булыгыз. Бигрәк тә бизнес белән шөгыльләнүче кешеләргә кагыла бу. Хәзергә җитди карарлар кабул итүдән тыелып тору яхшырак.

Кысла. Катлаулырак чор, ләкин сез хәл итә алмаслык вакыйгалар көтелми. Эштә ниндидер үзгәрешләр булуы ихтимал. Бу исә сезнең өчен күптән хыялланган яңа мөмкинлекләр ачачак.

Арыслан. Үз-үзегезне камилләштерү, белемегезне арттыру өчен яхшы вакыт. Тиз керем алам, дип ашыкмагыз, төрле авантюралардан сак булыгыз. Үзегезгә күптән таныш эш белән шөгыльләнү файда китерер.

Сөмбелә. Беренче планда эш булачак. Үзегез өчен яңа мөмкинлекләр ачарсыз. Тормышның вак-төякләренә артык игътибар итми торыгыз, сезгә иҗат кирәк. Эчке сиземләүгә таяныгыз, ул алдамас. Сәламәтлекне кайгыртырга онытып җибәрмәгез.

Бизмән. Ыгы-зыгылы ай. Күп көчегезне алган ниндидер вакыйга көтелә. Нәрсәнедер корбан итәргә туры килер. Якын танышыгыз булмаган кеше белән зур проектка тотынмагыз, оттыру ихтималы бар.

Чаян. Приоритетларны кабаттан билгеләргә туры килер. Яңалыклардан курыкмагыз, үзгәрешләр файдага гына. Бар көчегезне файдаланырга туры килер, карьера үсешендә яңа мөмкинлекләр ачылыр.

Укчы. Моңарчы тәвәккәлләргә курыккан эшләргә рәхәтләнеп тотына аласыз. Яңа эш башлар өчен кулай чор. Күңелегез кушканча гамәл кылсагыз, уңышка ирешерсез. Финанс өлкәсендә яхшы үзгәрешләр көтелә.

Кәҗәмөгез. Хыяллар чынга ашар ай. Үзегезгә нәрсә кирәген яхшы беләсез. Сайлау алдында калсагыз, вакытны сузмагыз. Зур әйберләр сатып алу, җитди карарлар кабул итү өчен отышлы чор. Сәламәтлеккә кагылышлы проблемалар уңай хәл ителәчәк.

Сукояр. Корган планнардан тайпылырга туры килмәгәе. Инде күптән сезнең игътибарны көтеп яткан эшләр калкып чыгар. Хәзер күп нәрсәне реакциягезнең тизлеге хәл итәчәк. Танышларыгызга таяна аласыз.

Балыклар. Профессиональ дәрәҗәгезне күтәрергә, үзегезне күрсәтергә яхшы форсат чыгар. Романтикага һәм хисләргә бай ай. Ай уртасында көтелмәгән күңелле вакыйга булуы ихтимал.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.







ЯКТЫ ТӨСЛӘР ПАЛИТРАСЫ

Махсус һөнәри белеме булмаса да, аның картиналары Третьяков дәүләт галереясында саклана! Сүзем – үз әсәрләре белән сәнгать тарихына кереп калган талантлы рәссам Әдия Ситдыйкова хакында.

Әдия исеме «гади» дип тәрҗемә ителә. Ул үз сәнгатендә дә бары гадиләштерү алымын гына кулланган кебек, әмма бу беренче карашка гына шулай. Рәссам композицияләренә ныклы уйланулар аша килә.


Әдия Хәбибулла кызы 1913 елда Казан губернасының Мордва авылында (хәзерге Әгерҗе районында) туган. Гаиләдә биш бала үскәннәр. Кыз кечкенәдән оста итеп теккән, чиккән, рәсемнәр дә ясаган. Ә менә иң беренче картинасын... нибары 45 яшендә язган.
16 яшеннән үк читкә китеп, Урта Азиядә, аннары Мәскәү янында яшәгән. 1934 елны Уфага килгән. Кечкенә улы Сирень белән берүзе калган Әдияне язмышы иҗатка китергән. Уфадагы Сынлы сәнгать остаханәләренең берсендә хезмәткәр булып эшли башлаган. Остаханәләр җитәкчесе, рәссам Рәшит Нурмөхәмммәтов исә аңа Сынлы сәнгать фондының сынлы сәнгать остаханәләре студиясендә укырга киңәш иткән. Сәләте булуын күргәч, иҗатта актив булырга да өндәгән.

1958 елда рәссамның картиналары беренче тапкыр республика күргәзмәсенә куелган. Ике елдан соң Әдия Хәбибулла кызы инде беренче шәхси күргәзмәсен дә ачкан. Һәм нибары курслар гына тәмамлаган сәләтле иҗатчының хезмәтләрен барысы да уңышлы дип тапкан. 1960–1970 елларда рәссам күп эшләрен пастель каләмнәре белән дә ясаган.

Сәләтле, тырыш ханым 1983 елда БАССРның халык рәссамы исеменә, 1993 елда Башкортстан Республикасының Салават Юлаев исемендәге премиясенә лаек булган. Әдия Ситдыйкованың үзенчәлекле картиналары илнең күп кенә шәһәрләрендә һәм Венесуэла, Бөекбритания, Германия, Швеция, Япония кебек дәүләтләрдә узган утызга якын күргәзмәләрдә дә катнашкан. Аларның күбесе бүгенге көндә БДБ дәүләтләре музейларында, шул исәптән, Башкортстанның М. В. Нестеров исемендәге дәүләт сынлы сәнгать музеенда да саклана. Рәссам әсәрләре – күңел байлыгын якты төсләрдәге палитра аша күрсәткән шатлыклы, тыныч, бәйрәм рухындагы хезмәтләр. Аларда сурәтләнгән әйберләр һәм җиләк-җимешләр, әйтерсең лә театр сәхнәсендә, чөнки алар урнаштырылган эскәтерләр һәм тукымалар да ачылучы сәхнә пәрдәләренә тиң. Кызганыч, соңрак инде рәссамның күзләре начар күргән, һәм ул яңа картиналар яза алмаган. Ләкин үзен бәхетле хис итәрлек сәбәпләре булган: улы – инде Академия тәмамлаган хәрби, ә дуслары – аны ихлас, игелекле холыклы ханым, төпле рәссам буларак хөрмәт итүчеләр.


Кайберәүләр Әдия Ситдыйкова иҗатында А. Матисс, П. Сезанн иҗаты йогынтысы булуын ассызыкласа да, аның әсәрләре үз йөзе, милли төсмерләре белән сокландыра. Танылган рәссам 2000 елда Уфада дөнья куйган. Аның әсәрләре хәзер дә күп кенә күргәзмәләрдә еш экспозицияләнә.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА











ӘДИЯ СИТДЫЙКОВА



ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES




KazanExpress




OZON



Я Маркет







АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама